# ЭЧТӘЛЕК


Адашкан ........................................................................6
“Җыр шәп була... бетсә шәп җирендә...” ..................................6
Хатын-кыз чак .................................................................7
Күңел турында ...............................................................7
Билгесезлек.....................................................................8
Кояшлы көз.....................................................................9
Юлга чыгам ....................................................................10
“Җырлыйм, җырлыйм...” ...................................................11
Тормыш ..........................................................................11
Тауга карап .....................................................................12
“Корып була бу тормышны...” ...........................................13
Нәнәем истәлеге ..............................................................13
Көньяк кояшына үпкә .......................................................14
Авылда соңгы кич ............................................................14
Дөнья нигә киң икән! .......................................................15
Бездә булса .....................................................................16
Читтә - гөлләр илендә .......................................................16
Рәхмәт сиңа ....................................................................16
“Син көчле!” диючеләргә ..................................................17
Могҗизалар була бу яз аенда ............................................ 17
Сары яфрак ..................................................................... 18
Аңлашу ........................................................................... 19
Соңгы хат ........................................................................ 19
Хат ................................................................................. 20
Билет .............................................................................. 21
Сөеклемнең исеме ............................................................ 21
“Син бит минем ап-ак өметләрем...” .................................. 22
“Тиеп кенә китте кош канаты...” .......................................22
Иссен җилләр... ...............................................................22
Бәхет көткән идем ............................................................22
Ирләргә үрнәк тау ............................................................23
Яшьлек килгәндә ..............................................................23
Бер кичне ........................................................................24
Көзгә бер караш ...............................................................25
“Җәй буена язны сагынып...” .............................................25
Охшату ............................................................................25
Шундый көн .....................................................................26
Алтын тарак ..................................................................... 26
Табигать-ана кочагында ....................................................28
“Сугыш” сүзен әйтәлмәгн улым..” ......................................28
Гомер ..............................................................................29
Май ................................................................................29
Бәләкәй малаем янында ....................................................30
Серле йомгак ...................................................................30
Бәпкәләр югалды ..............................................................32

Нәнәйгә хат ....................................................................................33
Зәңгәр чыршылар ..........................................................................34
Читтә ...............................................................................................35
Март кояшы астында ....................................................................35
Асылыма җитә барам ....................................................................36
Әнкәйләр ........................................................................................37
Гомерен ничекякса кеше ...............................................................38
Утыз икедә .....................................................................................38
Йорт казлары турында ..................................................................40
Белдем .............................................................................................40
“Тәрәз ачып куйыйк әле...” ...........................................................41
Шәһәрдә ат .....................................................................................42
“Карлар яуган каеныма...” ............................................................43
“Кычкырыр лә кәккүк...” ...............................................................43
Өлешемә тигән көмешем ..............................................................44
Ватык көзгегә карасаң ...................................................................45
Юл тик алга ....................................................................................46
Сөйгәнемне күргән кебек ..............................................................47
Кабатланыр әле .............................................................................47
Алтын балык ..................................................................................48
“Борыч төям – азиаттыр...” ...........................................................49
Яз күрү ............................................................................................49
Син гармунчы булсын өчен... ........................................................50
“Җанга кардәш кирәк...” ................................................................51
“Сергә төренеп, нурга коенып...” ..................................................51
Ак тау һәм Мөхәммәт ....................................................................52
Мәңге кошсыз... ..............................................................................52
Мин калырмын көчсез ..................................................................53
Мәхәббәт җиләге ............................................................................53
Синнән башка ................................................................................54
Дустым булсаң ...............................................................................54
Сукырлык .......................................................................................55
Без шундый ерак ............................................................................55
Сагынганда .....................................................................................56
Син киткәч ......................................................................................56
Иске җырның яңаруы ....................................................................57
Мәхәббәт һәм мәкер ......................................................................58
“Бездә яз бит. Ярдан чыкты ташу...” ............................................58
Мәхәббәте.......................................................................................59
Исән калыймәле..............................................................................59
Көз һәм розалар .............................................................................60
Яратуларын көтәм........................................................................ 60....
“Күңелләрен синең яктырсын дип...” ..........................................61.....
Кол һәм патша ...............................................................................61....
Минем җәй .....................................................................................62
Бер күз салсаң, гөл булырмын ......................................................63

Үз күлмәгем ....................................................................................63
Җәй җыры .......................................................................................64
“Гөлле җәйләр узган инде...” .......................................................64
Хәзер .............................................................................................65
Көз – сер шул әле ..........................................................................65
Бер иркенлек ..................................................................................66
Көз .................................................................................................67
“Кагылган чаклар да истә...” .........................................................67
Күчеш чоры ...................................................................................67
Сагынып сөйләр өчен... .................................................................68
“Еллар үткән саен ачыла күзләр...” ...............................................68
Зәңгәр кар киче ..............................................................................69
“Көн дә яңа карлар ява...” ..............................................................69
“Көннәр ятты, еллар ятты...” .........................................................70
“Шомырт чәчәк атса...” .................................................................71
Тәрәзә юам .....................................................................................71
Ах, бу бәхет! ..................................................................................72
“Ак чәчәк, күк чәчәк...” .................................................................72
“...Ә бит оча белсәң иде!” .............................................................73
“Күзе сәер мәхәббәтнең!” ..............................................................73
Багышлыйм ....................................................................................74
“Кагышмасак капкаларны...” ........................................................75
“Карга күзен карга чукымаса...” ....................................................76
Эндәшмәүчеләр турында ...............................................................76
“Диңгез суы тиз җылынмый икән...” ............................................77
Шигырьгә .......................................................................................77
“Шатлыгымнан кайгысы күп...” ....................................................79
“Ах, бу нинди янмый көю...” .........................................................79
Этләргә медаль биргәндә ...............................................................80
“Мин үзсүзле – агымнарны бордым...” ..........................................80
“Гармун тартам, гармун тартам...” ................................................80
Серле көзге .....................................................................................81
Җырлар бәйләнә .............................................................................81
“Иске димим бу дөньяны...” ..........................................................82
Туган як манзарасы ........................................................................82.
Язгы ашкынулар .............................................................................85
Төштә шулай ..................................................................................85
Тарихка бер караш .........................................................................86
Төштә яшь бала күрәм ...................................................................86
Җәлилчеләргә .................................................................................87
“Урман тулган печән исе...” ..........................................................88
Ничек кенә түзәдер ........................................................................88
Кеше турында – кешегә .................................................................89
Степан Разин турындагы җырны тыңлагач ..................................89
Әкият урамы ..................................................................................90
Саклануга яратучыларга ................................................................91

Яңа елның серле мәгънәсе ........................................................92
Яшәү-сагыну .......................................................................... 92
Әйтелмәгән сүз ...........................................................................91
Чүл генә белә .............................................................................93
Яшьлектән бер сурәт ..................................................................94
Күкләрдән торып .......................................................................94
Безнең серләр .............................................................................95
Урман җыры ..............................................................................95
Төнге күл хатирәсе ....................................................................96
Сирень чәчәкләре ......................................................................97
Җавап көне ...............................................................................99
9 январь, Принстонда беренче кар ........................................100
Ялгызлар илендә .....................................................................101
Элек һәм хәзер ........................................................................102
“Ак калфакның карлган чагы...” .............................................103
Сәнксгивиң ..............................................................................103
“Һич юк иде үз күңелемне...” .................................................104
“Көнме? Төнме? Кем бу? Минме?” .......................................105
“Кыр казлары кышны сизә...” .................................................106
“Көн-төн яңгыр коядыр...” .....................................................106
“Тарагын ташлады – урман булды...” ..................................107
“Җәй дә яңгыр, кыш та яңгыр...” ..........................................108
“Ераклардан арып болыт килә...” ..........................................109
“Туктамастай койган яңгыр...” ..............................................109
“Ачтын ишегең...” ...................................................................110
“Утыз елдан соң яңадан...” ....................................................110
Ник син миңа тере килеш... ...................................................111
“Ярый, тик күрмәдең инде...” ................................................112
Югалтып торган урынга... .....................................................113
“Шатлыгыңнан улый-улый...”................................................113
Вакытсыз булды .....................................................................114
Үз башыма ..............................................................................115
Таптым дигәндә югалткач ......................................................115
Өметле хәл түгел .....................................................................116
“Кыргый теләк тулы күзләр...” ............................................. 117
Төшләр тәмам! ........................................................................ 118
Һаман саклый .........................................................................118
Кипкән яфрак җыры ..............................................................119
Әй, кара кош... .......................................................................120
Син генә, тик син генә ..........................................................121
Югалтулар ..............................................................................122
“Биш чат була сирень таҗында...” ........................................123
“Әллә күренә белмәдем?” ......................................................123
Сәүдәгәрләр җыры ................................................................124
Замана манзаралары .............................................................126
Океан аръягында ..................................................................127

Алмагачның ак чагы ..............................................................128
Ул чыдармы? ..........................................................................128
Кышкы урманда .....................................................................129
Гомер икегә ярылган .............................................................129
Карындагы бала монологы ....................................................130
Өметләр ..................................................................................131
Җир шарында .........................................................................132
Бәби тугач ..............................................................................132
“Әй, Кояш, кабул ит...” .........................................................133
Йомшак күңелле малаема .....................................................134
Төпчек улым тугач ................................................................134
Сабыйга мәдхия ....................................................................135
Солтанга мирас .....................................................................135
Бала тапкач ............................................................................136
Уларыма исем куштым .........................................................137
“Минем улым бар дөньяны...” ..............................................138
Түләү сорама .........................................................................139
Улыма дога ............................................................................139
Сөйкемле сөяк .......................................................................140
Әниләр сагына .......................................................................140
Син .........................................................................................141
Шомырткай ............................................................................142
Ярый инде җай чыккач .........................................................142
Шундый очрак .......................................................................143
Ярый инде .............................................................................144
Ник тузасың! .........................................................................144
Бердәнбер чара ......................................................................145
“Тыңлыйм сине...” ................................................................146
Мин сөйсәм... ........................................................................146
“Чирле мәхәббәтем минем!” .................................................147
Яңа гомердә ..........................................................................148
Син генә минем өчен ............................................................
“Агачлар кып-кызыл, нык кызыл!” ..................................... 149
Каен утыны ...........................................................................149
Бәхет манзаралары ................................................................150
Хәсрәтле җыр ........................................................................151
“Мәхәббәтем сүнмәс борын...” .............................................152
“Кашыгы белән бирәсең...” ...................................................152
“Мин үтердем бүген сине...” .................................................152
“Хәбәрең-хәтерең юкка...” ....................................................153
Гаҗәбемнән гаҗизмен ...........................................................154

## АДАШКАН

Ашыгулар ялгышуга була.
Юк шул минем сабыр канатым...
Ялгышларым – урман,
язмышларым – буран...
Йөгерә-йөгерә кереп адаштым.

Ашкынулар үкенечкә була.
Ах, шулар ул - минем канатым!
Үкенечләр – урман,
өметләрем – буран...
Көлә-көлә кереп адаштым.

Шашынулар һәлакәткә була.
Һай, мин сине шашып яраттым!
Күңелең – серле урман,
мәхәббәтем – буран, -
Җырлый-җырлый кереп адаштым...

Урман – моңлы, буран – шомлы була...
Булса була – ә мин яратам!
Юлым – кара урман йә ак буран,
Хыялларым шунда адашкан.

Мин – бәхетле,
буран ера-ера,
Хыялларга тотынып чабалсам!
Мин – бәхетсез,
гомеремнең бер көнен
Ашкынусыз яшәп карасам.
Мин бәхетле – гомергә бер булсын,-
Урман-күңеленә багалсам...
Рәхмәт, усал буран, - горур иттең,
Рәхмәт, моңлы урман, - җыр өйрәттең.
Мин – бәхетсез, җырлый алмасам,
Мин – бәхетле, еглып калмасам.
Мин – бәхетле, ялгышлардан туган
Язмышларны җиңеп баралсам.

Китмәм, ахры, шушы язмышымнан –
Мин бит бәхетем белән адашкан!
Моңлы урманымны – буш яланга,
Буранымны – җилгә алмашмам.

***

Җыр шәп була... бетсә шәп җирендә,
- Тагын, тагын җырла! – дисәләр.
Төш шәп була – көпә-көндез, өндә

Төшнең дәвамында йөрсәләр.

Кунаклар шәп булса, хушлашалар:
- Бер күрү – бер гомер!- дип кенә...
Биздереп һәм бизеп китми алар,
Сагындыра алар, көттерә.

... Мин шәп кунак булсам иде җирдә,
Яки – шәп җыр.
Һич булмаса – бер шәп төш кенә...

## ХАТЫН-КЫЗ ЧАК

Күңелләрем уйнап тора –
Бик алгысаган чагым...
Җылы сүзгә, якты хискә,
Назга сусаган чагым!...

Күңелләрем сыкрап тора –
Нечкәреп җиткән чагым.
Бер авыр сүз күтәрсәм дә,
Өзелеп китәр чагым!...

Күңелләрем сызылып тора –
Җанның яралы чагы;
Текә таудай рухның, егылып,
Нидер ялварыр чагы...

## КҮҢЕЛ ТУРЫНДА

- Нәнәй, нәнәй, күңел нәрсә ул?
- Үскәч... белерсең, балам.
*(Балачактан)*

Уйлар баса, моңнар баса,
Өмет катыш шомнар баса.
Уйлар озын, гомер кыска...
Янам микән әллә юкка?

Кош сыя кош оясына,
Ә күңелгә - дөнья сыя:
Сыйган анда халыкларым,
Киләчәгем, тарихларым;
Халыкларның шатлыклары,
Кайгылары сыйган тагы.
Төшемдә дә өмет күрәм,
Өнем тулган уйлар белән,

Күңел тулган уйлар белән...

Кош сыя кош оясына,
Ә күңелгә - дөнья сыя.
Ә күңел ул – ирек сөя,
Күктән төшкән бер кош, гүя:
“Азат ит бу дөньяңнан!-ди, -
Бушат мине уйлардан! – ди.
Кыса мине җир гамьнәре,
Ах, ычкындыра богаудан!” –ди.

Уйлар озын, гомер кыска...
Янамдыр да, бәлки, юкка.
....Тик күзләрем күрә белгәч,
Илдә искән һәм исәчәк
Барлык җилләр миңа тигәч,
Мин – кош түгел. Кеше, күңел,
Кичер мине, кичер, күңел:
Богау димә - уйсыз, моңсыз
Һәм ваемсыз мөмкин түгел.

Кош сыя кош оясына...
Хәер, кермим гөнаһына:
Бәлки, нәни кошларның да
Дөнья сыйган күңеле бардыр.
Шуңа күрә таң атканда
Үз оясы кошка тардыр;
Шуңа алар талга басып,
Күккә ашып сайрыйлардыр...

Хәер, кермим гөнаһына –
Сер күп кошлар дөньсында.
... Ә син, күңел, миңа кадәр
Кош күңеле булган сыман!..
Кошларыңа кайтырсың син,
Кайтырсың син миннән соң да...
Тик анда да тынмассың шул –
Сыймассың кош оясына.

## БИЛГЕСЕЗЛЕК

Карт инде гомер агачы –
Яшьтәш Җиргә.
Тик миңа тигән яфрагы
Яшь бөредә.

Көзләр, кышлар була җирдә,
Карлар ява.
Ә гомерем, ә бүгенем –
Гел яз-бала.

Иртәгә - яз! Ул булганга
Яшим бүген,
Ачылар дип шул тылсымлы
Яшел бөрем.

Таңнар ата – офыклар ал,
Юллар томан.
Офыкларга җитим диеп
Юлга чыгам.

Җирдә кояш, җирдә җылы –
Җәйдер инде...
Ә гомерем – һаман серле
Язгы бөре.

Ә офыклар – аллы-гөлле
Билгесезлек...
Һәм мин җиргә мәңгелеккә
Килдем кебек.

## КОЯШЛЫ КӨЗ

Чың-чың... чың-чын..
Чыңлый нурлар, чыңлап һава.
Көзге көн бу, изге моң бу –
Сарылган ул болытларга,
Җилләргә дә уралган ул,
Чорналган ул чаганнарга.
Кояш яна чың-чың итеп,
Чың-чың килеп яфрак ява...
Шуңа:болыт миннән биек,
Миннән биек алтын яфрак.
Кояш миннән мәрхәмәтле,
Җиңел җилләр миннән сафрак.
Җилгә җиңел, миңа авыр-
Вак баскан күңел тардыр,
Куенда да ташлар бардыр...
Кул авырдыр, тел авырдыр...
Бәлки, бу – җан газабымдыр?!
И даһи моң! Илаһи моң!
Гөнаһлымын!-

Кил, син кирәк!
Урал миңа – күтәр мине
Үз-үземнән биегерәк!..
Дога укыйм, кабул булсын:
Вөҗданыма шул моң иңсен –
Инде күңелем гел киң булсын,
Инде кулым гел мул булсын,
Авыр сүзем җиңел булсын...
Сүзләрем дә, күзләрем дә
Чынлап торган нурлар койсын.
Шатлыгым да, сагышым да,
Гөнаһым да якты булсын!
Биеклеккә сәҗдә итим,
Түбәнлектән тәүбә итим.
Янарга да – чистарырга!
Кояш кирәк – очып китим,
Бөек моңга кушылып китим!

... Чың-чың, чың-чың...
Чыңлый кояш –
Нидер яна... Моңнар кала...
Чың-чың килеп мин дә яныйм:
Саф һәм җиңел моңга калыйм
Һәм сезне дә чорнап алыйм!

## ЮЛГА ЧЫГАМ

“Агыйделнең аръягында
Бер энәгә - бер сыер!”-
Көлмәгез лә! Тәвәкәлләр,
Дәрте барлар юл йөрер!..
Күңелләрем иләсләнсә,
Әй, әйләнәм сабыйга!
Ышанам – мин юк җирләрдә
Могҗизалар барына:
Алтын таулар калыкканга,
Көмеш сулар акканга;
Ярсып, яшь гомерләр түгел,
Поезд гына чапканга...
Эзләрмен дә табармын күк –
Килер кебек бөек көн!
Миңа дигән утырау бардыр –
Диңгезләр күп, җир – иркен.
Дәртем таша. Юлга чыгам.
Озын торна-хыялым
Аккош булып йөзәр әле

Бер күлендә дөньяның!

***

Җырлыйм, җырлыйм,
илһам җырга сыймый –
Мал барлыктан түгел, җан байлыктан.
Җырлап булмый кайчак, елап булмый –
Мал юклыктан түгел, җан бушлыктан...

Дөньяларга шатлык таратучы –
Сүз җырлары түгел, хис җырлары...
Кара кайгыларны агартучы –
Күз яшьләре түгел, хис яшьләре...

Маллар кереп, җанны басып алса,
Сүзләр генә булыр җырларымда.
Шул сүзләрне җәлләп елармын да!
Тик күземнән агар... сулар гына...

**ТОРМЫШ**

Безгә ак болыт булырга
Язмаган шул.
*(Р. Фәйзуллин)*

Ак болыт та гел ак тормый –
Кабара да карала.
Ул әле җиргә дә төшә -
Яңгыр ява, кар ява...

Йолдызлар да, күктә балкып,
Атылалар түбәнгә.
Никтер йолдыз атылуга
Шатланалар күргәннәр.

Ак болыт булып алырга
Язган булса сиңа да,
Мен югары, аш күкләргә!
Төшәреңне уйлама!
Тормыш үзе – күккә ашу,
Менгәч, төшми – юк чара...

Шулай тиеш: җир шатлана –
Биргәнен алганына;
Күк шатлана – җиңеләеп,
Чистарып калганына.

Син дә шатлан, бер булса да –
Күкләр айканыгыңа!
Көнләшәм – сиңа ак болыт
Булырга язганына.

Йолдызлар булып алырга
Язган булса безгә дә,
Мин әзермен, күктә балкып,
Җиргә атылып, сүнәргә!..

Әйдә, йолдыз атылуга
Шатлансыннар күргәннәр!
Тик күрсеннәр өчен дә бит...
Кирәк күккә менәргә!

## ТАУГА КАРАП

Үргә карап фикер ит
Түбән карап шөкер ит.
*(Мәкаль)*

Салмак атлар барганнарны
Йөгереп узасым килә;
«Адәмчә» буласым килми,
Үзем буласым килә.

«Ярыйсы» ул – ярты кебек,
«Бөтен» ясыйсым килә,
«Яраган безгә!» - дисәгез,
Әрләп ташлыйсым килә.

Беркем дә очрамаган
Күлмәк киясем килә.
Бер җырга да охшамаган
Җырны беләсем килә.

Бәхетле һәм көчлеләргә
Якын торасым килә.
Агачларның асылына
Асылынасым килә!..
Халыкның кодрәтле сүзен
Кире борасым килә:
Түбән карап шөкер итмә!-
Аска карый мәхлук мал...
Ә син – кеше, баш чөеп йөр!
Югарыга үрләп кал!

Түбән карап шөкер итмә,
Өстеннәрдән гыйбрәт ал.
Өскә карап фикер ит тә,
Расла кешелегеңне;
Кешегә кара, кешегә...
Тыйма көнчелегеңне!

Нәрсә затлы, нәрсә яхшы –
Мин кешеләрдә күрдем.
Юкса акны-караны да
Беләлми калыр идем;
Бер матур күлмәк кенә дә
Киялми калыр идем.

Көнләшәм мин – акыллыдан,
Алдынгыдан, уңганнан...
Хәттә мәрмәр һәйкәлләрдән,
Хәттә кояштан, айдан!

....Ай-кояшлар миннән биек!
Таулар да биегерәк...
Бәлки, йолдыз калкыр әле.
Башларга тиеберәк!...
Тик йолдызы кыйммәт түгел,
Кыйммәте – ярсу йөрәк!

***

Корып була бу тормышны, ләкин
Борып булмый икән үзеңчә.
Дөнья чиксездер дә - Җир түгәрәк,
Гомер чикле. Вакыт озынча...

## НӘНӘЕМ ИСТӘЛЕГЕ

Фани дөнья читтә инде,
Ай-һай нечкә бәйләнеш!
“Җирдә эш бетмәстәй иде,
Бетә икән, балам, эш...”

Озак торган – савап җыйган,
Минем нәнәй – саваплы...
Оҗмахка керелек итеп
Бирер иде җавапны!...

Тик күзләре нурсыз аның,-

Хыял юктыр күңелдә.
Ах, кем икән башлап әйткән:
“Берни юк, - дип, - тегендә”?!

Нинди бүләкләр бирсәм дә,
Тормыш инмәс җаныңа;
Ах, кем икән йозак элгән
Нәнәм оҗмахларына!

Нәнәем хыял кирәк –
Ничек үткәрсен көнен?
Нәнәемә өмет кирәк –
Нәнәемә бик кыен!

Һай, дөреслек! Нәнәемнең
Очар күңелен урладың!..
Нинди бөек ялган белән
Күзләреңә нур салыйм?!..

## КОЯШ КОЯШЫНА ҮПКӘ

Монда җылы. Ә Уралда суык.
Сиңа, кояш, бу як кардәшме?
Ә ул якта майда корау сугып,
Сиреңьнәрем шәрә калмасмы?

Сине гадел диләр. Гадел мин дә -
Бар җирендә сөям илемнең...
Ләкин Уралыма сине менә
Ешрак борып куяр идем мин.

## АВЫЛДА СОҢГЫ КИЧ

Йөгрә-йөгрә судан кайткан чакта,
Әллә нишләп суым чайкалды...
Ай төште дә чиләгемә -
Күңелем минем шуңа тын калды...

Ай бии дә бии сикереп-сикереп,
И шатлана, итә тантана!
“Дусларны мин оныта белмим, - диеп, -
Таныйм сине, судан кайтканда!
Син ташлама мине ятларга!”

Ә мин аңа бер сүз әйтәлмәдем...

Баскан җирем куйды чайкалып...
Китеп булса икән туган яктан
Чемоданга тулган ай салып!
Әй, түгелде суым! Ай күмелде...
Күңелем күле тулды, айкалды!
Тугрылык һәм хыянәткә шаһит,
Сарыларга сабышып ай калды...
Ятка калды... Судан кайткан чакта
Чиләкләрем шуңа чайкалды...

## ДӨНЬЯ НИГӘ КИҢ ИКӘН?!

Әнкәй әйтте: "Җиләк җыйсаң,
Бер җирдән җый тырышып.
Алан сайлап, урман чапсаң,
Буп-буш кайтыр тырысың".
Тик - кайсы алан минеке?
Эзлим, сайлыйм йөгереп.
Ә кояшны бирәү диләр,
Берәү диләр гомереҥ.
Яңа кояш юллап йөрсәң,
Гомереҥ иртә тузар...
... Ах, белмисез, таң атканда
Шаулап уза поездлар!
Көннең чыгышларынамы,
Әллә баешларына? –
Кулым болгап йөгереп чыгам
Поезд тавышларына!
- Тукта! Тукта!
- Китәм! Тотма!
Ах, илгизәк, ах, күңел!..
Тик: "Исәргә - көн узар", дип.
Әйтергә генә җиңел:
Туган йортның чирәмнәрен
Үксеп эзлим төшемдә...
Ә уята поезд тавышы! –
Нәрсә җитми кешегә?..
Сагынамын, саргаямын,
Кем гаепле, кем икән?
... Нигә шулай күп соң юллар,
Дөнья нигә киң икән?!
Ә сагынмый, саргаймый да,
Саргаймый да, сайланмый да,
Сайланмый да, эзләнми дә,
Ялгышмый да, төзәлми дә -
Яшәү мөмкинме икән?...

## БЕЗДӘ БУЛСА...

Пычык-пычык елап йөри,
Инде ничә көн бозып...
Ни явалмый, ни таралый,
Кемгә охшаган бу болыт?..

Их, бездәме... Бар булганын
Чиләкләп кояр иде!
Ачуыннан күк күкрәтер,
Чәменнән елар иде.
Ярсуыннан күкне ярыр,
Яшеннәр ягар иде.
Бәйрәм итеп аллы-гөлле
Күперләр корыр иде;
Күңелен басып, йөзен ачып,
Ялт итеп торыр иде!
Их, бездәме... Болыты да
Безнеңчә булыр иде!

## ЧИТТӘ - ГӨЛЛӘР ИЛЕНДӘ

Исең дә юк, затлы төсең дә юк,
Ишең дә юк синең, умырзая!
... Асыл гөлләр белән уралдым мин
Тик җилгә монда – көн озая.

... Анда, безнең урман буйларында,
Һаваларны язгы җил тетәдер!
Сүтмәгәндер кояш алтын чәчен,
Тик анда ул җанны җылытадыр.
Үкенмидер, күрмәсә дә җәйне –
Туган урманында – умырзая!
... Мактап яшәр идем чит җирләрне,
Көннәр узмый монда, көн озая –
Гомер зая уза, гомер зая...

## РӘХМӘТ СИҢА

Яшрен янарга өйрәттең,
Хатлар ягарга өйрәттең,
Җырлап-еларга өйрәттең,
Елап – чыдарга өйрәттең.
Оялчанлыкка өйрәттең,
Олыҗанлыкка өйрәттең.

Өйрәттең матур күренергә,
Өйрәттең очып йөрергә,
Тотынырга яшеннәргә
Һәм биек, биек менәргә!
Күккә мендем, рәхмәт сиңа!

Хисне үч белән болгаттың,
Хыял сарайларын ваттың,
Горурлык җенен уяттың,
Күкләремне каһәрләттең!..
Төштем җиргә... Ләкин бит мин,
Бит мин күктә очкан идем –
Үз-үземнән биек мендем!
Биеклекнең тәмен белдем...
Һәм һичкайчан үз-үземнән
Түбән була алмамын мин.
Менә шуңа – рәхмәт сиңа!

## “СӨЮ КӨЧЛЕ!” ДИЮЧЕЛӘРГӘ

Мин яңадан үз-үземә кайттым:
Аек башлы горур бер кеше –
Күп көлми дә күп еламый да торган,
Акыл – камил, рухият көчле.
“Көчле” диюегез хак төсле.

Үз-үземнән кире китәр идем
Киң күкрәкле көчле ярыма.
“Тилекәем!” – дисә, көләр идем
Һәм тилерер идем тагын да...
“Бәләкәчем!” – дисә, елар идем,
Тезләренә сарыла-сарыла.
Горур башкаемны ияр идем,
Үлән булыр идем алдында!
Акылсыз һәм көчсез калыр идем, -
Көчле ярым булса янымда!...

## МОГҖИЗАЛАР БУЛА ЯЗ АЕНДА

Чал чәчле Җир кыз чагына кайткан –
Гүзәл яз хакына.
Яз белән кыш назлы кочаклашкан
Ялгызак тамчыда.

Ах, тамчылар! Үтә җаннарыма,

Күзләремнән тама!
Могҗизалар була яз аенда!-
Киттем синең янга...

... Гүя минем тау-тау ак өметләр
Булмаган тик ак кар.
Гүя, һәр яз алар акмаганнар,
Бары сулар аккан.

Гүя мин яз булып җилкенгәндә,
Син кыш булмагансың...
Гүя атлап узу мөмкин әлдә
Яз һәм кыш арасын.

Яшь кыз булган әнә
                чал чәчле Җир –
Мөмкин барысы да!
Язлар кыска. Киттек тизрәк, йөгер
Ташкын каршысына!

Кар һәм кояш хәттә бергә сыя
Язның тамчысына...
Могҗизалар була яз аенда –
Мөмкин барысы да!

## САРЫ ЯФРАК

Сары яфраклар коела,
Җансыз күбәләкләр төсле...
Бүген берсе - өстәгесе,
Иңбашыма килеп төште.

Алтын яфрак, салкын яфрак,
Юлдан язган җилләр өзгән.
Миңа килеп сыенасың:
“Саклап кал, - дип, - сары көздән...”

Чәчләремә кадар идем –
Сарысың бит, сагышсың бит...
Җилләр бирде, җилләр алыр –
Очып китеп барырсың бит...

Яшел идең, биек булдың –
Йолдызларга яр булдың син...
Көз бит инде, алтын кошым,
Оч, уятма яз тойгысын!

Әнә яфраклар коела,
Соңга калган хисләр төсле.
... Мөхәббәтең ак каеннан
Сары яфрак булып төште.

## АҢЛАШУ

Мин ачылам миннән ачыкларга,
Миннән сабырларга сокланам;
Миннән өстеннәрдән көннәшәм мин,
Миннән акыллыдан көч алам;

Мин ихтирам итәм миннән зурны,
Миннән талантлыны зур күрәм;
Куркам бары миннән явызлардан,
Миннән көчлеләргә буйсынам.

Яратмадым:
Көнләштерәлмәдең –
Өстен булмадың һичкайчан.
Буйсындыралмадың.
Көч тә бирәлмәдең...
Куркытылмадың да, ичмасам!

Мин ташладым сине!...

## СОҢГЫ ХАТ

Бәхет өчен алтын таулар
Кирәк микән, кирәк микән?-
Сезнең яктан ай туса да,
Мин бит синнән хатлар көтәм.

Дулкын-дулкын хат юллары –
Бу бәхеттән бөгеләм инде.
Дулкын саен – синең күзләр –
Түгеләм инде, сибеләм инде!..

... Ә бу хатта сукыр күзләр –
Кыеп ала кылыч сүзләр:
“Ант бирмәгән, ант бозмаган,
Кичер, - диләр, - оныт!” – диләр.

Утлар төрттең, сулар сиптең,
Җаннарымны җансыз иттең.
Юк, онытмам, гафу итмәм,

Тик ант итәм: хатлар көтмәм...

Дулкын-дулкын зәңгәр юллар –
Соңгы хат бу, соңгы хат бу.
Үткәннәрдән, көткәннәрдән
Соңгы хат бу, соңгы хат бу...
Соңгы хат бу, соңгы хат бу.

## ХАТ

Исемең кушып
            җырлар җырым беткән,
Уйлар килми синең хакында,
Синсез дә бу дөнья – тора икән!
Әллә инде булмагансың да...

Син юклыктан – карлар кара түгел,
Көннәр дә юк кояш чыкмаган...
Күрсәм – төшем,
            дәшсәм – үз кешем бар,
Бәхет барлыкка да - ышанам.

Гамьнәрем дә, гамәлләрем дә бар,
Өмет бачасына еш керәм...
Тик төннәрдән бер төн, ялгыш кына,
Мин “Мәхәббәт” атлы төш күрәм.

Тик төннәрдән бер төн – aклардан-ак
Каурый-каурый тәүге кар була –
Киткән аккош гүя, кайтып ялгыш,
Каурыйларын коеп талпына.

Тик төннәрдән бер төн бер җыр килә -
Үзәкләрне өзеп алырлык! –
Агып барган агым судан алып,
Дөрләп янган утка салырлык!

Шундый карлар,
        шундый җырга кушылып,
Ап-ак моң итә дә күк төнне,
Мин төш күрәм Мәхәббәткә атап
Һәм төшемдә күрәм тик сине...

Төннәрдән бер төн ул – ялгыш кына.
Ә башкасы?
Ә башкасы – язмыш шикелле...

## БИЛЕТ

Ертмакчы да булдың билетымны –
Кәгазь генә бер билет.
Ник озаттың мине соңгы тапкыр? –
Соңгы икәнен дә белдең бит!

Поезд китте, мине алып китте.
Төшеп калсам, нәрсә булган ла!
Язмыш кына иде бугай поезд,
Язгыш кына калдың перронда...

Ялгыз гына киттем, антсыз гына.
... Гомер җитмәс ара үтелгән.
Кара урман баскан араларны,
Кошлар да юк сәлам китергән...

Вокзалыгыз – урман арты гына,
Килеп ләкин булмый бирегә:
Киләчәккә билет сата касса,
Үткәннәргә бирми кирегә...

## СӨЕКЛМНЕҢ ИСЕМЕ

Крамагыз бер генәмә,
Әйтмәгез исемнәрен!..
Ул сандугачлар ярата –
Сандугач, кит син, бәгърем!
Ул йөргән урамнарга да
Кертмәс идем һичкемне...
... Ах, көндәде язмыш-явыз,
Минем көнчел гыйшкымны!
“Ул күргән офыкларны да
Күрмәсен” дигән микән?
Мин көнләгән сандугачны
Кемнәргә биргән икән?..
Тамчы суга зар елаган
Чүл ялчысы төсле мин –
Кемнәр күрә сөеклемне,
Кемнәр ача ишеген?
Кемнәр исендә?-
Әйтегез –
Бик сагындым исемен!
... Тик һаман да көндәше мин
Исемен әйткән кешенең...

***

Син бит минем ап-ак өметләрем,
Син бит минем кара шикләрем.
Хисләремне, шикләремне белми,
Мәңге белми калсаң – нишләрем?!

Әйтелмәгән сүзләремнән үреп,
Йөрәгеңә көмеш юл сузам...
Сүзләр әйтмәм:
Алтын-көмеш хакын
Аңлый белсәң, кил син шул юлдан.

***

Тиеп кенә китте кош канаты,
Чык калмады гөлдә бер бөртек...
Мәрҗән итеп тезгән хисләремне
Бер аек уй куйды юк итеп!...

## ИССЕН ҖИЛЛӘР

Элек кигән күлмәкләрем – сакланмаган.
Элек булган теләкләрем – акланмаган.
Элек янып сөйгән ярым – ятка калган.

Ул күлмәкләр – яшьлек төсе, -
онытылмаган...
Ул теләкләр искә төшсә, һушсыз калам...
Ул мәхәббәт төшкә керсә, утсыз янам!..

Әй, сакламыйк әле җанның салкын көлен –
Көлдә аунап куанырга – кошлар түгел!
Сүнгән утлар – ул мәетләр – ышан,
күңел!
Иссен җилләр,
очсын көлләр...
бушан, күңел!

## БӘХЕТ КӨТКӘН ИДЕМ

Әй, киттең лә киттең...
Бәгъремне кистең,
Бәхет көткән идем –
Шагыйрәң иттең...

Рәхмәт – онтылмадың,
Калдың җырларга.
Шигырем “Кояш” атлы,
Җирдә син барга.
Сагынып көтеп тора
Иртә, кичкырын
Җырым – синнән калган
Иркә кызчыгым.
Ләззәтле һәм якты
Моңсу уйларым.
Сагыш иленнән мин
Тылсым урладым.
Әй, көттем лә, көттем!
Җаныма үттең!
Кызым “Кояш” атлы –
Бәхетле иттең..

## ИРЛӘРГӘ ҮРНӘК ТАУ

Ай, бу Кавказ биек икән!
Эшләпәсе болыт икән –
Нинди килешә чал чәче!
Дан гына ир-егет икән...
Күкрәкләре урман икән,
Адым саен имән үскән;
Җимерелми, шуңа микән, -
Төпле ирләр сыман икән.
Кыяфәте горур икән,
Күп макталган – эремәгән...
Әллә соң бу чын ир микән?
Чылтыр-чылтыр шарлавыклар –
Йөрәге тулы җыр икән.
Күңеле җырда, башы күктә, -
Төшләргә керер икән!..
Монда хикмәтләр бар икән,
Алалсаң гыйбрәт ал икән...
Тик серен таш итеп саклый –
Ирләргә үрнәк тау икән.

## ЯШЬЛЕК КИЛГӘНДӘ

Җаннарыма үтте кояш җыры –
Йөрәк ярып бозлар кузгала.
Абау, кайнар бозлар!
Карлар – утлы кузлар,
Йөрәкләрем тулып боз яна!

Кулларыма каен кузы тиде –
Нурлар күрәм, үреләм – тоталмыйм!
Таллар, мин нишләдем?
Нигә юк хисләрем?
Кошлар җырын ишетәм, оталмыйм...

Үзем җирдә, күңел әллә кайда...
Яшьлек кулын сузган ич күктән!
Бәхет тора аздан –
Канат сорыйм яздан –
Сыерчыккай, бирче үтечкә?-
Толымнарымны ал бер кичкә!..

## БЕР КИЧНЕ

Мәрҗән-мәрҗән тезелеп,
Бизи карлар җирне.
Абау, күзем чагыла! –
Сукыр калам инде.
Карның сафлыгыннан,
И, киңәя һава!
Агарган саен, җир
Иркенәя бара.
Кар йомшаткан назлап,
Ефәк иткән җилне.
Абау, бигрәк җиңел –
Очып китәм инде!
Ак бишеккә җиһан –
Гүя яңа туган...
Мин дә яңа менә
Туып килгән сыман.
Дөнья белән бергә
Ап-аклана җаным,
Һәм киңәя йөрәк,
Җир киңәйгән саен.
Ах, йөрәгем! Ярылыр...
Буп-буш киңлек анда!
Буш итмәгез җанны!
Күп кирәкми җанга:
Салыгыз ак эзләр –
Күңелем – иркен урам,
Елмайсачы берәү –
хәзер гашыйк булам!
Ефәк җилдәй нәфис,
Кардай йомшак күңел.
Җырлагызчы бер җыр –

Түгелеп җылар идем.
Теләгез ак теләк!
Эндәшегез көлеп!
Туып кына киләм –
Калыгызчы күреп!..
Җем-җем балкыр идем,
Бәхетле җир кебек.
Күңелем балкышына
Җир таң калыр иде.
“Тиңдәш таптым!” – диеп
И шатланыр иде.

**КӨЗГӘ БЕР КАРАШ**
(Тукайны уйлап)

“Үтте, - диеп, - дәрт вә дәрман чоры!”
Һаваларда ялгыз торна моңы...
Басуларга бушлык таралган,
Яшел йөзе җирнең саргайган.

Биек-биек хыялларны кыеп,
Салкын җилләр үтә җаныма.
Бу – көз инде...
Ләкин яздан үлгән
Умырзая бик тә жәл миңа:
Барыбыз да көзгә барабыз да...
Тик җәйдән соң – көз ул ял гына.

***

Җәй буена язны сагынып
Кипкән яфракларын таллар
Агым суга салганнар да,
Олыгаеп тын калганнар.
Тик иң өстә ялгыз яфрак
Саклап калган яшел төсне:
“Сайра, былбыл! Әле җәй бит,
Таллар яшь бит!” – дигән төсле.

## ОХШАТУ

Яз килде дә - язның җырын җырлап
Агып китте карлы ташкыннар...
Моңлы калды кара күлмәкле тау,
Яшьләр коеп кый ташыннан.

Беркөн кайтыр карлар, болыт булып,
Җылы яңгыр, салкын боз сибеп...
Тау аларны тагын кабул итәр,
Нишләсен тау? – хатын-кыз кебек.

## ШУНДЫЙ КӨН

Кояш әйтә: “Көл” дә “көл”, - ди,
Яшь чыгара күздән җиле.
Үзе кояш, үзе суык, -
Бүген җәйнең китәр көне.
Картайдылар күбәләкләр,
Бал кортлары безләмиләр.
“Чәчәк чаклар” үтте, - диеп
Зар сөйлиләр җилгә гөлләр.
Алмагачлар алма коя,
Тук башаклар шаулый җирдә;
Алда тагын күп-күп көннәр:
Бар тереклек орлык сибә.
Кояш бата, офыклар ал –
Димәк, аяз килер таңнар.
Юмарт көзләр, таза кышлар –
Алда иң шәп гомер калган!
Алмалары көлеп тора,
Елап тора сулган гөле...
Үзе рәхәт, үзе кыен –
Бүгенге җәйнең соңгы көне.

## АЛТЫН ТАРАК

- Су анасының нәрсәсе бар?
- Алтын тарагы бар.

Алтын тарак, алтын тарак!
Каян аласың аны!
Юк шул, безгә ата-баба
Алтыннар калдырмады...
Япь-яшьләр башлар чыгып китте
Үзең күр үз көнеңне!
Ә җиңелме илгә чыгу,
Ә көн күрү җиңелме?..
Диңгездә нәни көймә кук
Чайкалдык та чайпалдык...
Йөзә белмәсәк - өйрәндек,
Өйрәтте бөтен халык.
Чәчтән тартып чыгардылар

Батып барган чакларда, -
Рәхмәт хисе күңелемдә
Гомер буе саклана.
Илдә чыпчык үлми, диләр,
Язган булса, сау кала.
Сау калды, әрәм булмады,
Адәм булды бит бала!
Шундый илең бар вакытта,
Алтыным юк, дип кара!
Бурычларны чак күтәреп,
Илем буйлап барамын.
Шушы илем, шушы халкым –
Минем алтын тарагым.

Илдә искән һәрбер җилдән
Сыгылып дулкынланамын.
Әллә бала мин бу илгә,
Әллә инде анамын:
Утлы җил килсә илләргә,
Миндә янгыннар куба.
Бозлы җил гөлләр булганда,
Йөрәк калтырап тора...
Инешләрдә сулар кипсә,
Сугарам яшем белән.
Илгә нурлы яңгыр килсә,
Көч алам яшененнән!
Елый йөрәк, көлә йөрәк,
Уйлар уйлап барамын.
Менә шушы йөрәк инде –
Минем алтын тарагым.
Йөрәк белән йөрибез без
Уфтанып та шатланып.
Нәфрәтләнсәк – кычкырабыз
Ишетсен дип бар халык, -
Туганыма ярамам дип,
Тел яшереп тормыйбыз!
Яшермибез, сокласак та,
Телебез бар – җырлыйбыз.
Нәфрәткә дә, рәхмәткә дә
Бигрәк оста бит телем.
"Озын" - диләр.
"Озын булсын!
Мәңге кыскартмам!" – димен.
Телем озын, юлым озын.
Җырлар җырлап барамын.
Шушы җырым, шушы телем –

Минем алтын тарагым.

## ТАБИГАТЬ-АНА КОЧАГЫНДА

Шундый тынлык – бар хафаны
Оныттыра.
Ак болытка ятып, кояш
Оеп тора.
Җил, исәргә кыяр-кыймас,
Тыйнак тора.
Тузганаклар тузмый гына
Җыйнак тора.
Күбәләкләр иплэп кенә
Очыштыра.
Яфраклар да - шыпырт кына,
Пыш-пыш кына.
Чөнки минем улым йоклый
Мыш-мыш кына.
Бар табигать сакчы аның
Йокысына.
- Табигать! Кодрәтеңә
Чик-чама юк!
... Балаларың тынлык боза –
Ник чара юк?
Балаларың аза-туза,
Вата-кыра, аса-кисә,
Сабыйларның гомерен өзә -
Ник җәза юк?!
- Кодрәтем бар тик шәфкатькә,
Яманга – юк...
Мин бит – Ана.
Җәзалырлык
Балам да юк.

***

“Сугыш” сүзен әйтәлмәгән улым
Сугышлы уйный, мине тыңламый.
Мылтык аскан, фуражкасын кигән:
“Киттем! Ела! Үлдем! Ела!” – ди...
“Бах-бах” – ди дә “гөрес” җиргә ава,
Курчак тоткан кызны куркыта.
Фәрештәдәй сабыйкаем минем,
Нинди шайтан сине котырта?!
Ник, табигать, җир туганнан бирле
Малайларның канын бозасың? –

Фәрештәдәй гүзәл кыласың да
Җен шаукымы кагылдырасың!
Иң табигый максат куйдың бит син –
Таш тишеп тә гөлләр тудырдың!
Үлем теләү гайре табигый бит!
Әйт, табигать, кайсы йөзең чын?!
Син дә икейөзле каршылыкмы?-
Иҗатында – фәрештә һәм җен...

## ГОМЕР

Секундлар белән, минутлар белән,
Дошманнар белән һәм дуслар белән,
Сөйгәннәр белән һәм ятлар белән,
Болытлар белән, агачлар белән
Бер танышу бу, бер сүз кушу бу,
Шундук мәңгегә югалтышу бу...

Болытлар килә, китә мәңгегә -
Яңа болытлар булып әверелә.
Күрешү булмас инде соңыннан, -
Бер минуттан соң мин дә булмам.
Бер мизгелем дә кайтмас яңадан...

Гел сулыш алу яңа һавадан!
Кабатланмаула ашкыну һаман,
Яңа булу һәм яшь булу һаман!
Газапта ана балалар таба,
Яңару дәрте көч бирә аңа!
Туу – яңару, үлү – яңару,
Мәңгелек хисе шуңадыр җанда!
Дәртләнеп-ярсып алга ашу бу,
Ә бит мәңгегә бәхилләшү бу!..
Нинди фаҗига, нинди тантана!
Ах, бар да артта... Ах, бар да алда!
Күпме бәхет бу бәхетсезлектә,
Вакытлылыкта һәм чиксезлектә.
Колачны җәеп алга ашу бу,
Көлеп-елмаеп бәхилләшү бу...

## МАЙ

Тузан кунмаган, бөҗәк тимәгән
Нәни яфраклар, нәни үләннәр!
Сабыйлар сыман гади-серлеләр,

Сабыйлар белгән телдә сөйлиләр.
Пышылдашалар:
“Пип-пип-пип-пип-пип”, -
Сары чебиләр сибелеп китәр күк.
Йөгерә сабыйлар: “Тә-тә-тә-тә!” – дип,
Уф, йөрәкләре: “леп-леп-леп-леп-леп...
Сабый дөньяда нинди бергәлек!
Олы бер уртак йөрәк тибә күк.
Уртак шатлыклар шуклыкка күчә -
Йөгерә сабыйлар туктый алмыйча.
Чирәмгә ава хәле калмыйча,
Көлә балалар, туктый алмыйча!
Ул саф авазлар һавага күчә,
Көлә табигать, туктый алмыйча!
Сабыйлар сыман чылтырап көлә!
Бу – яшәү башы, сабыйлар җирдә.
Шундый аңлашу, шундый бергәлек!
Олы бер уртак йөрәк тибә күк!

## БӘЛӘКӘЙ МАЛАЕМ ЯНЫНДА

Минем нәни малаемның
Нәни шатлыклары бар.
Нәни кайгылары да бар, -
Кем дә юк инде моң-зар!
Кайгысы да, шатлыгы да
Бар була да юк була...
Тик әнисе йөрәгенә
Һәммәсе кереп тула.
Таулар булып калка алар,
Ут һәм су кайный тауда –
Чылтырый кипмәс чишмәләр,
Сүнмәс вулканнар яна.
Һәм нәни улының нәни
Кайгы-шатлыкларыннан,
Бер минутлык елмаюы,
Бер минутлык зарыннан
Әнисенең күзләреннән
Ташкын ташырга тора,
Әнисенең күкрәгеннән
Вулкан атарга тора.

## СЕРЛЕ ЙОМГАК

Улым гомере – серле йомгак –
Тәгәрәсен булмаса!

Әй, тәгәри китте йомгак,
Серләрен ача-ача:
Көн саен бер яңа һөнәр,
Көн саен бер яңа сер.
Искеләрен оныта бара,
Ота бара яңасын.
Үзе йомгак чаклы гына,
Кодрәтенә юк чама:
Бер ачылмас йөзләрне дә
Кояш сыман итә ала!
“Шаккатырыйм, яраттырыйм,
Китсен, - дидер, - исләре”.
Башын юньләп тотмаса да,
Ул бик ушлы, исле әле!
Ушлы булсын, башлы булсын,
Без белмәсне ул белсен.
Әтисен дә, әнисен дә
Һәр җәһәттән уздырсын.
Шулай булырга да тиеш –
Шулай барабыз алга.
Тик барыбер әнисенең
Улы булсын ул бала!-
Патриотлык үз анаңа
Тугрылыктан башлана.
Әнисе улы булса да,
“Мамкин сынок” булмасын!
Яклап барлык әниләрне,
Күкрәк киереп торалсын!
Без бөртекләп туплаганны
Югалтмасын, ишәйтсен!
Без җуйганны, тапмаганны
Тапсын, сөйсен, яшәтсен!

И сүзем күп! Бер әйтермен –
Аңларсыңмы, улкаем?..
Догам да бар, әйтмәм ансын –
Аңламассың, мөгаен...
Эчтән генә укыйм аны
Баш очында көн саен:
“Улым гомере – серле йомгак –
Тәгәрә чибәр генә!
Тәгәрәп туктавын күрү
Язмасын күзләремә!..
Язмасын күзләремә”.

## БӘБКӘЛӘРЕМ ЮГАЛДЫ

Бәбкәләр югалды,
Адашты чагылда –
Нәнәйнең казларын
Саклаган чагымда.

Тапмадым таллардан,
Тапмадым керәннән.
“Бәбкәләр кыр казы
Булырга теләгән...”

Һәм алар кайтмаска
Киткәннәр чагылдан.
... Талларны кискәннәр,
Чагыллар чабылган.

Тезелеп-тезелеп
Оча кыр казлары.
Нәнәйгә иптәшкә
Бер каз да калмады.

Һәм мин дә калмадым
Нәнәйнең янында.
Адаштыммы әллә
Үзем дә чагылда?

Бәбкәләр артыннан
Ияреп киттемме?-
Киек каз язмышы
Минеке шикелле –

Җылыны читтә эзлим,
Кайтмыйм мин карарга
Чабылган чагылга,
Киселгән талларга.

Кан тарта, җан тарта
Ул якка яз гына:
Сабый чак, җил булып,
Җаннарга кагыла.

Җан тәннән аерылып
Талпына аз гына...
Аңлар бу халәтне
Тик киек каз гына.

## НӘНӘЙГӘ ХАТ

Миңа, нәнәй, һаман бер төш керә,
Ул төштән соң мин гел моңаям.
Бәп-бәләкәй, ап-ак өебезнең
Идәннәрен сагынып уянам.

Истә тотам аның һәр тактасын,
Сабый хәтер сүтелми икән!
... Ә сүтелгән идән утын икән,
Ә нәнәйсез өйгә ник идән?!

Бер, син, нәнәй, иркәләдең мине,
Бер син көйләп “бозып бетердең”.
Мин кадерле кеше булу бәхетен
Туган йортта гына кичердем.

Калган гомер гел “төзәлеп” узды –
“Төзәтүче” күп ул дөньяда...
Нигезләрен сүткәч туган йортның,
Ятим кала икән шул бала.

Сүттеләр шул инде, яктылар шул
Сабый чакның назлы бишеген.
Шунда гына җәйрәп йокладым мин,
Шунда гына рәхәт кичердем.

Калган гомер гел сагынып узды,
Сезне сагынып, сары тактала
Йокым бары сагышлы төш булды,
Төн булмады сезгә кайтмаган.

Нәнәй, Нәнәй! Туган ил ул нәрсә?
Мин исергән нинди хис белән?
Минем илем – үткән гомеремме әллә?
Исләремә төшсә, төш күрәм.
И нәнәем! Мин шул төшләремдә
Газиз булу бәхетен кичерәм.

Минем илем –
шигъри бер моңмы әллә?-
Төшләремә керсә, яшь түгәм.
И нәнәем! Ул яшь шундый кайнар!-
Җан җылыну бәхетен кичерәм.

## ЗӘҢГӘР ЧЫРШЫЛАР

“Зәңгәр”дә “зәңгәр” диләр бит,
Яшел сыман күрсәм дә!
Шаккатып йөрдем Кавказда
Зәңгәр чыршы үскәнгә.

“Зәңгәр чыршы” аллеясы!-
Мактыйлар бит – сокландым...
... Үз башым белән уйларга
Өйрәндем соңыннан мин.

Әй, яшь башым! Учлап тузан,
Учлап комнар тутырткан.
Тап алтынын, бушат комын...
Гомер күпме? Бер тотам!

Инде – зиһен, фикерләрне,
Зәвыкләрне тазарту...
Ышанмау шәм яктысына,
Көн яктысын ярату.

“Ак” дигәнне, “ак микән” дип,
Кояшка куеп карау;
Кызганмый кыска гомерне,
Көн саен туып карау,

Ләкин сабый булып түгел –
Ташка басылганны да
Карап карау, сынап карау...
Картаяммы, йә дөнья!..

Шикчел булу – ташбашлыктыр,
Вакчыл булу – картлачлык...
... Акыллы сабак алдым шул,
Мин Кавказдан кайткачтын:

Өй артында үскән икән
Шул зәңгәр чыршылар!-
Тик болар “зәңгәр” дигәнгә
Өйрәнмәгән чыршылар...-

Кемнәр белсен, кемнәр күрсен,
Сөйләп тормагач ялан!
Уфада – зәңгәр чыршылар...
Күргән саен оялам.

## ЧИТТӘ

Бигрәк татлы телле монда халык,
Бер дә юкка мактап маташа.
Их, әйтсәләр икән бер ихлас сүз,
Төчеләнми генә - татарча!

Егылмаганда кул сузалар,
Егылсам да, бәлки, килерләр.
“Авырткандыр тәне баланың”, - дип
Булмас ләкин яше түгелгән...

Ятимгә дә ятлар йомшак телле,
Тик ул онытамыни әнкәсен?!.
Безнең өчен көч һәм яшь коючы,
Төртеп екса, тартып торгызучы
Туган ил һәм әни яшәсен!

## МАРТ КОЯШЫ АСТЫНДА

Әй, җылыта кояш кышны,
Әй, балкыйлар офыклар!
“Уф, авыр!.. Тыным бетә...” – ди
Изрәп ята күпрек кар.
Авыр булса да түз инде!
Җиңеллек килер тиздән:
Арчылырсың, ачылырсың,
Бәхет түгелер синнән –
Кояш белән икегездән
Туар тәти малайлар.
Елтыр-елтыр йөгереп китәр
Гөрләвек кебек алар!
Котлап кояш малайларын,
Шук тамчылар биерләр...
Бәби туена бүләккә
Яшелләнен бөреләр.
Бәбиләргә җыр җырларга
Матур кошлар килерләр;
Елтыр күзле улларыгыз
Чылтырашып йөрерләр...
Терелтеп Җир-әбиләрен,
Яңа тормыш бирерләр!

## АСЫЛЫМА ҖИТӘ БАРАМ

- Улыгызның исеме ничек?
- Искәндәр.
- И-и, бигрәк иске исем кушкансыз икән!

Үткәннәргә “искелек” дип
Йөз чытарга ашыгылган.
“Яңа һәрчак искедән шәп”
Дип уйланган – яшь булынган...
Безнең буын, безнең гасыр –
Тарих башы дип йөрелгән.
Ә ул чиксез һәм картлыксыз:
Һәркем аңа тормыш өргән –
Сабый булып сафлык биргән.
Хәтер барсын җыеп торган:
Хәтернең тирән җиреннән
Алтын таулар китә күренеп,
Тарихтагы батырларга,
Акылларга һәйкәл кебек.
Күпме асыл затлар киткән,
Юлларына җәүһәр сибеп!
Бер бөек хәл, бер бөек эш.
Бер бөек сүз – һәр җәүһәре.
Алда микән күбрәк хикмәт,
Артта микән – белмим әле...
Белмим әле, ни бәйдер
Аңламаган әнкәй сүзе.
“Примитив” дип тыңланган сүз,
Никтер, һәрчак истә йөрде.
Истә әнкәй такмаклары –
Әйтеп, улымны биетәм.
Карап торам да әнкәйчә,
Нәкъ аныңча атлап китәм...
Якыннан карыйм әнкәйгә -
Бездә берүк караш икән!
Йөз кызартып искә төшә
Караган чак аңа өстән...
Җирдәй иске чынлыкларга
Ачыш ясап барып җитәм.
Шулай тарих акылларын
Тамчы-тамчы йота барам.
Асылыма җитә барам –
Әнкәй булып бетә барам.

# ӘНКӘЙЛӘР

Ата каз куса да ысылдап,
Йә усал кигәвен чакты исә,
Йөгердек: “Әнкәйгә әйтәм!” – дип,
Һәм әйттек түкмичә-чәчмичә.

Әнкәйсез куркыта көч юкта
Кәҗә дә, бака да, черки дә.
Күп була чәнечке, кычыткан...
Йә кулга, йә күзгә чүп керә.

Ул зур-зур малайлар дисеңме!
Үчекли күрсәтеп телләрен.
“Әнкәйгә әйтәм!” – дип кычкырсаң,
Зураеп ук китә йөрәгең.

Йөрәгең ни хәлдә соң, әнкәй?
Калгансың син хәзер бәләкәй.
Көчсезгә барысы да көчлеләр –
Чагадыр кычыткан ишеләр?

Саклауга, яклауга мохтаҗдыр –
Хәле дә чамалы, хәтере дә.
Җитәкләп йөртсәң дә, тамандыр,
Ярамый тик алай әйтергә -

Үпкәчел баладай еларга
Керфектә күз яше гел әзер.
Юкка да кайгыра, куана,
Көчсез дә, көйсез дә шул хәзер...

Һәм эче – тышында, тик елый
Яшерен, күрмәсен дип халык.
“Балама әйтәм!” – дип янамый
Һәм килми: “Син мине якла!” – дип.

Ә кайтып егылсаң чарасыз,
Теш кысып гөнаһың кичерә.
“Рәнҗешем төшмәсен!” – дип тели
Шәфкатьлем, хәсрәтлем, кечкенәм...

... Кайчандыр көчле иде әнкәйләр,
Әнкәйләр һаман да көчлеләр.

## ГОМЕРЕН НИЧЕК ЯКСА КЕШЕ...

Сүнми дә сүрелми кояш,
Сүрелмәс тә, сүнмәс тә.
Балкыр кояш, бар дөньяда
Барлык утлар сүнгәч тә.
Бар хәрәкәт тукталса да,
Вакыт тукталмас һаман.
Чабар вакыт, янар вакыт,
Һәм һаман кояш янар!
Вакыт яна – кояш булып,
Гомерләр, чорлар яна!
И табигать балалары! –
Шул кояшка куана...
Кояш нурын күбрәк сипсә,
Шатланабыз тагын да;
Ә бит иң гүзәл гомергә
Иң зур ялкын кабына!..
Үзебез янган утларда
Үзебез назланабыз –
Нинди зур оптимистлар без,
Нинди сабыр бала без...
Сүнәбез гомерне ягып,
Рәнҗемибез дөньяга.
Без китсәк тә, кояш калсын –
Канәгатьбез шуңа да.
Ялкынланып кайныйк әле,
Чагылсын кояш күзе!
“Бу кемнәр гомере яна?” – дип
Эзләсен кояш безне.
... Вакытмы яна, гомерме?-
Хәер, андамыни эш!
Мәңгелек Кояш-вакытта
Безгә - Кояш-гомер ич!
Гомерең ничек акса кеше,
Шулай яшәргә тиеш.

## УТЫЗ ИКЕДӘ

Аз гомер юраган әүлия,
Шуңа бик ашыккан Искәндәр![1]
Җир гизеп җир читен табарга
Гомерлек яу чыккан Искәндәр.
Гомер аз – утыздан чак өстә,

[1] *Искәндәр* – монда: Александр Македонский.

Максат зур, юл озын, яу каты.
Җан кыю, кан кою, кол җыю...
(Бу түгел, юкса, чын максаты!)-
Җир чите, җир чите, кайда ул?
Ул чиктән нәрсәләр күренә?
Кочарга, учларга бу җирне!
Һәр сернең төшәргә төбенә!
Ул кергән илләргә зур булып,
Хур булып качмаган яулардан,
Абсолют биеклек эзли ул!-
Нәрсә кан һәм нәрсә яралар!
Күпме уй, күпме дәрт, күпме эш!
Җитәрме,
                җитәрме гомере тик?
... Әкренләп – икеләнү, шикләнү...
Кайда син, кайда син,
Абсолют дөреслек?!
Утыз ике яшь җитә.
                                Искәндәр
Сүрелә, моңая, боега.
Җан хәзер гәүдәдән аерыла –
Абсолют дөреслек шул гына...
Менә шул. Ап-ачык. Нигәдер
Бүгеннән ачыграк үткәннәр.
Белгән аз, белмәгән никадәр!
Җир читен эзләмим, шулай да
Аңлыйм бит мин сине, Искәндәр!
Абсолют дөреслек булмавы
Миңа да газаплы, күңелсез.
Чынлыкның асылы, яшәүнең
Башы һәм азагы билгесез.
Ашкынам төбенә төшәргә,
Тик төпсез, билгесез ул диңгез!..
Уйларым очсыз да кырыйсыз,
Көннәрем, төннәрем тынгысыз.
Миңа да вак-төяк тоела
Һәр көнне яуланган бу үрләр.
Абсолют, абсолют җиңүгә
Ярсынып талпына күңелләр!
Теләкләр һәм дәртләр беткәнче
Бетмәс күк, бетмәс күк гомерләр...
Уйларның, эшләрнең очына
Чыгыйм дип йөгерәм, йөгерәм!
Чыгармын шикелле... Искәндәр:
“Юләр!” – дип көләчәк, мин беләм...
Утыз ике яшь миңа. “Бетә!”- дип

Әйтмәде бит әле әүлиям!

## ЙОРТ КАЗЛАРЫ ТУРЫНДА

Очып китте йорт казлары:
- Кайталмасак, хуш! – диеп.
Тезелгән булганнар әле:
- Без дә күчмә кош! – диеп...

“Юньләп очмый, юньләп йөзми,
Юньләп йөри дә белми...” –
Йорт казлары! Сездән шулай
Нинди генә кош көлми!

Кыр казларын күрдегез дә,
Онытылдымы гасырлар?
Сез бит хәзер – ит кошлары,
Бозылган бит нәселләр...

Чынлыкка бер каһкаһәме,
Язмышка бер үч микән?-
Гаң-гаң килеп казлар тузды!
Нинди серле көч икән?

Һаваларда казлар моңы –
Тугрылыкка мәдхия!
Калган казлар җиргә баккан –
Уйга батканнар гүя...

Күземдә яшь, күңелемдә җыр.
Рәхмәт! Хуш, ак казларым!
Юк иде каз сагышына
Кушылып җырлаганым!...

## БЕЛДЕМ

Дустым китте, дустым китте бу дөньядан,
Киткәч, кайтулар юк терелеп.
Хәер, аңа инде барыбердер...
“Бәлки, түгелдер?” – ди бер өмет:

Ничек сүнсен безгә шундый кирәк,
Шундый зирәк, кыю, тирән аң!
Ничек сүнсен бездә шундый сирәк
Изге теләк белән туган җан!

Сүнсә, миңа ак юл юраучылар
Калмый да бит инде дөньяда!..
Кемгә барыйм, гаделлекне юллап,
Шундый чакта нигә юк Алла?!

Аның җанын, аңын ничек яклыйм
Ышанмаган Аллам алдында?
... Аңа күктән гүзәл дөнья сорап,
Бер өметем егылып ялына!..

Мин, сагынып саргайсам да, риза,
Кайтмаса да риза, терелеп.
"Ышанмаганнарың чын булсын, - ди,-
Син гөнаһлы бул!" – ди бер өмет.

Булсын гына! Аңа рәхәт булсын!
Мин тамугка риза, димен бит...
Әй дускаем, сиңа оҗмах сорап
Елау хәсрәтләрен күрдем бит!

Аллаларның, оҗмах, тәмугларның
Каян чыкканнарын белдем бит:
Барысын да шагыйрь иҗат иткән,
Дустын югалткачтын минем күк...

***

Тәрәз ачып куйыйк әле
Һәм ачыйк ишекләрне,
Тынычлыкны куыйк әле,
Шакшыны, шом-шикләрне!
Салкын сафлык тулсын әле,
Томау төшсә, ни бәлә!
Ах, ник томаудан куркасыз?!
Мин ялварам җилләргә:
Ачыгыз сез ишекләрне,
Читлекләрне ачыгыз,
Ачыгыз битлекләрне дә,
Бикләрне дә ватыгыз!
Тән тазарсын, җан тазарсын,
Иркенәйсен сулышлар!
Җанга мунча юк, ди шагыйрь,
Ышанмаска тырышам.
Тормыш - тузанлы сәхнә, ди...
Тик чын йөзен кешенең
Басмасын тузан, басмасын

Чын йөзен, чын исемен!
Исегез, җилләр, исегез,
Тузанны тазартыгыз!
Ачыгыз да чын йөзләрне
Битлекләрне ертыгыз!
Киңәйсеннәр бу күкрәкләр,
Чистарсыннар бу миләр.
Таза тәндә - таза җан, ди,-
Киңәйсеннәр күңелләр!
Бит “һау-уа” дип, сөрән салып,
Килә кеше дөньяга.
Тынчуга күнекмик әле
Җилләр уйнап торганда,
“һа-у-уа” диеп, сөрән салып,
Бала-чага туганда!
Чын йөзе, саф күңеле белән
Килә кеше дөньяга;
Чын сүзләр сөйләргә килә
Һәм саф һава суларга.
Иссеннәр хуш исле җилләр!-
Тәрәз ачыйк шуларга.

## ШӘҺӘРДӘ АТ

Чана вакыты димиләр,
Тәгәрмәчләр йөриләр.
Тыңласаң, котың чыгарлык –
Үкерәләр, гүлиләр.
Карасаң, өркеп качарлык –
Машина да машина...
Артта, алда, уңда, сулда –
Бар да чаба, бар да ашыга.
Ә ул тыңлап тормады,
Тормады каранып та;
Хафаланмады юлында
Чанага карлар юкка.
(Монда чана юллары да
Ташлы асфальтлар икән...)
Кайсы авылның күк аты бу?-
Чәчәкле чана җиккән!
Курыкмады, өрекмәде,
Горур тотып башкаен,
Тоякларын чат-чот итеп,
Чатнатып юл ташларын,
Чабып үтте малкаем!
Башын иеп калды аңа

Юл читендә карт каен:
Исләренә төшергәндер
Аландагы чакларын...
Шәһәрнең бөтен ташлары
Шаккатып карап калды!
Чәчәкле чана артыннан
Күземнең яшьләре тамды...

***

Карлар яуган каеныма,
Калын бозлар камаган...
Кем үзгәрмәс авырлыктан!-
Танырлыгы калмаган.

Көч табып бер кагын, каен,
Авырлыктан арын бер!
Минем менә көчем дә юк,
Мин шулкадәр арыдым...
Селкеп сал да боз-кайгыңны,
Яшь һәм сылу бул тагын!
Хәтерләт кыю чагымны –
Кагын инде, йә, кагын!
Язмышымны хәл итәм бит,
Бар өмет синдә, каен.

***

“Кычкырыр ла кәккүк, сайрар былбыл,
Шул чакларда ничек түзәрсең?” –
Дип җырлаган идек заманында,
Бергә чакта булган, күрәсең...

Май айлары үттемени инде,
Сайрамыйсың нигә, сандугач?
Сакауландыңмыни, моңлы кәккүк,
Кем елатыр инде сагынгач?

Кайда икән дуслар-ахирәтләр,
Кан кардәшләр, агай-сеңелләр?
Әй, сөекле, җанга якын затлар!
Кемнәрегез кай сибелгән?..

Мин идем бит сезгә хатлар язып,
Яшь башымнан авыр сулаучы.

Сагынуларым сыяр җыр тапмыйча,
Үзем утырып шигырь уйлаучы.

Тауга менеп, ташка басып карап
Йөрүче мин идем, сердәшләр!
... Хәзер инде тауга менгәнем юк, -
Сез белмисез, беләдер ташлар.

Сез белмисез. Хәер, үзегез дә
Менгәнегез юктыр шул анда.
Күңелләрем әллә ачылыр иде,
Сагыну хәбәрегез булганда.
Йөрәкләрдән каннар саркыса да,
Ачмыйм хәзер, әй, ахирәтләр.
Кан оешса әгәр йөрәкләргә,
Таш булалар микән йөрәкләр?..

Ташлар да бит җилгә сибелеп бетә,
Сибелергә иде җилләргә!
Сагынырга иде өзелеп-өзелеп,
Күрмәмме дип, тауга менәргә!
Сагынулар сыяр җыр тапмыйча
Төннәр буе яшьләр түгәргә!
Йомшак күңел – якты кояш бит ул,
Каты күңел – кара күләгә.
Сагынып түзү – рәхәт газап бит ул,
Сагынусыз ничек түзәргә!

“Кычкырыр да кәккүк, сайрар былбыл,
Шул чакларда ничек түзәрсең?”
Сандугачлар тынган, кәккүк сакау,
Гөр-гөр килеп йөри күгәрчен...

## ӨЛЕШЕМӘ ТИГӘН КӨМЕШЕМ

Кем икәнен кемнең сорыйсы юк,
Маңгайларга язып эленгән.
Кайберәүләр никтер маңгай каплап,-
Үзләреннән качып йөриләр!
Нинди каннан, кайсы туфраклардан
Яраланганын онытып китәләр.
Танымыйча затлы почмакларда,
Аналарын үтеп китәләр.
Ә мин ачып йөрим маңгаемны –
Кем икәне күренеп торсын ла!
Дөньяның бик ару җирендә дә

Калынган юк әле ким-хурга!
Дөньяның иң нурлы җирләрендә
Безнең күз нуры да төшәрлек.
Дөньяның иң нурлы җирләрендә
Җырыбыз бар җырлап үтәрлек.
Шуңа “Кем?” дигәндә “Без” дип торам
Һәм акларга торам исемне.
Бар кардәшкә уртак исем өчен
Мин җаваплы тоям үземне.
Аннан шәфкать күрсәм, җан җылына,
Ул түбәнлек кылса, өши җан.
Җанымда да – маңгайдагы мөһер,
Җаным белән бергә тик чыгар.
Җан тартадыр, кан тартадыр инде,
Әллә искечерәк – кадим мин...
Дөньяның иң шаулы җирләрендә
Үз туганнарымны таныйм мин.
Дөньяның иң затлы җирендә дә
Туганнардан затлы табылмас –
Иман нуры балкый йөзләрендә,
Телләрендә сайрый сандугач!
Ник танымыйм мин шул сандугачны!
Ник яшерим алтын-көмешем?!
Өлешемә тигән көмешемне
Бөтен дөнья белән бүлешим!
Тик бар дөнья йөзен чөерсә дә,
Көмешемнән мин баш тартмамын...
Күз яшедәй газиз бөртекләрне
Күзләремә салып саклармын.

## ВАТЫК КӨЗГЕӘ КАРАСАҢ...

Уйный кояш нурларында
Алтын комлы елгалар.
Ватык көзге кулларымда,
Йөзләрендә нурлар бар.
Алтынлы сулар күрсәтә
Тылсымлы ватык көзгем.
Ул шатлыклы сүрәтләрне
Мин кайтып-кайтып эзлим.

Ватык көзгегә карасан,
Бәхетсез буласың, ди.
Мине сөендергән көзге
Ни хәсрәт юрасын ди!..

Бәхесезлегем дәрьясы
Алтын чагымда калган.
Карасам серле көзгемә,
Мин чумам шунда һаман.
Дулкын-дулкын моңлы караш
Тирбәлә ул елгада,
Тирбәлә онтылмас тавыш,
Аерылу җыры ага.
Сары сагыш бөртекләре
Алтын булган ул суда.
Аларны барлау бәхете
Ләззәтле дә, моңсу да.
Яшьлек кичәм, сафлык эчәм, -
Җандай газиз бу хиснең
Башка һичбер дәрьяларда
Юклыгын беләм ич мин.
Мәхәббәтем дәрьясы бу!
Югалма, ватык көзгем!
Бәхетсезлек дәрьясыннан
Бөртекләп бәхет эзлим.

## ЮЛ ТИК АЛГА

Үз өендә үз күзләрең
Ишек тапмый йөри.
Киләчәккә киткән уйлар
Кайта, юлны белми.
Яңа ишек тишәр идең,
Эшең төшә кулдан...
Эш тә юк, үкенеч тә юк
Һәм көч тә юк сыман...
Күңел сүрелү халәтен
Кемнәр кичермәгән!
...Бәхетленең үткәннәргә
Юлы киселмәгән.
Анда аның эчәр суы,
Ашар икмәге бар.
Сагныр көннәр, сыеныр куллар,
Аh! дип көткәне бар.
Зарын онытып, ул бәхетле
Хыял көймәсендә
Үткәннәргә кайтып егылыр,
Йөзеп күз яшендә.

Мин бәхетсез: үткәннәрдә
Сыеныр почмагым юк.

Кире кайтып кайтарырлык
Сулар эчкәнем юк.
Юл тик алга! Юл башларга
Сагнып искә алырлык.
Үзең үткән адымнарга
Үзең сокланырлык!

## СӨЙГӘНЕМНЕ КҮРГӘН КЕБЕК

Быелгыдай ук алгысап
Яз көткәнем юк иде.
Ах, ниһаять, күкне тишеп,
Иркә нурлар сузылды!
Сөйгәнемне күргән кебек,
Шул нурларга шатландым!..
Ташландым тик күңелем белән,
Тик күзләрем яшьләнде.
Кыймадым кочып алырга
Һәм шаулап шатланырга.
Шауласам, куркыр күк шатлык...
Инде, кыш, кайтма гына!
Инде булыр бу минуттан
Бары бәйрәм, бары яз!
Бары яшьлек! Кышлар миңа,
Еллар миңа кагылмас.
Җанда булыр гел җылылык,
Гел тынгылык һәм гел җыр.
Шушы көнне күргәч инде,
Җәл түгел үткән гомер!

Сөйгәнемне таптым гүя...
Назымны тыеп торам.
Күзем чагыла, йомып торам –
Ачсам, күз тиеп куяр...
Әй, язлар, назлар килгәндә,
Шушы тыелуларым!
Күз тиярлек бәхетләргә
Күз йомып калуларым...

## КАБАТЛАНЫР ӘЛЕ

Киттеңме, көз, кире алып
Уйларыңны, зарларыңны?
Белмәдеңме мин аларны
Җырлый алмый калганымны?

Шатлык катыш моңнан иде
Көзнең салкын йөзләрендә.
Тантаналы җыр бар иде
Җил-давыллы көз зарында!
Аңламадым шул серләрне,
Берәр аңлап буламы инде?
Берәр уйлап бетәрменме
Көз тудырган уйларымны?..

Ә көз кире алып китте
Китергән бер хәзинәсен.
Беләдер ул берәр заман
Аңа хуҗа табыласын.
Тагын төяп килер әле
Йөз елданмы, мең елданмы
Шул шатлыклы сагышларны,
Тантаналы шул моңнарны!..

Уйланлыр әле алар,
Аңланыр да, җырланыр да.
... Аңлашылмас бер сер булып
Кайтылыр да шул ук җиргә...
“Мин югалткан җыр бит син!”-дип
Үксер кемдер, сарылып җырга...

## АЛТЫН БАЛЫК

Әкияттә генә бит – чын
Алтын балык.
Нигә көтәм аны һәркөн
Кармак салып?

Һаман гади балык кулда,
Корбан ише...
... Тезелеп-тезелеп көннәр уза
Кәрван төсле.

Мин аларны сагынмыйм да,
Кызганмыйм да.
Алтын балык кына уйда,
Күз алдымда!

Тирән сулар тарта серле
Хикмәт төсле.
Бер хикмәтле мизгел мине
Көтә төсле.

... Бар гомернең хикмәтеме
Алтын балык?
Морадыңа җиткән көнме
Алтын балык?

Бер гомердә хикмәтле көн
Бер генә бит –
Ник шуны да күпсенәсең
Инде, балык?

... Елгаларда йолдыз уйный
Ялтырланып. –
Алдавычың әллә шулмы,
Алтын балык?
Гомерләрне тотасыңмы
Кармак салып?..

***

Борыч төям – азиаттыр,
Азиаттыр ахры мин.
Борыч сөям – ачыРактыр,
АчыРактыр ахры мин.
Борыч сибәм – яратканнар,
Яратканнар ашасын!
Борыч сибәм – яратмаган,
Яратмаган чәчәсен!
Ачы сүзнең, хаклы сүзнең
Кадерен белгән яшәсен!
Борыч төям – аңы барлар,
Аңы барлар аңларлар.
Борыч сибәм. Аңлаганга,
Аңлаганга бал да бар!
Балым яшерен, тел төбемдә,
Тел төбемдә балларым.
Тел очыннан һәр сүз саен
Бал сибүне аңламыйм.
Ачы сүзгә оста телем
Татлы сүзгә әйләнми.
Борыч сибәм... Үземне дә
Аңлый алмыйм әллә ни...

## ЯЗ КҮРҮ

Калайларда сәйлән йөгерә -
Карлар эри.

Күңелләрдә сыечыклар
Очынып йөри.
Кояш көлә тыйнак кына.
Үбеп куя тау битләрен
Уйнап кына.
Күк болытлар чилтәр төсле,
Челтәр төсле.
Челтәргә төренеп килгән яз
Китәр төсле...
Әй, гомерләр!-Бер язгына,
Уен гына...
Язлар килсә - уйлар төшә ,
Кыен була...
Тик сер сөйли тау битендә
Умырзая:
- Бер яз күрдем – булды димим
Гомер зая!
Бер яз күрдем!

## СИН ГАРМУНЧЫ БУЛСЫН ӨЧЕН...

Их, сыздырасың, гармунчы!
Мин дә сыздырам сыман:
Ун бармагым биеп тора,
Бөгеләм дә сыгылам.

Гармуныңны мин алсам да,
Уйнап җибәрер кебек.
Бир әле! Сузып карыйм бер!-
Булыйм гармунчы егет!

Юк, шул... Синең гармуннарың
Синдәгенә әйттерә.
Миңа да дарман бирмәгән шул,
Биргәне бар дәрт кенә...

Ә шулай да син, берүзем
Уйныйм, диеп уйлама –
Миңа дигән дарманны да
Биргән синең кулларга!

Ун бармагым биеп тора,
Бөгеләм дә сыгылам.
Син гармунчы булсын өчен,
Мин шулай хисле туган.

Минем дәртем-хисләрем дә
Гармуннарыңа тулган.
Их! Сыздырасың, гармунчы!
Мин дә сыздырам сыман...

***

Җанга кардәш кирәк –
Бар кайгыны юк итәргә.
Канатларны канатларга куеп,
Юл үтәргә.

Җанга кардәш кирәк –
Юк шатлыкны бар итәргә.
Канатларны канатларга салып
Ял итәргә.

Җанга кардәш кирәк –
Ярты рухны бер итәргә.
Канатлардан канат аерылса,
Җыр итәргә.

***

Сергә төренеп, нурга коенып,
Сихри көннәр килделәр.
Көйгә салсаң,
                җыр булырлык
Шигъри көннәр килделәр.
Аералмыйм бу көннәрдә
Вакыт белән вакытны:
Үткән белән бүгенгене,
Яшьлек белән картлыкны.
Күптәнгечә очып йөрим –
Элеккеге төш керә.
Дөньялардан күптәнгечә
Нечкә татлы ис килә!
Үткәннәрдән көмеш тама –
Тамчы-тамчы ис килә...

И нәфис хис! Атыйм сине
Бары “шигъри” дип кенә.
Аңлаталмыйм – сүзләр җитмәс,
Җырламыйм – көн табылмас.
Синең көең – күптәнгечә -
Тагы яшьлек, тагы яз!

Күптән йоклаган бөрене
Уята ул күңелдә.
... Үткән гомер кала икән
Әверелеп шигырьгә.
Яз саен бер: шул шигырьдер
Тамчы-тамчы түгелә...

## АК ТАУ ҺӘМ МӨХӘММӘТ

Әйтә идең:
“Мин – Мөхәммәт, син – тау,
Тау килмәсә, килер Мөхәммәт...”
Ә калдыргач җилдә-яңгырларда,
Тау да ватыла ич, ниһаять...

Боз тауларым эреп кибәр иде,
Таудай учак яксаң, Мөхәммәт!
Тик учагың бигрәк түбән иде –
Сүрән иде синең мәхәббәт...

Боз тауларда тунганымны белә:
Киләм диде, килер Мөхәммәт.
Тауны эзләр – анда салкын үзән...
...Әллә ничек икән бу хәят!

## МӘҢГЕ КОШСЫЗ...

Ут каурыйлы карлыгачны
Күрмәдеңме, илче җил?
Калды микән? Алда микән?
Ансыз җансыз, өнсез мин!..
Арып дәрьяларга төшә
Кушканатлы кошлар да...
Мәхәббәткә канат үсә,
Таш яуса да очарга!
Кыялардан атылып бер көн,
Җан бирәләр бөркетләр –
“Тау купса да, мәхәббәтем, -
Үлмәм!” – дип сүз беркеткән...
Бәреләдер диңгезләргә,
Сугыладыр җирләргә...
Көтәм. Кайтмый – Якты кошым
Китте сине эзләргә!..
Бер китсә, югалта, диләр,
Мәхәббәт кайтыр юлны.
Юлдашы син булсаң гына,

Табар, ахры, ул мине.
Бәреләдер кыяларга,
Сугыладыр җирләргә...
...Адаштырдың кошкаемны!
Мәңге кошсыз йөр, әйдә!

## МИН КАЛЫРМЫН КӨЧСЕЗ

Син килмисең. Җиргә томан ябам –
Томаннарга күмелеп килсен дип.
Аннан куа башлыйм томаннарны –
Адашмасын, юлны күрсен дип.
Син килмисең... Куам яктылыкны –
Күрмәсен дип синең килгәнне.
Ай балкытам, күккә йолдыз сибәм!
Аннан куа башлыйм төннәрне...
Таң аттырам, таудан нурлар сузып,
Һәм җибәрәм сиңа җилләрне.
Мин – сихерче: миңа хезмәт итә
Мәхәббәтнең гүзәл җеннәре!
Килмәс булсаң, җеннәр ташлап китәр,
Мин калырмын – көчсез бер пәри...
Кояш чыкмас.
Янмас йолдызлар да...-
...Шундый хәтәр уйлар килгәли.

## МӘХӘББӘТ ҖИЛӘГЕ

Хисләр чәчәк аткан болын
Чакыра, кичләр килсә.
Шул чәчәкләргә уралып,
Тылсымлы җиләк пешә!
Эзләми дә табам аны
Иксез-чиксез аланнан.
Бәхет көтеп бөгелгән ул,
Алсыннар дип алланган...
Яратудай татлы микән?
Алданудай ачымы?-
Ничә еллар!- белә алмыйм,
Төн пышылдый: “Ал шуны!”
Тик һичкем өзеп бирәлми –
Яшерә төн – юк җиләк!
Ал, дисең дә алдыйсың, төн,-
Хыянәтче син бигерәк...
Ә көн белә, ә көн белә:
Берәү китте сихерләп.

Өзәргә бәхет җиләген
Сихерче үзе кирәк...

## СИННӘН БАШКА

***

Синнән башка үткән тиле көннәр
Тиле төннәремнең дәвамы:
Төн буена төштә сине күрдем,
Көндез йолдыз күрәм аннары.

***

Ике-чиге бер күренер микән
Синсез үткән озын көннәрнең?
Мәңгелек тә шулай чиксез булса,
Юк, мин мәңгелекне теләмим!

***

Җәйге таңда хәтәр кырау суга
Сине көтеп үткән һәр көнем.
Кырау – аязга ул, күрешербез.
Ничек безгә гөлләр җәл түгел?
Кыра кырау яшьлек бакчаларын,
Елап эзләрбез бит һәр гөлен!
Кырау – аязга ул, күрешербез,
Ничек безгә яшьлек җәл түгел?

## ДУСТЫМ БУЛСАҢ

Җиргә төшер мине, яшел җиргә,
Зәңгәр күкләр шундый салкыннар!
Шәфкать чәчеп җирдә кояш көлә,
Һәм шат йөзле анда хатыннар.

Күм син мине кайнар нурлар белән,
Яңгырдан һәм җирдән арала.
Ай-йолдызлы, бозлы уйларымнан
Чирле башкаемны дәвала.

Эзләү-тапмау, уйлау һәм аңламау,
Янып җылыналмау газабы...-
Син шулардан яулап ал әле!

Күге сүнгән, канатлары талган,
Оялары аның ватылган...
Шул кошчыкны коткар афәтләрдән,

Җылы кулларыңа тартып ал!

## СУКЫРЛЫК

Янам, янам! Түзмәм беркөн
Чәчеңә кабынырмын.
Тезләреңә сарылырмын,
Җаныңа кагылырмын.
Минем күңел күзләремне
Күзләрең күрер кебек –
Бу гөнаһлы хисләремне
Аклар көн килер кебек.
Өндә карыйм, төштә карыйм,
Белмим күзеңнең төсен:
Мин сукырмын – сине күрмим...
Син дә мине күрмисең.
Карашыңнан күз чагыла!-
Гашыйк хәле шушыдыр.
Мин мәхәббәттән сукырмын,
Син нәрсәдән сукырдыр?..

## БЕЗ ШУНДЫЙ ЕРАК

Сез миңа охшамагансыз,
Без шундый-шундый ерак.
Безнең як – ут, сезнең як – боз,
Арада – минем йөрәк.
Боздан ялкын эзләп бара –
Йөрәк ул шундыерак...
    Мин сезгә охшамаганмын,
    Бәлки, ошамам да әле...
    Әйтче, дөнья, утны бозга
    Ничек кушалар әле?
    Утлы бозлар була диеп
    Мин бит ышанам әле.
Мин сезгә охшамаганмын.
Ошамам да, ахрысы...
Йөрәгемнең яртысы ут,
Ләкин боз шул яртысы.
Бозга басып өмет йөри –
Бозда җылы бар төсле.
    Сез миңа охшамагансыз,
    Сез миңа бик ошыйсыз!-
    Бозларны ут итәр өчен
    Җитмимени шушы сүз!

## САГЫНГАНДА

Җаныем, җаныем, җанашым,
Бик кирәксең, кайдасың?..
Син генә баса аласың
Сынган бәхет ярасын.
Җаныем, җаныем, җанашым,
Ашык – соңга каласың!
Сынса сагыну канатларым,
Басалмассың ярасын.
Җаныем, җаныем, җанашым,
Сындыр сабыр канатың!
Сабыр төбе – алтын түгел, -
Каер! Кагыналмасын!
Сабыр төбе – салкын боз ул,
Сүнсәң кабыналмассың...
Үзем сиңа алтын булыйм,
Ялкын булыйм, җанашым!
Җаныем, җаныем, җанашым,
Сызлый сөю канатым,
Сынса сөю канатларым,
Куялмассың яңасын!

## СИН КИТКӘЧ

Яшел урманнар төссез калдылар,
Сайрар кошлар да өнсез калдылар.

Зәңгәр һавалар кояшсыз калды,
Күзләрем минем күз яшьсез калды.

Таң җилләре дә җиләссез калды,
Айлы кичләр дә кирәксез калды.

Утлы яшен дә кодрәтсез калды –
Гәүдәм бит инде йөрәксез калды...

Кояшым китте күңлендә синең,
Сайрар кошларым – сүзендә синең,
Якты яшеннәр – күзеңдә синең...

Йөрәгем китте кулыңда синең,
Уйларым ага юлыңда синең.
Ә киттемме мин уеңда синең?..

## ИСКЕ ҖЫРНЫҢ ЯҢАРУЫ

Яшел фонтан яктысында
Көзге төндә
Син җырладың озын чәчле
Кыз турында:
“Үксим, - дидең, - үлдең, - дидең,
Матур ярым!”
Иңрәделәр гитараның
Бар кыллары...

Яшел фонтан яктысында
Көзге төндә
Озын чәчле бер кыз идем
Мин үзем дә.
Алда күпме яңа-яңа
Язлар иде!
...Бер-беребезне онытырга
Язган иде...

... Ә син һаман да тугрысың
Үз җырыңа:
Җырлыйсың син күз күрмәгән
Кыз турында.
“Үксим, - дисең, - үлдең, матур
Ярым”, - дисең...
Күз алдыңа килгән кызны
Танымыйсың.

ОнытКансың.  Таный мине
Тик гитара.
Иске җырны яңартучы –
Мин бит бары.
Язган миңа язмышыңнан
Югалырга,
Тик калырга гитараңның
Кылларында.

Кара төндә яшел фонтан
Нурланганда,
Озын чәчле кыз турында
Җыр яңара.
Җыр югалмый. Язмышларга
Үрелә бара.
Язмышны җырны кабатлый да,
Җыр яңара.

Җыр яңара.

## МӘХӘББӘТ ҺӘМ МӘКЕР

Чирлә инде, чирлә инде
Үлем чирләре белән!
Һәм әйт соңгы теләгеңне:
“Үлим сөйгәнем белән”.

Чакырырлар – килермен дә
Йөрәгеңне ачармын.
Йөрәгемнән йөрәгеңә
Тамуг уты чәчәрмен.

Син үләрсең! Мин шатлыктан
Елый-елый көләрмен!
Йөрәгеңне үбәрмен дә
Күз яшьләрем сибәрмен...-

Терелтермен! Һәм әйтермен:
“Үтердем дә коткардым!
Күз яшем тамган йөрәккә
Хуҗа булып мин калдым!

Ай-йолдызлар, хатын-кызлар –
Бөтен күзләр! Белегез:
Мин җан керттем йөзләренә -
Карамагыз берегез!...”

Чирләсәнә, чирләсәнә
Үлем чирләре белән.
Терелмәсәң, үлим әйдә!
Үлим сөйгәнем белән!

***

Бездә яз бит. Ярдан чыкты ташу,
Актарылдым синең каршыңа.
Сездә җирләр бигрәк туң икән шул,
Юк икән шул сыңар тамчы да...
Ах, боз булдым!
Ап-ак бозлар булдым!
Эресәм дә, инде ташымам...

## МӘХӘББӘТЕМ

Мәхәббәтем, кичер мине
Күз яшьләрем кипкән өчен.
Синең авыр сынавыңны
Тапшырмыйча киткән өчен...
Сикәлтәле юлларыңны
Читләп кенә үткән өчен.
Синең өчен көрәшмичә,
Җиңү генә көткән өчен.

“Сүнмәс” дигән ялкынларым
Инде кабынмаган өчен.
“Сагынырмын” дигән ярым
Мине сагынмаган өчен...

Кичер мине очар күңелем
Канат кагалмаган өчен. –
Канат асларында сине
Саклап калалмаган өчен.

Гаепләмә мин көчсезне.
Үпкәләмә. Килеп йөре.
... Юк, мәхәббәт кичермидер,
Кичерсә, бер килер иде...

## ИСӘН КАЛЫЙМ ӘЛЕ

Көн туганда туам, күзләремнән
Нурлар чәчеп, кояш шикелле.
Сине күрер өчен киләм җиргә,
Әйтер өчен синең исемеңне.

Көннәр буе күз нурларым түгеп
Эзлим сине меңнәр эченнән.
Табалмагач – сүнә күз нурларым,
Күрәлмәгәч – үләм кич белән...

Төшләремдә әйтәм исемеңне,
Төшләремдә күрәм төсеңне –
Күзләремә тагын кайта нурлар,
Туам таңда, кояш шикелле!

Тууларым – татлы хыял гына...
Үлем газапларын - кичерәм.
Ах, җаныем, туыйм да бер таңда,

Исән калыйм әле кич белән!

## КӨЗ ҺӘМ РОЗАЛАР

Бар сукмаклар – кат-кат сары келәм,
Без йөргән төш кенә - җәйләрдә:
Ак розалар монда! Ах, розалар!

Бу кич – диңгез, бу төш – серле утрау.
Исерт әле мине хуш искә!
Бу кич шундый мохтаҗ гашыйкларга,
Бу кыз шундый мохтаҗ чын хискә!

Зәңгәр томан – күкләр җиргә иңгән.
Сары түгел, зәңгәр ич көзләр!
Роза өздек, тагын роза өздек!
... Ә розалар көзен иссезләр.

Җитәкләшеп кердек бакчаларга,
Җитәкләшеп аннан чыкмадык.
Серле утрау батты диңгезенә -
Без бит аңа ялган сер салдык.

Розаларга, хис булганнан түгел,
Гөл булганга сокландык.
Төссез калды алар, иссез калды,
Сокланмасын, диптер, хиссезләр.
Исермәкче идем, исермәкче...
Розаларың, дустым, иссезләр.
Томан беткән –
күк бит җирдән киткән!
Сары төстән... чатный бит күзләр!..

## ЯРАТУЛАРЫН КӨТӘМ

“Булса җырны тыңлыйм, - дисең,
Ә булмаса, сагынмыйм”.
Мине сагынгарыңны
Алдану дип саныйм мин.

Дөрес, үзем җыр да түгел
Һәм шигырь дә түгелмен.
Тик аларсыз мин – мин түгел,
Бүтән булыр идем мин.

Син бүтәнне сөясеңдер.

Ә мин үземне күптән
Җыр итеп һәм шигырь итеп
Яратуларын көтәм.

***

Күңелләрең синең яктырсын дип,
Күпме түктем күз нурларын!
Ачылмады күңел тәрәзәләрең,
Кара төнгә китеп югалдың.
Күңелләрең синең йомшасын дип,
Җиргә йомшак карлар юлладым.
Карларымны кара таптау итеп,
Бозлыкларга китеп югалдың.
Күңелләрең синең агарсын дип,
Ак бураннар булып уралдым.
Бураннардан китеп, ышыклыкка –
Карурманга кереп югалдың...

Югалдың да минем көннәремә
Салкын соры томан чорнадың.
Кояш төшми, үтми анда җил дә, -
Үзек синең томаның...
Шундый шомлы, авыр ул томанда!
Уяныргa куркам, таң атса.
Көтмим инде, көтмим – син югалган,
Ах, томаның тизрәк таралса!...

## КОЛ ҺӘМ ПАТША

Минем биләмләремдә
Кол бул әле!
Боерсам – нур, йә боерсам –
Гөл бул әле.
Минем алда йомшак кына
Басып йөр син.
Баш и! Тезлән! Ләкин берүк
Патша бул син.
“Ах, ханбикәм!” – дигән бул да
Зур ит мине,
“Баш өсте!” – дип, гөл ит мине,
Нур ит мине...
Алларыңда йомшак басып
Йөрет мине.
Көчең түгел, хисең белән
Кол ит мине.

## МИНЕМ ҖӘЙ

Кыска күлмәкле
Бер шаян иде.
Күлмәкләр озын!
Ул кайда инде?
Хыялый иде.
Хыялда инде!
Алда вакытта,
Янда вакытта
Булмады җәйне
Танып калып та!..
Назын-шифасын
Файдаланып та,
Тунмаслык итеп
Янып калып та.

Юк! Миндә җәйнең
Ярсу чаклары,
Күкләр күкрәве,
Яшен ташлары!

Юк! Көн дә килә
Җәйнең хатлары.
Хатлары саен –
Серле әлифба...

... Ә син, көз миннән
Көләсең юкка!-
“Андый әлифба
Буламыни!..” – дип,
“Күргәнең дә юк
Син андыйны”, - дип.

Ә мин ышанам
Күрмәгәнгә дә,
Күз күрмәс әллә
Ниләр барга да!
Аң җитмәс тирән
Серләр барга да, -
Юкса, ничек җәй
Миңа хат яза!
Күзем күрмәгән
Серле әлифба
Мин юк чорда да
Мине бар итә:

“Синең җәй – синдә! –
Ди ул өзелеп.-
Ул җәй бәхетле:
Аның көзе юк!”

Минем җәй миндә -
Шат һәм яшь калды!
Моңсу күземдә -
Хыял яшьләре,
Кулымда – көзгә
Яшен ташлары!

***

Бер күз салсаң, гөл булырмын,
Берүк йолкып ташлама.
Карамасаң, таш булырмын,
Тик гөл үсәр таштан да.

## ҮЗ КҮЛМӘГЕМ

Балачакта вакыт озак үтә, -
Җәйне җиткерәлми тилмереп,
Мин кар көри идем, кар астыннан
Ул чыгарга тиеш дип белеп.
Көри торгач, җәй дә җитә иде.
Үз вакыты аның, үз җае...
Тик мин уйлый идем үзем казып
Алдым диеп ямьле ул җәйне!

Хәзер вакыт никтер бик тиз үтә -
Өлгерәлмим алып көрәкне,
Яңа күлмәк киеп җәйләр җитә!..
... Бер мин генә иске күлмәкле!
Яңа күлмәкләрем иске җәйдә -
Кар астында гына калды бит!
Тик кар казып җәйләр эзләр өчен
Нидер җитми... Җитми сабыйлык.

Юк, үткәнне сагыну ул кадәр үк
Кар тырнарлык түгел анысы.
Яңа җәйләр каршыларга чыгам!
Үз күлмәгем үземә - ярыйсы...

## ҖӘЙ ҖЫРЫ

Озын кышлар буе җылыттың
“Җәйләр килер бер” дигән өметем.
Июнь генә әле – җәй башы,
Тузганаклар инде чал чәчле!

Ямьле җәй көннәре санаулы –
Истәлеккә генә калмады.

Өметем зур кыска җәйләргә,
Уйларым күп – башым әйләнә.
Тузганаклар туза “Уф!” – дисәм. –
Әллә өметләре юк микән?..

Ямьле җәй көннәре санаулы –
Уфтанырга гына калмады.

Сынма, өмет, эзлән, сызланып син!
Чал тузганак булып тузма син!
Сагынырга калсын бу җәйләр,
Онытылырлык булып узмасын.

Ямьле җәй көннәре санаулы –
Сагынырга гына калмалы.

***

Гөлле җәйләр узган инде.
Көзнең дә иң азагы.
Чәчәкләрнең иң кыйммәтле,
Иң хикмәтле заманы.

Шулай хәзер, гөл-чәчәкне
Сирәк бүләк итәләр.
Ансын да әле – бүтәннәргә
Бүләк итә бүтәннәр...

Рәхмәт, дустым, шул чакларда
Алсу гөлләр сузасың!
Ләкин син чәчәк бирүнең
Беләсеңме йоласын?..

Мондый бүләк – ул бит йөрәк,
Уйнак серләр символы.
Дәртләр сүзгә сыймаганда

Бирәләр бит мондыйны!

Кыйммәте дә, хикмәте дә
Шул серләр белән генә.
Ансыз - чәчәк берни түгел,
Бары чүп үлән генә!
Мин яратам символларны, -
Яшим уен хәлендә...

Дөрес, көз шул. Чәчәкләрне
Сирәк бүләк итәләр.
Тик көнләшмим: бүтәннәргә
Бүләк итсен бүтәннәр...

... Әнә ап-ак кар өстенә
Чәчәк сибеп киткәннәр!
Кичер, дустым, - димәк, алар
Чүп үләне икәннәр...

### ХӘЗЕР

Бураннарга кереп адашырга
Җитә әле, җитә кыюлык!
Тик бураннар хәзер бигрәк сыек,
Хәзер адашырлык урын юк.
Буран канатының каурыйлары
Бетә микән шулай коелып?..

## КӨЗ – СЕР ШУЛ ӘЛЕ

Гөнаһын, чаңын дөньяның
Салдырып алды көзләр.
Ак томанга төрде җирне.
... Ник соң моң-зарлы кызлар?

“Җәй генә тормышның күрке,
Көз – үлем, үлем! – диләр, -
Андый гөлләр булмас инде,
Ах, гөлләрем шиңделәр!”

Язгы ярсулардан бушап,
Тынычлап калды күңел.
Челләләр көйдергән иде,
Дәвалап исә дым-җил.

Урманнар үтә күренә!

Офыклар тирәнәйде.
Бушанып, чистарып йөрәк
Киңәйде, җиңеләйде!

Сулар да гөл, чыгар да гөл!-
Үлем дә түгел, ял бу, ял!
Яфрак койган каеннарның
Кәүсәсендә ак хыял!

Бөреләрдә өмет йоклый,
Өмет ташый көз җиле...
... Кызларга көз сер шул әле:
Кызларга тик унҗиде...

## БЕР ИРКЕНЛЕК

Җылы язда иркәләнеп,
Эссе җәйдә назланып,
Мин белмәгән кошлар белән
Шаярып, куштанланып,
Мин белмәгән мәдхияләр
Ишетеп былбыллардан,
Миңа тимәгән бизәкләр
Алып затлы нурлардан,
Яфраклар да инде менә
Мин йөрмәгән юллардан
Кара көзгә килеп керде.
Көзгә керсәм, моңаям.
Ә аларда – мин күрмәгән
Алтыннар чылтыраша,
Аларда – мин кичермәгән
Көч һәм дәрт ташып аша!
Алтыннарын атып бәреп,
Башны салып җүләргә,
Барын кичергән яфраклар
Ирек даулый җилләрдән!
Ирек эзләп оча алар
Салкын үлем юлыннан...
Ирек – һаман бер агачта
Калтырашып торудан,
Мин белмәгән сәер ирек –
Торгынлык коллыгыннан.
... Мин дә сизгән бер иркенлек
Яфраклар коелудан.

## КӨЗ

Сокланып та өлгермәдек
Бу якты, көләч көзгә...
Алдагы кошларны уйлап,
Кояш инде яшь түгә;
Каен инде яфрак түгә,
Усак инде төс түгә,
“Алда бозлы ялгызлык”, - дип,
Җилләр башланы бөгә -
“Алда язлар сезгә түгел,
Сез, - дип, - кышта каласы!..”
Җилне тыңлап, шомга баткан
Бар табигать баласы.

Тукта, җил! Бәхетле булыйм! –
Җир тулган алтын белән.
Вакытында дөрлик әле,
Сүнәрбез вакыты белән...
Кума китмәгән җылыны
Килмәгән салкын белән!
Кояш яуган өметләргә
Яумаган карны кушма!
Курыкмыйм – гайре табигый
Түгелдер әле кыш та...
... Бүгендә генә яшәргә
Өйрәнеп булмый һич тә.

***

Кагылган чаклар да истә
Һәм сугылган чакларым да.
Төрлесен күрсәтеп, тормыш,
Өйрәттең бит шатланырга!
Алдан белсәм шатлык хакын,
Күнмәс идем шартларына...

## КҮЧЕШ ЧОРЫ

Агачларда бәсле сары,
Кырыу һәм яфрак исе.
Көзнең башка күчеше бу.
Бездә - хисләр күчеше.

Урамнарда – иркенәю,
Һаваларда – тазару.

Кызганып, салкын яфракны
Җирдән күтәреп алу.

Җил дә тынган. Тәүбә кылган
Яфрак кырып йөрүдән.
Ә җан кыю, ә кан кою
Беткән кебек – бүгеннән.

Мәңгелекне уятучы
Киң һәм йошак яктылык.
Вак-төяк үпкә һәм чәмнәр
Урынында – яхшылык.
Кеше икәнеңне онытып,
Изгелеккә талпыныш.

## САГЫНЫП СӨЙЛӘР ӨЧЕН...

Чәчләремне кисеп җилгә сипсәм,
Каргамаслар микән бу чәчләр?
Яфрак өзә җилләр, яфрак туза!
Ник еламый икән агачлар?..
Агачларда - сабыр нәзәкәтлек,
Тез һәм горур булып торалу.
Башта – җыеп, саклап бәхет табу,
Аннан – ташлап, бушап куану...
Сары яфракларның тузынуы
Рухташ әле миңа бүгенгә.
Кисәм әле сары чәчләремне!
Бу гүзәллек ялгыш бу индә!-
Җиде тапкыр үлчәтеп тә тормый,
Тәвәккәллек җене тилерә.
Миңа өзү, себереп түгү кирәк,
Тәмамлау. Һәм – башлау яңадан.
Торналарга ышанып та тормый,
Чыпчык очырып рәхәт табалам.
Үсә микән көзен кискән чәчләр?
Кисүен мин кисеп караган...
Тик ул кыю һәм шаян чак иде,
Шаулап яфрак ярган чак иде;
Чуалчыкны, буталчыкны сүгеп,
Ачып ташлый алган чак иде!
Менә хәзер бу буталчык чәчләр
Арасында калдым чуалып.
Колакларга болай җылы да соң,
Җаным караңгыга чумган бит!
Алтын яфракларны җилләр коча,

Алтын толымга да шат булыр.
Йә! Үсмәсә үсмәс көз кискән чәч,
Сагынып сөйләр өчен яд булыр!

***

Еллар үткән саен ачыла күзләр,
Дөресерәк карый, кыюрак.
Ләкин комнан алтын табып алу
Еллар үткән саен кыенрак.

## ЗӘҢГӘР КАР КИЧЕ

Шундый хозур, шундый зәңгәр бу кич!
Мин дә зәңгәр микән бу мәлдә?
Ак карлар да, җиргән төшкәч, түзми, -
Әверелеп китә зәңгәргә.

Азмы монда моңсу, томса төсләр!-
Бер көнемдә генә мең төс бар.
Бөтен төсләр чума саф зәңгәргә -
Бар дөньямны күмә керсез кар.

Зәңгәр таулар булмаганмындыр инде –
Әкиятләр чынга ашканнар! –
Зәңгәр кошлар оча күзләремнән,
Зәңгәр гөлләр чыккан ак кардан...
Күңелемдә тик зәңгәр тәрәзәләр!
Бүтәннәргә кошлар ватканнар.

***

Көн дә яңа карлар ява,
Көн дә яңа җил исә.
Ә мин бар да картаер дип
Курка идем югыйсә:
Еллар буе яши торгач,
Җирдә кызык бетәр дип,
Нинди генә яңалык та
Яңа булмас бүтән дип.
Тик күзләрем иске җиргә
Гел яңача карыйлар.
Иске дөньяны көннән-көн
Яңарак дип санпритлар.
(Әллә яңалык күзләренең,
Үзләренүк салынган?..)

Көн дә яңа булып туам,
Яши башлыйм яңадан.
Картаермын дигән идем,
Яңарам да яңарам;
Игелекнең, изгелекнең
Кадерен белә барам.
Кешеләргә рәхмәтле һәм
Шәфкатьле була барам.
Үткәндәге оятлардан
Менә хәзер кызарам...
Картая дип кайгырмагыз –
Мин яхшыга үзгәрәм.

***

Көннәр ятты, еллар ятты –
Катлы-катлы кар булды.
Аклары бар, таплары бар –
Дөнья булгач, бар инде...
Ни булса да, үз карымны
Юрган итеп ябынам;
Җылы тапкан булам шунда,
Юаныч тапкан булам.
Яшәү миңа шунда гына –
Әйтерсең лә Кар кызы...
Тик яз килсә, кыра-кыра
Кара-кора кар-бозны,
Минем дә үз карларымны
Килә кырып түгәсем,
Һәм куркытмый алар белән
Бергә юкка чыгасым!
Калын-калын кар астында
Үзгә тормыш бар сыман,
Мин һичкайчан күрмәячәк
Гүзәл тормыш бар сыман...
Башка тормыш, чиста тормыш,
Мәгънәсе мәгълүм тормыш!
Тик мин шул карларым белән
Бергә китәргә тиеш,
Ах! итеп яшәү мәгънәсен
Эзләп йөргән килеш...
Юк, көн килер: ялбырдатып
Кисмәгән толымнарны,
Меңәр еллык көртне ерып,
Йөгереп чыгылыр әле!
Гүзәлеккә бизәк булып,

Яздай яшь һәм саф булып,
Яшәүгә дә, үлемгә дә,
Үзенә дә хак белеп!
Ала-кола карлардагы
Таплардан азат булып!

Әй, Кар кызы! Бер үк кардан
Мөмкин тик бер туарга...
Ә ул, исәр, язлар сорап
Кулын сузган дөньяга!
Үзгә тормыш, гүзәл тормыш
Әллә каян елмая! –
Кешелекнең киләчәге
Канат җилпи хыялда.

***

Шомырт чәчәк атса,
Кара-коры кача.
Тик яшеллек җирдә, тик аклык!
Шомырт җырлап тора,
Сөю сорап тора.
Сөю булган җирдә гөнаһ юк.

Кара ботакларны,
Шәрә ботакларны
Нинди сихер көче гөл иткән?
Ак бәхет яз саен
Һәрбер тәлгәш саен! –
Әй, көнләшәм шушы шомырттан!

Белсәм шомырт телен,
Егылып сорар идем:
Бу яңару сере нәрсәдә?
Бөек телем, кичер! –
Җитми синең көчең...
Мин газапта...
Шомырт чәчкәдә!

## ТӘРӘЗӘ ЮАМ

Кыш буе кулым кычыта –
Тәрәзә юалмыйм да.
Тын кысыла, җан тарлыга
Һәм тарая бар дөнья.
Ай, шапшаклы сөймәүләрем!-

Әллә чистомания...
Бер галәмне юар сыман
Тилерәм кайчагында!

Майлар җитә! Их шартлатып
Ачабыз тәрәзләрне!
Яшәсен язгы өмәләр!
Яшәсен Май бәйрәме!
Яшәсен язгы омтылыш:
“Пычрак яшәмик, туган!”
Яшәештән гүзәл күренеш:
Җырлыйм һәм тәрәз юам.

Көндез тапмаган тапларны
Эзләтеп тазартам төнлә,
“Ябалак” мин – караңгыда
Ачыклыйм фикеремне дә.
Ул тапларны миннән башка
Булмас искәрүче дә.
Бар шатлыгым – шул чистару:
Тап калмасын фикеремдә!
Сөенсен җан! – Байга түгел,
Җанга диеп эшлим лә!
Елык-елык тәрәзәләр!
Нинди иркенлек тышта!
Үз тәрәзәң пакь булгачтын,
Тыш та күренә чиста.

## АХ, БУ БӘХЕТ!..

Күпме йөртелде хыялда,
Күпме көтелде!
Килде шаулап, килде купшы,
Ләкин соң килде!-
Яңа ел үткәч бизәлгән
Чыршы шикелле...
Ах, бу бәхет...

***

Ак чәчәк, күк чәчәк,
Нигә исмең юк, чәчәк?
Әллә исмең булса да,
Белгән кеше юк, чәчәк...

Ак чәчәк, күк чәчәк,

Нигә исең юк, чәчәк?
Әллә исең булса да,
Сизгән кешең юк, чәчәк.

Ак чәчәк, күк чәчәк,
Ник сез ишле, күп чәчәк?
Әллә сезне шуның өчен
Күргән кеше юк, чәчәк...

Ак чәчәк, күк чәчәк,
Менә күрдем бит, чәчәк!
Юатыр сүзем күп, чәчәк, -
Әйтмим. Үс һәм көт, чәчәк...
Дөнья бу! Шуны аңларга
Дөньяга килдек, чәчәк!

***

... Ә бит оча белсәң иде!
Ә бит оча алганыңны белсәң иде!
Ә бит очып китә алганыңны белсәң иде!
Бәлки, очмас идем дә мин.
Бәлки, очып бик тиз алҗыр идем дә мин.
Бәлки, арып-талып
кире кайтыр идем дә мин...
Тик мин азат булсам иде!
Тик мин җирдән азат булсам иде!
Тик мин
җирдән куба алганымны белсәм иде!
“Очсам – иркем...” дисәм иде!
“Җир тетрәүдән дертләп яшәү
бетте ...” дисәм иде!
Купмас идем, бәлки, җирдән –
Җир кадерен ныграк белә күкне белгән,
Ул баерак, иманлырак була шул белүдән.

Әйе, оча белсәң иде.
Әйе, оча алганыңны белсәң иде.
Әйе, очып китә алганыңны белсәң иде!

***

Күзе сәер мәхәббәтнең! –
Яратудан бит, беләм,
Үз баламның бер хатасын
Биш дип күреп интегәм.

Читтә булса, күзем йомып
Үтәр идем чүп-чарны...
Елата күзгә кадалып
Үз илемнең чүпләре.

“Үз күзеңдә бүрәнә дә
Сизелми”, - диләр. Ялган!
Кайчагында күзләремне
Ачарга да оялам...

Сукыр мәхәббәт куенында
Йокымсырау татлыдыр.
Тик теләмим.
Алданырга
Гомүмән яратмыйм мин.

## БАГЫШЛЫЙМ

*Сибелә чәчәк...*

Белмим, җилләре дә, кыравы да,
Ходае да сүз берләшкәнме –
Барысы да тия иң күркәмгә,
Барысы да кыра чәчкәне.
Карак кәҗәләр дә, җай чыктисә,
Керт-керт итеп чәчәк кабалар. –
Чәчкә утлап кына гомер иткән
Кешеләргә охшаш хайваннар...
Ләкин чәчәк утлаганга карап,
Гөл үсми шул алар эзендә!
Гөлләр генә гөл тудыра белә,
Һәм алар гел илнең күзендә:
Каты күзләргә дучар алар,
Дошман алар бар көнчеләргә,
Үчле кулларга да корбан алар, -
Озак торулар юк гөлләргә!
Гөлләр генә гөл тудыра белә.
Иҗатында – ямь дә, җимеш тә.
... Чәчәк сакламаулар искә төшә,
Кара чүлләр туса тормышта...

***

*Какма кеше капкасын,*
*Үз капкаңны кагарлар.*

Кагышмасак капкаларны,
Күгәрер бит капкалар...
Үзебез дә тутыгабыз,
Чыгалмый ихатадан.
Без калырбыз намуссызлар,
Кыюсызлар, телсезләр,
Дошмансызлар һәм дуссызлар,
Көрәшсез, җиңүсезләр.
Куркынычлар, кара эчләр,
Астыртыннар, ялгызлар,
Капка ярыгыннан кереп
Чага торган явызлар...

Ярык-йорык юк капкамда –
Еланнар да каксыннар!
Каксыннар – буйлары җитсә,
Җиңәлсәләр – чаксыннар!
Каксыннар ачыктан-ачык,
Чаксыннар – гаеп өчен:
Еланнарга да Ходаем
Гадел явызлык бирсен!
Елан белән елан булмам, -
Мин еланнан өстенрәк.
Бүтәнрәк – усаллыгым да,
Һәм миңа бүтән кирәк:
Капка кагам дус табыйм дип,
Табыйм дип фикердәшләр,
Көткәннән яхшырак булып
Чыксыннар дип тиңдәшләр,
Уянсыннар дип йоклашлар,
Мүкләнмәсен дип ташлар,
Гарьләнсеннәр дип куркаклар,
Уйлансыннар дип башлар,
Сискәнсеннәр дип сабырлар,
Кузгалсын дип юашлар!
Ә кыюлар, ә шаяннар,
Ә теллеләр, үткенләр,
Валлаһи, яратып киләм –
Колач җәеп көтсеннәр!

Шыгырдап торган капкам бар,
Берүк кага күрсеннәр.

Ләкин кагып качмасыннар,
Каккач инде – керсеннәр.
Күтеп торам иманга көч
Алырга һәрберсеннән.

***

Карга күзен карга чукымаса,
Каргалар да хикмәт тирән бит!

Адәм күзен адәм чукымаска,
Туганнарны хурлап утырмаска,
Якын кояштан тап чүпләмәскә,
Пәйгамбәрне читтән эзләмәскә,
Кардәш телен кардәш тешләмәскә,
Якынына этлек эшлмәскә,
Күрше йортын күрше яндырмаска,
Дусларына кабер казымаска...

Каргаданмы инде өйрәник?!

## ЭНДӘШМӘҮЧЕЛӘР ТУРЫНДА

Дәшмәүчеләр бекемне дә тыңламый дип
уйламагыз,
Дәшмәүчеләр бернәрсә дә аңламый дип
уйламагыз,
Дәшмәүчеләр барын да белә, сизә дип тә
уйламагыз,
Дәшмәүчеләр барына да риза дип тә
уйламагыз,
Дәшмәүчеләр гомер буе шым яшәр дип
уйламагыз,
Дәшмәүчеләр берәгәйле бер дәшәр дип
уйламагыз.

Эндәшмәүчеләр турында
Бернәрсә дә уйламагыз:
Яхшы дип тә, яман дип тә,
Башлы дип тә, надан дип тә...
Олы дип тә, эре дип тә,
Үле дип тә, тере дип тә -
Бернәрсә дә уйламагыз:
Үз сүзен әйтмәгән кеше
Ул беркем дә түгел әле.

***

Диңгез суы тиз җылынмый икән,
Бик тиз кыза икән ярда ком.
Мин яратам кайнар колы ярны,
Салкын суларны мин яратмыйм!

Диңгез суы тиз суынмый икән,
Тиз суына икән ярда ком.
Ышанма син комга, ышанма син!-
Бер тәүлеккә бишәр алдатыр!

Мин аунадым, диңгез кайнар комда!
Санламадым салкын суыңны.
Баксаң, диңгез – ул тирәнлек икән,
Ә ком – бары сайлык символы...

Эссе комда шау-гөр килгән чакта
Һич уйланмас идем шикелле.
...Мин – суынган комда ялгыз, төнлә...
Җылы диңгез! Ючы шул комны!

## ШИГЫРЬГӘ

Барсыңмы, Шигырь, юксыңмы?-
Ай күрә, кояш ала...
Йөргән ир белән хатыннар
Ничек яши, йә Алла!

Үзең миннән ирекле син,
Үзең чорналган миңа.
Үзең ләззәт, үзең газап,
Мин шуларга кол гына.
Шулкадәр өстән карыйсың!-
Шәүлән генә күренә.

Үрелсәм, буйларым җитми,
Аңлыйм дисәм, җитми аң.
Син лаеклылар эзлисең,
Мин тик сине яратам.

Сиңа гына ача алам
Йөрәгемнең серләрен.
Ачтырмасаң, ачылмасам,
Шартлаячак йөрәгем!

Тик син шигъри гашыйкларны
Күргәнсең ахры күбрәк...
Минем серләр шундый иске!
Сиңа яңалык кирәк...

Тулып торган дәрт кирәк тә,
Ургып торган шигърилек!
Миндә чирле шигърилек тик
Эллә шигъри чирлелек...

Гел авырту! Гел сызлану!
Каһәрлим сине, каргыйм!
Юкка чык! Эзең булмасын!
Мин болай яши алмыйм!
Тарал, гомерлек сырхавым!
Савыгыйм, дим, югал, дим!

Төштә күрәм каргышымның
Сиңа чынлап төшкәнен,
Алгысынмый һәм ярсынмый
Яшәр көннәр җиткәнен.

Күз алдымнан гүзәл шәүләң
Бөтенләйгә киткәнен,
Шәүләнмә җан кермәсме дип
Зар елавым беткәнен.

Инде син юк! Инде син юк!
Саулык бар да йокы бар!
Тик яңадан авыру булып
Уянам шул йокыдан...

Әллә минем канымда син
Агуланган ук сыман...
Әллә агу, әллә дару –
Хәлемне ала... Буйсынам...

Риза якты шәүләңә дә,
Сүнмә генә, әй, шигырь!
...Йөргән ир белән хатыннар
Бәлки, шулай яшидер...

***

Шатлыгыннан кайгысы күп,
Болытлы көн – кояшлыдан.
Кара күктән яңгыр коя,
Шул чынлыкны юган сыман..

***

Ах, бу нинди янмый көю,
Нинди сызлау ярасыз?
Януларга тузган йөрәк
Янмауларга – чарасыз...

Аллы-гөлле ялкынларны
Аллы-гөлле канатым
Очып барып кочар иде,
Белә торып янасын;
Аллы-гөлле канатлардан
Тик яралар каласын,
Үзе янган көлләрендә
Аунап дәваланасын!..

Яктыга талпынган күңел
Янмый ничек калалсын!
Утка корбан булыр идем,
Белсәм икән чарасын!
Ах, утларым булса икән,
Булса икән канатым!..

## ЭТЛӘРГӘ МЕДАЛЬ БИРГӘНДӘ

Муеныма затлы чылбыр асу
Бәхет миңа шундый микъдарда:
Никадәрле бәхет бирә ала
Медаль яулап алу этләргә.

Муеныма затлы чылбыр асмау
Хәсрәт миңа шундый микъдарда:
Никадәрле хәсрәт бирә ала
Медаль яулап алмау этләргә.

Тугрылыкка каршы – тик тугрылык,
Мәхәббәткә каршы – тик мәхәббәт,
Мөлдергән күзләремә каршы –
Күзләр тулы тирән мәрхәмәт,

Эчкерсезлегемә - эчкерсезлек,
Мәкерсезлек – ачык җаныма!
Һәм мин күбәләктәй йөрәгемне
Учыгызга әзер салырга!
...Бәхеттә һәм бәхетсезлектә мин
Эткә охшыйм кай чагында...

***

Мин үзсүзле – агымнарны бордым,
Агым уңаена акмадым.
“Язмыш” дигән сүзне инкяр итеп,
Тормышымны үзем ясадым.

Гомрем юлы үз кулымда булды.
Үзем хуҗа калган көннәргә.
...Үткәннәргә ләкин күз ташласам,
Гүя мин күрмәгән биләмә!

Миннән сорамыйча аккан су күк,
Миңа таныш түгел юл кебек.
Үзем иҗат иткән, истә йөрткән,
Ләкин миннән азат җыр кебек...
Язмыш-патша еллар, юллар аша
Күзен кысып куя бер көлеп!

***

Гармун тартам, гармун тартам,
Көй чыкмый гармунымнан.
Күздән яшьләр генә чыга,
Сыгылып йөрәк моңыннан!

Әй, тормыш, гармуннар бирдең,
Өйрәтмәдең уйнарга...
Көйсез тормыш юлларында
Көйсез икән җырлар да!..

Гармун тартам, гармун тартам!
Гармунчы түгелмен шул...
Әй тормыш, син мең-мең көйле
Җыр булып күрендең шул!
Барысын да отыйм диеп
Чәчелдем-сибелдем шул...

## СЕРЛЕ КӨЗГЕ

Барын да белә, барын алдан күрә
Серле көзге – ана күзләре.
Тезелешеп менә алга килә
“Саклана күрсәнә!” дигәне.

Үзе күргән барлык афәтләрдән
Сакламакчы аны баласын.
Әниләрнең үткәннәре барын
Балалар соң каян аңласын?!

Шуңа күрә соңрак аңлашыла
Әүлиядай ана сүзләре.
Тезелешеп, менә, алга килә
“Шулай булмасана!” дигәне...

Оныткандыр димә, искә төшә -
Изге икән синең сүзләрең.
Көзге икән күңел күзләрең!
Барысын да бирдең миңа, әнкәй,
Шул көзгеңне генә бирмәдең...

## ҖЫРЛАР БӘЙЛӘНӘ

Бәйләнә бит җырлар, бәйләнә бит!
Минекеләр түгел – аңлыйм да...
Диваналар булам көйли-көйли,
Кодрәтләрем җитми арынырга.

Төрле арбаларга утырыла –
Арадашлык көчле заман бит.
Кемнең арбасына утырдисәң,
Шуның җырын җырлау яман бит!

Ат-арба да, юл да кешенеке,
Уй-фикер дә, сүз дә, фигыль дә...
Арадашлар булу – ярый ансы,
Ләкин арбадашлар түгел лә!

Ятлар тиресенә кереп яшәү
Табигатьтә булыр хыянәт:
Табигатьтә һәр зат оригинал,
Кабатланмас бер экспонат.

Табигатеңә дә тугры калып,

Заманга да ничек ярарга?
Халык мыжлап торган бу сәхнәдә
Үз җырыңны ничек табарга?

Иртән торсам – гаҗиз:
башлар шаулый,
Әллә мең җыр анда төялгән!
... Авыр башларымны сафаландырып,
Нәнәй килә тирән төннәрдән.
“Тамыр җәйгән гөлләр кебек!” диеп,
Яңгыратып җырлап җибәрәм!

***

Иске димим бу дөньяны –
Әйләнеп тора дөнья.
Тик яңа да димим аны –
Әйләнеп кенә тора.

## ТУГАН ЯК МАНЗАРАСЫ

### Офыкта эскерт

Зәңгәр офыкта якты тау –
Сары салам балкышы.
Килеп егылдым эскерткә,
Өемә кайткан төсле.

Ул шулкадәр җылы икән,
Якын икән кояшка!
Мин соң ничек яшим икән
Кояшлы таудан башка?

Ни икәнен белдем микән
Тормышны яратуның? –
Белмәгәнмен ни икәнен
Кояш кочып ятуның!

Офыкларга җитәлмичә
Күңелем күпме интекте!
Минем офык – эскерт икән,
Туган якның эскерте.

**Болыт бәллүендә**

Җем-җем кояш нурларына
Болыт бәллү элгән.
Ак бәллүне тирбәтергә
Иң йомшак җилләр килгән.

Мине дә тирбәтә алар
Назлы күк бәллүендә.
Һич кенә дә гаҗәп түгел:
Мин бит туган җиремдә!

**Туган кырларда**

Ямь биреп далага,
Йомраннар елт та елт –
Чибәрләр, шаяннар,
Торалар елмаеп;

Гүя мин кайткачтын
Курку да онтылган,
Йомраннар да гүя
Тансыклап кайтылган.
Бу туган кырларда
Гүя без бертуган...
Гүя мин кул сузып:
- Саумысез! – дип торам!
Хәер, бу шулай шул...
Йомраннар сизгерләр!
Илкәйне сагынуым
Сибеләдер күземнән.

**Туган якның асылмалы каеннары**

Сезнеке ни, безнеке ни –
Каен инде каендыр!
Тик каенлы шушы юлда
Туктыйм кайткан саен мин,
Туктыйм кайткан саен мин...
Алар мине аңлыйлар –
Муеныма асылына
Асылмалы каеннар.

Каеннарның аермасын
Мин менә шуннан беләм:

Кочаклашып елап була
Тик бу каеннар белән...

**Хәвефле тургай**

Тургай сайрый, тургай сайрый
Баш очымда ачынып,
Оясыннан ераккарак,
Ераккарак чакырып.

Балаларын алырлар да
Көнчелектән, үчлектән
Саесканча йә каргача
Өйрәтерлә дә микән?..

И курыкма миннән, кошчык!-
Мин бит үзем, бәгырем,
Тургайлыкны саклар өчен
Кош булырга әзермен!

Тургай сайрый, тургай сайрый
Бәргәләнеп, ачынып –
Җирдә иң соңгы оядан
Азаккы тургай кебек...

**Әкияттәй**

Әкияттәй серле-гади:
Үз урынында бары да.
Таллары су буйларында,
Ташлары тауларында.

Урманда урман һавасы,
Далада дала җиле.
Кешеләр дә үз урынында –
Торган җир – туган җире.

Шушы җирдә ямьле алар –
Үз урынында булганга.
“Чыбыктан таяк” булганнар
Килешмиләр бу фонга!

Әкияттәй серле-гади:
Үз урынында авыл да!
Күпме тиңтергәннән соң, -
Үз урынында җаным да.

## ЯЗГЫ АШКЫНУЛАР

Эчә диңгез суын,
Яңгыр суын, боз суын.
Сусый диңгез, сусый диңгез!-
Тоз гына шул, тоз – суы...
Каты суы, авыр суы,
Ташу белмәс ярсуы;
Җырлый белмәс, елый белмәс –
Күңеле дә катымы?
Чайпалдырып авырлыгын,
Авыр сулап куя да...
Булдыралмый ярдан чыгып
Йомшак суга коярга.
Суың каты, күңелең каты,
Ник кызганыч шаулавың?
Сиңа кыен аңлатуы,
Безгә кыен аңлавы.
Бар дулкынын сүзгә салып
Әйтә белми адәм дә...
Ярсыйм телсез диңгез булып
Моңлы язгы айларда!
Тик мин әле бүтән диңгез:
Минем кояр җирем бар,
Язларга кайтып егылырга
Минем туган җирем бар.
Авырайды дулкыннарым –
Тозлар-ташлар тулганнар...
Чәен куеп җибәр, әнкәй! –
Таш булдым ят сулардан...
Иң йомшак су – синең чишмәң,
Йомшарам тик шуңардан.

## ТӨШТӘ ШУЛАЙ...

*Тауга менеп, ташка басып,*
*Карасам да, күрәлмим...*

Күзләремнән яшьләр коеп,
Әй, эзләдем бер өйне! –
Һичнәрсәне шулай өзелеп
Эзләгәнем юк иде.
“Соңга калам, соңга калам!
Сүтәләр!” – дип йөгердем.
Йөгерсәм дә, соңга калдым –
Ул өй инде юк иде!..

Барыбер нәнәй капка ачты,
Барыбер капканы элде.
Аның җаны бу нигезгә
Шуңарга кайткан инде...
Ә мин бүтән - ә мин киткән
Һәм оныткан ул өйне!
...Төштә шулай үз-үземә
Кайтып йөрим түгелме?!

## ТАРИХКА БЕР КАРАШ

Офыкта – кызыллык.
Юл җитмәс, кул җитмәс серле ут.
Мәңгелек ал шәфәкъ. –
Төтенсез утларга сүнү юк.
Төтеннән котылган,
Котылган үлемнән, көрәштән.
Тик дөрләү дә юк шул!-
Болытлар куенында урнашкан.
Җир һәм күк арасын
Ил итеп, офыкка сыенган.
Ә иле – ал мираж...
Ә үзе – бар микән, гомумән?..
Бар ул, бар – балкый бит –
Төтенсез, тик кайнар теләкле:
“Туңам, ди, ягыгыз!
Кабынсам, мин бөек бүләкмен!
Мин сезгә башларны
Биегрәк итәргә кирәкмен.
Кемнәрнең уты мин?
Таныгыз, өрегез җан миңа!
Табылсам, мин сезне
Үлемсез итәчәк хәзинә!”
Ә офык – ал мираж...
Акыл да җитәлми хәзергә!
Тик акыл пәрдәсен
Тирбәтеп төннәрдә җил керә:
“Боз кебек офыкта
Югалган тарихлар интегә!..”
Күзләрдә - гел төтен... Гел төтен...
Төтенсез утларны кем күрә!

## ТӨШТӘ ЯШЬ БАЛА КҮРӘМ

Төштә яшь бала күрәм дә
Юрыйм бала тууга.

Тик яшь тама татлы уйга,
Дәртле күңел боега.
Төшләремне искә төшерәм,
Төшләрем – төсле кино...
Тик төштән уйларга күчә
Кап-кара төсләр генә:
Җимерекләр һәм үлекләр,
Кара мич авызлары...
Кара көйгән чирәмлекләр,
Кара көш авазлары.
Чатнап кипкән кара күлләр,
Буш җир асты кап-кара...
Һавасы да кара төтен,
Ту да тын алып кара!
Ту да рәхәт күреп кара
Кара бушлык эчендә...
Ту да рәхмәт диеп кара
Сине тудыручыга!
Ачлык. Корылык.
Һәм тынлык.
Урмансыз, кошсыз җирдә
Яшел җир-су галәмәте
Калган сүрәттә генә...
Җинаятьче кем тарихта?
Кемнән алырга җавап?
Җинаятьләр ачылса да,
Гомер кайтмый шул кабат...
Буяу сеңгән, комнар күмгән...
Хөкем залы – буш дала...
Гаепле һәм гаепләүче –
Бала тапкан бер ана.
Куркам төшләргә юрарга да
Һәм уйлар уйларга да.
Куркам кино карарга да
Һәм бала табарга да...

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРГӘ

Андый җырлар калмас елап үлгәннәрдән,
Ышанам мин – сез елмаешып үлгәнсез –
Елау заты юк Җәлилнең җырларында.
Күз яшьләрен көн нурына яшергәнсез!..

Елмайгансыз... Тик яшергән яшьләрегез
Көн нурыннан
минем күзгә күчкән мәллә?-

Уйлыйм – елыйм, сөйлим – елыйм...
Мин бары тик
Сезне сагынып елар өчен үскән мәллә?
Кичерегез мин елакны.
Ах, бу кояш
Бигрәк моңлы ядкарь сездән –
исәннәргә...

***

Урман тулган печән исе,
Юкса, тәмле ис кенә.
Тик бүген чалгы тавышы
Бигрәк шомлы ишетелә.
Хәтернең ул авырткан
Кылына тия сыман.
Ромашкалар ауган чакта,
Кызарып куя сыман.
Җиләкләр тәгәрәп ята
Чапкан печән өстендә.
Зират җиләкләре сыман –
Алып капмыйм берсен дә.
Бал кортлары бәргәләнә -
Ни гамьнәре бар икән?..
Адәм баласы күргәнне
Күргәннәре бар микән...
Уйлана тора күңел,
Әллә нинди хәл бүген.
Уф, печән чапмагыз әле! –
Үләннән дә жәл бүген!..
Бүген егерме икенче июнь...

## НИЧЕК КЕНӘ ТҮЗӘДЕР

Сөлек кебек егетләрне күрсәм,
Борчуларым китә таралып:
Илдә тормыш, димен, гөрли әле,
Яшиселәр алда бар әле!

Сөлек кебек егетләрне күрсәм,
Борчуларым китә куерып:
Сөлек кебек буйлары, дим,
Кай илләрдә калыр егылып!..

Урамнарымны ямьләп үтә алар
Һәм тибрәтеп нечкә күңлемне.

Сөлек кебек егет әнкәләре
Ничек кенә түзәдер инде...

## КЕШЕ ТУРЫНДА – КЕШЕГӘ

Ямьсез күреп, ямьсез дия күрмә -
Һәр чәчәкнең аның төсе бар.
Сөйкемсез сөяк буламы! –
Һәркемнең әнисе бар.

Бәләкәйне бәләкәй ди күрмә -
Һәр җимешнең аның төше бар.
Кеше бәләкәй буламы! –
Кешенең әнисе бар.

Баласына сүз тидертмәс өчен
Газиз җанын бирер кеше бар.
Борчак хәтле берәүгә дә
Берәүләрнең таудай хисе бар!

“Мәрхәмәтле бул балама!” диеп
Дога укып торган кеше бар.
Кимсетә күрмә кешене! –
Кешенең әнисе бар.

## СТЕПАН РАЗИН ТУРЫНДАГЫ ҖЫРНЫ ТЫҢЛАГАЧ

Суга ташладылар шаһ кызын...
Идел булып Идел шаккаты!
Исерек башта акыл буламы?
Исерек башның хакмы максаты?

Гүзәл кызның фарсы шаһының
Кайсы дулкан икән агызган...
Айнык баштан, ихлас күңелдән
Ничә битең, тарих, язылган?..

Аракылы, канлы битләрең
Ертып суга ташлыйсым килә.
Шулай юган-чистарткан булып
Аклыйсым һәм яклыйсым килә.

Аңлатасым заман хәлләрен,
Стенька Разин герой икәнен...

Ниять изге булгач, чаралар
Бар да эшкә ярый икәнен.

Аңлаталмам! Алмам... Үземдә
Кызгану һәм нәфрәт берьюлы –
Ирек юлы бөек Иделне
Каргагандыр фарсы сылуы...

Нәрсә хакына да килешмәм
Кансызлыгың белән, кешелек!
Ник шәфкать юк көч булган җирдә?
Җиңүчегә нигә хөкем юк?!

Гөнаһсыз кыз бала корбанга
Нигә кирәк, нигә Иделгә?
Илләр буйлап ага Иделләр –
Батырлык һәм явызлык бергә...

## ӘКИЯТ УРАМЫ

Сезнең урам бер әкият төсле,
Карап тора тылсым-сер булып.
Ул таныйдыр мине, ул җанлыдыр
Һәм эндәшә төсле син булып.

Кешеләрнең күзләрендә монда
Әкияти, сабый изгелек! –
Безнең яшьлектән бит килә алар
Һәм һәрберсе азрак син кебек...

Кояш мине яшел нурга күмә -
Мин җуйганны саклап торганмы?..
Йөрәгемә шундый җылы тула! –
Кояш кызы булып туаммы?

Һәр тәрәзә назлап, сөеп карый,
“Хуш килдең!” дип тора һәр ишек.
Әкияттә таш та йомшак икән!
Ә чынбарлык каты һай ничек!..

Сезнең урам бер әкият төсле,
Ә син үзең?.. Кайда икән син?
Тәрәзәләргә нурын сипкәнсең дә,
Күңелеңне ташка түккәнсең дә,
Миңа дигән хәзинәләреңне
Елларыңа корбан иткәнсең дә...

Әкиятне берүземә ташлап,
Чынбарлыкка чыгып киткәнсең!
Мин сагынып килгән әкиятне
Чынга ашмаска хөкем иткәнсең.

## САКЛАНЫРГА ЯРАТУЧЫЛАРГА

*(Шаяру)*

Юл уртасы тар сызык,
Җайлы, нейтраль сызык.
Бер куркыныч юк монда –
Бар хәрәкәт зур юлда.
- Андагылар кызганыч –
Анда бит гел выж да выж!
- Ярый, тор син шушында.
Машиналар сиңа
Кырын да карамаслар,
Бармак та янамаслар
Юлыннан читтә торгач,
Һәремгә син – ай, кояш!
Һичкемгә юк зарарың,
Борчылусыз җаннарың.
Сүзләр дә тидермәсләр.
Җавап та бирдермәсләр.
Дөрес сызыкта торгач,
Түләтмәсләр штраф!
Тор да тор син шушында,
Ни туда һәм ни суда!
Тик бу сызык нейтраль,
Нейтральләр – тик тора...
Рәхәт кебек халәт бу,
Ләкин үлек халәт бу.

## ӘЙТЕЛМӘГӘН СҮЗ

(Җыр)

Әйтмәдем сиңа әйтер сүземне –
Җырларым өчен, ахры, сакладым.
Үттеләр инде әйтер вакытлар,
Җиттеләр инде җырлыр чакларым.

Моң булып калган сүзләрдән үреп,
Мин сүзсез генә озын җыр сузам.
Нидер хәтерлә җырымны тыңлап,
Мине хәтерләп таны шул җырдан.

Хәтерлә мине, эзләмә мине!
Сиңа тик моңым төшсен нур булып.
Тик җырда калсын әйтелмәгән сүз
Һәм мәңгелеккә күчсен җыр булып.

## ЯШӘҮ – САГЫНУ

Сагынам җирнең китер-китмәс карын,
Йөрәгемнең җитәр-җитмәс язын,
Бәхетемнең сагынам оялчаның,
Көләр-көлмәс кенә торган чагын.

Әлҗе-мөлҗе серле утны сагынам
Дәшәр-дәшмәс күзләр ягыннан,
Ал хыялның гади чынбарлыкка
Ашар-ашмас чагын сагынам!

Күпме яңгын яуган болытларсыз
Һәм төтенсез утлар ягылган!..
Болыт салкын, төтен ачы диеп
Белер-белмәс чакны сагынам...

Минем гомер күпме кабатланган,
Минем уйлар күпме язылган!
Бу дөньяның ачылмаган китап,
Серле утрау чагын сагынам!

Ә дөньяның кайчан ачылганы,
Кайчан сагынмаслык чагы бар?!.

## ЯҢА ЕЛНЫҢ СЕРЛЕ МӘГЪНӘСЕ

Иске елга тагын чал карт булып,
Тик шат булып, көлеп китәргә.
Тагын киселергә чыршыларга,
Ләкин балкып бәйрәм көтәргә.

Якут биреп тапмас вакытларны,
Уйнап-көлеп, җырлап озату –
Әллә мәңгелек бу газиз гомер,
Әллә аз булса да, йомарт бу...

Картаюга бер ел якынлашып,
Яшел символ кую яшьлеккә.
Ялтыр-йолтыр уенчыклар асып,
Маяк итеп санау бәхеткә!

Җиңү санап гомер озатуны,
Чын күңелдән “Ура!” дияргә.
Иске санап вакны һәм түбәнне,
Гел югары сүзләр сөйләргә.

Оптимистик бөек асылына
Кайта бугай тормыш бер мәлгә!
Серле бәйрәм!
Аңлашылмый мәгънәң,
Ләкин ошый миңа бу мәгънә!

Ел саен бер котлавыма
Гаҗәпләнмәсеннәр дусларым.
Бәйрәм саен дежур котлауларга
Гадәтләнмәсеннәр дусларым.

Дежур сүзне бит мин сөйләү түгел,
Тыңлауны да оят дип саныйм.
Серле мәгънәгә тап булсам гына
Сүз дәштерә мине илһамым.

## ЧҮЛ ГЕНӘ БЕЛӘ

Син һаман минем төшләрнең
Иң татлысында.
Сагышы да ул төшләрнең
Тик шатлык кына.

Гел дулкынланулар гына,
Гел оялулар...
Киләм диеп килми калып,
Күрми калулар.

Аннан соң эзләп йөрүләр
Таңнарга чаклы!
Тик мәңгегә югалту юк –
Уянгач ансы...

Ә уянгач, буш күңелдән
Сине табалмау.
Назлы сагну диңгезендә
Дулкынланалмау.

Уй белән дә, хис белән дә
Үткәнгә кайтмау.
Тик күңелдә чүлдәй шыксыз

Зур бушлык саклау...

Кибә күңелем коры чүлдә -
Нишләргә икән?
Күңел тулып ташып чыга,
Төшләргә керсәң!

Төштә диңгез була да ул,
Көн туса, кибә...
Диңгезгә әйләнгән чүлләр
Бар микән җирдә?
Диңгез булу нинди бәхет!-
Чүл генә белә...

## ЯШЬЛЕКТӘН БЕР СҮРӘТ

Безнең җитәкләшкән нечкә сыннар!
Аерылудан азат бергәлек!
Үзгәрүдән азат мизгел бит ул –
Без бит аны, хәтер, бирмәдек

Үзгәрүчән акыл хөкеменә,
Үзгәртүчән язмыш иркенә!
Хәзер бөек сәнгать әсәре күк
Гомеремдә ул минем иң түрдә.

Хыянәтсезлеккә символ-сүрәт,
Вакыт кодрәтенә - каһкаһә!
Безгә хуҗа вакыт, ә аңа – юк,
Ул үзенә үзе хан, патша!

Коллыгыңа төшер, гүзәл патша!-
Татлы миңа синең кодрәтең...
Мин туганмын бары аңлар өчен
Кыйммәтен бу мизгел-сүрәтнең!

## КҮКЛӘРДӘН ТОРЫП...

Мин күкләрдән торып сөйдем сине,
Әйтмәс идем сиңа ни генә!
Кирәксенмәдең шул күкләр телен,
Сүз тапмадым җирләр телендә.

Еллар буйлап син дә килдең миңа,
Бәлки, башка китмәс идең дә...
Кирәксенмәдем шул җирләр телен,

Сүз тапмадым күкләр телендә.

Мин талынып тетрәп карап калдым –
Җирләреңә киттең күгемнән.
... Телләр бит ул күңел көзгеләре,
Ялгышмаган телләр-күңелләр:
Күктән торып сине сөймим инде.

## БЕЗНЕҢ СЕРЛӘР

Ул яз ярсу һәм ямансу иде.
Яндым. Ташкыннарда коендым.
Күңлем ачтым – анда тик син идең,
Серне белдең дә син – суындың...

Язлар саен күпме ярсысам да,
Үч алыр дип мине уйлама.
Тик, тиргәмә, - безнең матур серләр
Таралдылар инде дөньяга.

Яндым. Ташкыннарда коендым да
Сер сыярлык җиргә сыендым.
Безнең серләр – җырда. Үчем түгел,
Бүләгем бу сиңа, күз нурым:

Сине саклыйм бит мин җырларымда –
Һаман шул ук яшьсең, кайнарсың!
Үз-үзеңне сагнып тилмегәндә,
Җырларымны эзлә - табарсың.
Үзеңнән син миңа күчкәнсең дә
Серләремә сарылып калгансың.

## УРМАН ҖЫРЫ

Урманнарга барам карлар ерып,
Урманнарда язгы ярым бар.
Анда һәрчак кошлар, ак ландышлар,
Анда һәрчак яшел каеннар.
    Ай-ай-ай ук... Акланнары калган
    Ландышы юк...
    Оялары калган – кошы юк...
Карлар баскан яшьлек урманымны,
Аһ, тапмадым дустым юлларын!
Бураннарга кушылып еладым да
Озын-озын уйлар уйладым.
    Ай-ай-ай ук... Оялары калган –

Кошы юк ла...
Гәүдәләре йөри – ушым юк...
Ничек китим яшьлек урманымнан?-
Монда минем тиңсез ярым бар!
Ул бер чыгар төсле, ландыш тотып,
Бер яшәрер төсле каеннар!
Ай-ай-ай ук... Оялары калган –
Кошы юк ла...
Күңелкәйләремнең кышы юк...

## ТӨНГЕ КҮЛ ХӘТИРӘСЕ

Таллар суга төшкән иде
Бөгелеп,
Әйтмәдең: “Син талдай моңсу!
Бүген!” – дип.
Ә талларның тибә иде
Йөрәге.
Йөрәк тарткан зәңгәрлеккә
Төбәлеп,
Алар җылы бер дулкынга
Зар булып,
Яши иде салкын суга
Сарылып.
Син сизмәдең. “Кая, - дидең,-
Карыйсың?”
Төнге күлдәй салкын иде
Тавышың..

Йөрәк тартты... Ләкин сиңа
Сыенып
Утырмадым. Таллар яши
Сыгылып,
Ә мин киттем биек ярга!
Йөрәгем
Калды ләкин почмагында
Көймәнең...

Бик моңаям шул йөрәккә
Зар булып.
Тик яшәмим салкын суга
Сарылып.

## СИРЕНЬ ЧӘЧКӘЛӘРЕ

I

Чәчләреңә чәчәк казармын дип
Ничә язлар сирень үстердем!
Үзеңне дә минем чәчләремә
Сирень үргән итеп төш күрдем.

Ләкин хисләр яшрен бөре иде
Яшьлектәге яшел айларда.
Әй, шул сирень...
Чәчкә калдырмыйча,
Чәчәк килеш калды җаннарда...

Өзмәсәң дә, сирень чәчкәләре
Коелалар икән беркөнне...
Безнең үткән гомер –
өзелмәгән
Сирень чәчкәләре шикелле!

Юк, сыкрамыйм
бергә калмадык дип,
"Тормыш" дигән парлы уенда.
Минем җырым бары өзелмәгән
Сирень чәчкәләре турында...

2

Күз сал әле язга бер генә:
Май куенынннан сирень сибелә!
Күз сал әле миңа бер генә:
Мин шулкадәр мохтаҗ сиреньгә!

Майдан сирень алып бирегә
Сөйгән ярым бар син генә.

Чәчәкләргә башын куяр идем,
Яшьлегемә кайтып урар идем!

Ул яшьлектә яши бер кеше –
Тартмый аны сирень хуш исе.

Күңеле каты аның таш төсле,
Яшь һәм матур үзе – яз төсле...
Мин аңардан сирень көткән идем,

Көтеп алалмыйча киткән идем...
Сукмагыма рәнҗеш сипкән идем!
Сирень тотып шуннан үтәр идем!

Булчы зирәк – бүләк ит сирень,
Яшьлегемә күренеп килим!

Аңламыйсың син дә, бер генәм! –
Бәхетем юктыр инде сиреньнән...

3

Берәү генә синнән сорар сүзем,
Сергә каршы серләр әйт әле:
Мин күрәчәк түгел илләрендә
Сиреньнәрең чәчәк атамы?

Әй, сиреньнәр, шау бөредә иде!-
Байлык итеп саклый хәтерем.
Тик мин аның кадрен белми идем...
Инде беләм!
Ләкин... фәкыйрьмен!-
Сиреньнәрдән сыңар чәчәк тапмам –
Бөре килеш алар кипте инде.

Беләсеңме? – мин бит һичбер вакыт
Чәчәк аталмадым шикелле!..
Шуңа микән, сирень бөдрәләнсә,
Үткәннәргә күңел кайта әле:
Син дә минем кебек түгелсеңме?-
Сиренез чәчәк атамы?

“Әйе” дисәң, чын, шатланыр идем,
“Мин чәчәкле җанны сөйдем” дип...
“Бакчасында минем исемгә дә
Ачыладыр әле бөре” дип.

Бер тәлгәш тә бүләк итмә - алмыйм!
Тик бакчаңны гына ач әле!
... Гомерем буе белә алмам инде –
Сиренегез чәчәк атамы...

4

Яз тартамы, кан тартамы,
Бер кайтаммы шул илгә!

Әй, зарктым өй артында
Рәнҗеп калган сиреньгә!

Төнлә килеп “Әйдә” диеп
Чәчемнән тарта минем.
Ничек шулай тартасың син?-
Җаның бар мәллә, сирень!

...Әллә минем җаным калды
Тамырларыңда синең?..

5

Яз соңлады быел, соңлады.
Әллә көттерергә уйлады.
Мин көтәргә инде күнеккән,
Тик сиреньнәр көтмәс кебекләр.

Чәчәк чакта мин дә шул идем –
Салкын язда ачылып коелдым!..
“Ашыкма! Чын язны көт!” диеп
Бөрене шул булмый көттереп.

Бөре чакта чәчәк ни белә! –
Салкын тияр инде сиреньгә...

Яз соңлады, тагын соңлады,
Тагын шаярырга уйлады!
Минем белән инде шаярма –
Мин ышынмыйм хәзер язларга.
Сирень көтәм ләкин һаман да –
Сындырмыйча сынап карарга...

Мәрхәмәтле бул, яз, сиреньгә!
Сиреньнәр бар әле күңелдә.
Чәчәкләргә күмелеп йөрергә
Күңелләрем әле һаман тилмерә!

***

Җавап көне ерак иде,-
Әзерләнеп бетмәдем.
И Ходаем, каршыңа да
Килгәнемне көтмәдең!

Ашыгу гадәтләрем бар,
Ачуландыңмы шуңа? –
Теге дөнья сынауларын
Җирдә үк бирдең миңа...

Могҗизалар күтә идем
Җирдә табылмый торган,
“Ыргытыйм!– дидеңме – бирсен!
Мин могҗизадан туйган!”

Син дә ашыктыңрак сыман,
Син дә кызурак сыман...
Соң, сиңа яраган – миңа
Нигә ярамый, Ходам?..

## 9 ЯНВАРЬ, ПРИНСТОНДА БЕРЕНЧЕ КАР

Унҗиде кат яфраклардан котылдык инде.
Кап-кара калган агачлар күк булдык
инде.

Коелып төште, үксеп очты,
кышка калмады!
Кызгануымы язмышның, әллә җәзамы?

Әллә бушлык газабында сынавы микән?
Яфраксыз калгын агачлар еламый икән...

Югалтасың югалткан да ялгыз-ялангач,
“Мин бар микән, юк микән?” ди
йокы аралаш.

Уян! Куркыр нәрсә беткән –
үлем җиңмәгән!
Саргайткан яфрак сагышы,
тамыр шиңмәгән!

Елата да, юата да – гадел табигать.
Һәм яратмый ул бушлыкны,
кар сибә җырлап:
“Бергә кар булган идек, бергә ак булыйк!”
Агара кара ботаклар, карларга чумып.

Алла бирсә, калмас әле кара җире дә -
Ялгыз башым агарырга өйрәним генә!

Мин төшләремнән кайтып киләм кебек
өнемә:
Кар кочаклап, башны салдым язмыш
иңенә...

## ЯЛГЫЗЛАР ИЛЕНДӘ

Әй, куркытып җилләр улый,
Өермәләр өерелә.
Мин курыкмыйм бернидән дә, -
Алчы мине өермә!
Бергә керик океанга,
Яңгырлар булып чыгыйк.
Су бассын, сагыш басканчы,
Давылга качып җылыйк!
Күптер качып җылаучылар-
Көн дә давыл тилерә.
Мин генә җитмәгән икән
Бу давыллар илендә...
Хәер, болар чыга белә
Судан да коры килеш.
Су баса дип яшь коймыйлар,-
Монда – шат булу тиеш!
Зарлыларны яратмыйлар.
Елмаерга – бу илдә.
Мин оныткан елмаюны –
Алчы мине, өермә!
Куптар таш булган җиремнән,
Теләсәң кая ыргыт!
Йә - коткар кеше булудан,
Икәү өермә булыйк!

Яки - өйрәт елмаерга,
Чын йөземне үзгәртеп.-
Кешеләр елмая белә,
Ялгыз димәсеннәр дип.
Ялгызларны яратмыйлар,
Яшерелгән ялгызлык
Елмайган тешләр артына,
Зарланырга зар булып...
Мин дә тешне кыскан ла ул,
Җаным күздән түгелә...
Мин генә җитмәгән икән
Бу ялгызлар илендә!

## ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Күршемдә - зират,
Гел чаң кагалар.
Ташландык этләр,
Эре каргалар.
Тузганак баскан
Биек үләнлек.
Үзе эч поша,
Үзе түзәрлек.

Кара сакаллы,
Көчле бер егет
Тарта каядыр,
Кочып та үбеп.
Вәгъдәләр бирми,
Аңлатмый берни.
Тик буйсынасың,
Ак-кара күрми.

(Бәхеттән генә
Китәсең килми. –
Зираттан бәхет
Көтәсеңмени?!)

Аңга киләсең
Яңа урында.
Эре тиеннәр
Карга урнында.
Кыргый этләр юк,
Ыспай чирәмлек.
Нигә эч поша?
Түгел түзәрлек!
Ах, монда да бит-
Күршемдә зират!
Чиркәү чаүнары
Уята чыңлап...
Бәхетем зираттан
Булган алда ук!..
Акыл-ак сакал
Качты гарьләнеп!
Зират кошлары
Сайрый тирбәлеп.
Ул көлә - бизгән
Ирләр шикелле.-
Кара сакаллы,

Язмыш исемле...

***

Ак калфакның каралган чагы...
Иске җырның яңарган чагы.

Ак калфакның ертылган чагы.
Үткәннәрнең онтылган чагы.

Ак калфакның югалган чагы.
Горур башның хурланган чагы.

Ак калфакның ташланган чагы.
Җаннарымның тапталган чагы.

Ак калфакның салынган чагы.
Йөрәгемнең ярылган чагы.

Ак калфакның энҗесез чагы.
Каргышларның җиңгесез чагы.

Ак калфакның таушалган чагы.
Ходайның да ташлаган чагы.

Ак калфакның урынсыз чагы.
Язмышларның узмышсыз чагы.
Ак калфакның бизәксез чагы...
(Җырларның да кирәксез чагы!)

## СӘНКСГИВИҢ[1]

Нинди күркәм гореф-гадәт –
Сәнксгивиң.
Бай булып та юмарт булмау
Ямьсез бүген.
Ун кадаклы күркә пешә
Һәрбер мичтә.
Америка рәхмәт укый,

[1] *Сәнкс* – "рәхмәт", "*гивиң*" – бирү. 1620 елда Америкага йөз пилигрим – чит ил кешесе –килгән. Кыш чыкканчы аларның байтагы ачтан, салкыннан, чирдән үлгән. 1621 елда – Англиядан Америкага яңа тормыш башларга дип килеп, бәлагә дучар булган ул кешеләргә Американың төп халкы – индиан (индеецлар) ярдәм итеп, аларны үлемнән коткарып калган. Алар өч көн дус булып бәйрәм иткәннәр, табында күркә, кабак, көрәнбери – саз җиләге булган. Шул көннән башлап, ноябрьнең дүртенче пәнҗешәмбесе Америкада милли бәйрәм санала, Сәнксгивиңдә беркем дә эшләми, һәркем күркә пешереп бәйрәм итә, ярлы, эшсез, өйсез саналучыларга бушлый да күркә өләшәләр.

Бәйрәм итә.
Шөкер итә бу дөньяда
Булганына.
Шөкер итә түзеп торган
Ходаена.
Бөтен бер ил әйләнә дә
Бертуганга.
Күркә тотып, башын ия
Индианга:
Үз җирендә яшәр урын
Биргән өчен,
“Кунагым!” дип күркә тотып
Килгән өчен.
Кунак ашы – кара-каршы
Дигән мескен.
Ашка каршы таш атуны
Каян белсен!
Каян белсен әйләнәсен
“Индианга”,
Исеме дә онтыласын
Бу дөньяда...
Каян белсен кырылып җиргә
Әйләнәсен,
Әкияткә әйләнгәчтен,
Җәлләнәсен!
Елга бер көн – ул мескенгә
Рәхмәт әйтү:
Каргышлары төшмәсен дип –
“Сәнкю, сәнкю!”[2]

***

Һич юк иде үз күңлемне
Күрә алмаганым –
Гел фаш итеп торган өчен
Телнең ялганнарын.
Күзләремнән качкан яшьне
Җыеп торган өчен.
“Коргаксыз үл!” дигәндә дә,
Ташып тулган өчен.
Һич юк иде өметләрне
Буып үтергәнем.
Бетеп беткән өметне дә
Газап кичергәнем.
Һич юк иде эчемдәге

[2] *Сәнкю* – “рәхмәт сиңа”.

Җанны сөймәгәнем.
Эч өзелсә, “Өзелеп чык!” дип
Теләк теләгәнем:
“Өзел! Сызлан! Явызлан!” дип-
Ләкин чыкма эчтән!”...
Кара эчкә әйләнүләр
Шушы була микән?..
Эч белән тыш шушы кадәр
Аерылыр икән!
Хис белән сүз шушы кадәр
Дошман булыр икән!
“Үз эченә бикләнү” дип
Кемдер исем куйган.-
Хуш... Мондый ачыларны да
Күрүчеләр булган.
“Бар без генә түгел!” диеп,
Такмак әйтеп йөрим.
Мине тере итеп тоткан
Син генә бит, телем!
Мине саклап дөреслектән,
Гөнаһ җыйдың, мескен...
“Телең корсын!” димә, Ходам!-
Үзең шулай иттең...

***

Көнме? Төнме? Кем бу? Минме?
Абау, каңгылдаулары!
Нәнәйнең казлары кебек
Каңгылдыйлар, карәле!

Мин – монда татар баласы
Каз арасында үскән,
Кыр казлары киткән чакта
Һаман уянам икән!
Уянам уяу йоклаудан,
Тереләй үлгән җирдән,
Бу исәнгерәп йөрүне
Яшәү дип белгән җирдән.
Ни икәнен белмәсәм дә,
Сөю дәрте уяна.
Хәттә бәхет бардыр кебек
Казлар булган дөньяда.
Уяна газиз тантана:
Туганнар килгәнмени!
Нәнәй җиңнәрен сызганып

Кунаклар сыйлап йөри...
Мин дә пәйда булам шунда
Үзем килеш, чын килеш.
... Үзен югалткан кешегә
Сагыну да - сөенеч.
Сагыну сөеп уята,
Өмет кылын тибрәтә:
“Кыр казлары күрдең әле,
Исәнсеңдер!” дип әйтә.

***

Кыр казлары кышны сизә,
Кычкыралар илереп.
Шул авазлар бирә микән
Канатларга җиңеллек?

Җиңел чаклар бар иде ул!
Хәзер җанлы таш кебек.
Бер аваз да чыгармыйбыз –
Ташка әйләнгән каз кебек...

Тик канат җәелгән килеш
Һәм озын муен текә.
Эчтә казлар кычкырса да,
Без дә текәлек җитә!

Йөрәк тулы ачы тавыш,
Өзгәләнеп, алгысап!
Нинди биек очар идем,
Шушы йөрәк ярылса!..
Уф йөрәгем димәс идем,
Каңгылдаган каз булсам...

***

Көн-төн яңгыр коядыр,
Океан якынгадыр.

Күңелем хәле бик сәер,
Кешеләр сәергәдер:
Шар ачылырга әзер,
Ачыла белмәгәнгәдер.
Бик ягымлы, бик сабыр,
Гаепләре баргадыр...
Хәл сораучылар күптер,

“Ярдәм сорама” диптер.
Бүреләр дә җанлыдыр,
Сарыкларны җәллидер –
Ит кенә ашап торадыр,
Үләнне калдырадыр...
Бай илләр ул шулайдыр –
Киң күңелле буладыр.

Бай, гомүмән, сәердер,
Бар дөньяны җәллидер.
Ә байлыктан көләдер,
Тишек ыштан киядер!

Әллә уйнап киядер,
Әллә чынлап җүләрдер...
Шырык-шырык көләдер,
Фанны[1] гына сөядер.

Кемдер карап торадыр,
Күп-күп акыл җыядыр.
Америка ача-ача,
Аптырап та куядыр –
Минем кебек буладыр.

Көн-төн яңгыр коядыр.
Чын су микән бу яңгыр?

***

Тарагын ташлады – урман булды,
Яулыгын ташлады – күл булды.

Тарак төште, мөмкин иде тотарга.
Тик тотмадым – иелмәдем юк-барга.

Тарак төшкән: урман үскән, котырган...
Мин – нәзек тә сыялмаслык чытырмын.

Ни алда юк, ни артта юк яктылык.
Кайчагында яшен генә ялтырый.
Мин йөгерәм - өлгерәм дип, тотыйм дип!
Бер тубал утка әйләнеп очыйм дип!

Риза утлар дөньясына күчәргә -
Бу караңгылыкны гына кичәргә!

---

[1] *Фан* – күңелле, кызыклы

Юк! Яшен дә алмый мине – мин ямьсез!
Чәч кенә үсә урмандай иләмсез.

Тарагым юк, тузган чәчем-башларым!
Мин убырлы карчык була башладым...

Мәрхәмәт кыл! Кодрәтең бир, уф, Алла,
Түбәл хәтле утка калып очарга!

Канатсыз мин – очарга да яраксыз...
Булмый икән бу дөньяда тараксыз!

Тегесендә - убырга да охшамам,
Тараксыз калганыма да уфтанмам.

***

Җәй дә яңгыр, кыш та яңгыр,
Су да су.
Әллә кая сыеп бетә
Торган су.
Бу җир ничек агып китми
Чыдыйдыр.
Чыдау чикле, чыдау шикле,
Шомлыдыр.
Күпме сулар җыелмасын
Болганып,
Күз йомып йотып тора җир,
Хурланып.
“Эчем туп-тулы булганчы
Җыйыйм дип,
Елап акмыйм! Шартлаганчы
Чыдыйм!” дип.
... Ул шартласа, дөньяга ут
Кабар ич –
Хурланганның эче тулы
Яман көч.
Суларны да яндырыр ул,
Көл ясар.
Су бастырмый түзгән җирне
Көл басар.
Ул пышылдар: “Сизденме инде –
Көл булдык!
Көл булдык та икебез дә
Бер булдык”.

***

Ераклардан арып бер болыт килә,
Мине күргәч, туктап ял итә.
Ераклардан арып килгәннәрне
Арып беткән болытлар көтә.
Эчләренә суык кергәннәрне,
Туңып килгәннәрне каршылап,
Кояш балкый. Ләкин җылыталмый,
Туңган җаннар йөри калтырап.
Эчкә суык керү ни икәнне
Белми кояш, тора аптырап...
Нинди эссе! Чәчкәләр дә түзми,
“Коткар!” диеп елый әлсерәп.
Хыял зәхмәтенә тарганнарны
Болыт куып йөргән җил көтә.
... Чәчкәләрне өзеп суга куйдым.
Белмим, алар хәзер ни көтә...

***

Туктамастай койган яңгыр
Туктаган.
Төн чыкканчы яшел җирне
Боз сарган.
“Бар нәрсәне үз урынына
Куям, ди –
Вакыт Галиҗәнәпләре
Шулай ди. –
Ачулансам, кирегә дә
Борылам –
Су эчерәм төкереп киткән
Коеңнан!
Ашыкма, ди, көтеп көтек
Булма, ди.
Иске Җирдә яңа җырлар
Җырла”, ди.
Көтә-көтә күз күгәргәч,
Кемнәрдер:
“Бер болганмый, су да тынмый!”
Дигәндер.
Болганыр да тонар әле,
Туңмаса..
Әйләнә дә баса дөнья,
Бер баса!
Бер баса да аклы биреп

Йөдәтә.
Яңалык шул – Яңа җирдә
Иске мин.
Төкереп киткән коем юк –
Үкенмим.
Ә су туңган - өлгермәгән
Тонарга.
Мин болгаткан бер су да юк
Дөньяда.
Миңа шулай диеп кенә
Җырларга.

Ачтың ишегең,
Эчең ачмадың.
Үзең чакырдың,
Үзең – башладың.
Нәрсә теләдең?
Нәрсә эзләдең?-
Көтеп алалмыйм
Җавап сүзләрен.
Телләрең чишек,
Хисләрең бәйдә.-
Сөймәгәнгә бу
Сөйкәлүмәллә?..
Күзләрең ачык,
Ябык карашың –
Ничек син мине
Сайлый алгансың!
Тик асылымны
Аңлый алмассың-
Күңелгә бакмый
Торган карашың.
Мин – ихласлыкны
Яраткан нәсел.
Эчкә - дөрескә
Килә керәсем.
... Ә бәлки, юктыр
Синең ул эчең?
Бигең – бушлыкны
Күрсәтмәс өчен?
Шулай дип әйтик.-
Уйлау авыр бит
Серләрен яшереп,
Каршы алды дип,
Күзләрен яшереп
Озатып калды дип,
Башкалар өчен

Ачкычлары дип...

***

Утыз елдан соң яңадан
Канатым үскән иде.
Сынган канат кабыклары
Коелып төшкән иде.
... Әй, охшаган идең тәүге
Канатны куючыма,
Ләкин, еламыйча көлеп,
Җанымны кыючыга,
Үзе сындырган гомеремнең
Түрендә торучыга.
Бәлки, сихерләгәннәрдер,
Бәлки, язган маңгайга:
Кол була җаным, көл була
Җанны кыйнаганнарга!..
Сөймәгән саен – сөйкәлә,
Әй, сәләтсез каргышка!
Кабер түгел, Кадер кыла
Шул Сөюгә, байгышка...
Йолдызлар кабызып куя
Бикле күк капусына.
... Сайлмаган идем сине
Нәкъ шушылай булсынга.
Күзең төшеп, күңелең төшми,
Еламыйча көлсенгә,
Сәгатенә карый-карый,
Вакытны үтерсенгә...
Утыз ел. Сихер бу, сихер:
Шул ук тавыш, шул чырай.
Шулай ук – тарсылдап тудым,
Гөрселдәп үлдем – шулай...
Ымсынып кояшка мендем,
Егылып төштем кимсенеп.
... Йозаклы күк капусында
Балкып торсын исемең!

## НИК СИН МИҢА ТЕРК КИЛЕШ

“Дөньяны яратмыйм”, - дисең.
“Яшәвем - болай гына”.
Шуңа микән минем алда
Караңгы чырай гына.

Юк... Син мине яратмыйсың.
Шуңа күрә бугай ла
Сытык йөзле шәүлән генә
Калган бүген дөньяда.

Әй, бардыр бит якты Рухың,
Мәхәббәттән нурланган!
...Бәхетлерәк булыр идем,
Китсәң тизрәк дөньядан...
Рухлар мине яраталар,
Табалар килер юлны.
Үзең китсәң, Рухың миңа
Кайтып сыенып иде.-
Мәхәббәтле нурлы шәүләң
Мин генә күрә торган,
Балкып торган күңелемнең
Кадерен белә торган.
... Ник син миңа тере килеш?-
Кара коелып утырган!
Читкә карап, текә карап,
Үләсемне китергән!

***

Ярый, тиң күрмәдең инде.
Кем башыннан узмаган...
Гаҗәп түгел, гаеп түгел.
Ник ашкынам, уф Аллам!
Яңа тирeләргә кереп,
Каршыңа басмак булам,
Сөйдергеч сулары сибеп,
Күзләрен ачмак булам.
Тапмас борын югалтканын
Тезеп куям алдына,
Егып елатмаклар булам,
Якты бөркеп аңына:
"Күрмәдең мине! Ашыкма!
Ашыкма! Кара! Сына!"
Акылга зыян килмәгән.
Күңел шулай шашына.
Акыл көлә: "Ул югалта,
Ул кайгырыр, син түгел.
Ә син таптың – югалтмадың,
Сабак алдың син, сөен! –
Азларнымы ашкындырдың,
Кан елаттың, шаштырдың!

Мең каргышка лаек идең,
Бер җәзага тап булдың.
Бар да кайта. Бернәрсә дә
Югалмый бу дөньяда.
Инде белдең: хисләр түгел,
Сүз белән дә уйнама".

***

Югалып торган урынга
Елмаеп торган булсам,
Уйланып торган урынга
Кыланып торган булсам,
Уйлап сөйлисе урында
Уйнап сөйләгән булсам,
Сиздереп куясы җирдә
Сиздереп куйган булсам,
Көлдереп куйган урынга
Сөйдереп куйган булсам!
Алдагысын алдан белсәм, -
Алла теләгән булса...
Их, мин буталган булсам ла,
Юллардан язган булсам,
Киләлми калган булсам!

Ә син сул яктан түгел,
Уңыннан торган булсаң,
Сүрелеп торасы җиргә
Сөенеп торган булсаң,
Сөрлегеп куйган җиремнән
Көлдереп куйган булсаң,
Бетереп ташламас өчен,
"Сөй!" диеп куйган булсаң,
Үтереп ташламас өчен,
Бер чара кылган булсаң...
Йә сөйдереп куймас өчен,
Биздереп куйган булсаң!..
Их, син буталган булсаң ла,
Юллардан язган булсаң,
Туалмый калган булсаң!

***

Шатлыгыннан улый-улый,
Омтыласың ай нурына!
Бәхет шундый якын гына,

Бәхет шундый зур тоела!
Айны кинәт болыт баса,
Күктән ташлар ява башка!
Койрыгыңны кысып кына,
Сыенасың бер агачка.
Сөйрәләсең үз өнеңә,
Хәлсез генә, ятим генә.
Ыңгырашмый, дәшми генә,
Ана бүре яши бирә.
Эт өрер дә бүре йөрер
Эт каргышы төшмәс аңа.
Җан кыйганын бар да белә,
Кан җылавын – тик бер Алла:
Җиңел мәллә көчле булу,
Явыз булу, тешле булу!
Күмәкләргә, көләчләргә
Ят булу һәм үчле булу...
Таш җаныңны йомшартырдай
Урын тапмау зур Җиһанда,
Һәм әйләнү үз-үзеңне
Талый торган бер дошманга.
Баш та имәс, сер дә бирмәс. –
Димәсеннәр “Ятим” генә!
Яраларын ялый-ялый,
Ана бүре яши бирә.

## ВАКЫТСЫЗ БУЛДЫ

Вакытсыз булды,
Урынсыз булды,
Озак киленде,
Китү тиз булды.
Соңлап күрештек,
Ашыгып “Хуш”, - дидек.
Очрашсак та, без
Аймылыш булдык...

Син – минем өчен,
Мин – синең өчен –
Шуны аңлап тик
Сискәнер өчен!
“Минеке иде!”
Дип калыр өчен.
Язмыш-явызга –
Шаярыр өчен...

Язмыш ул кайчак
Ярап та куя. –
Аймылышларны
Аяп та куя, -
Ай, хыял чиксез!
Вакыт чикләнгән.
Алда юл ачык,
Йөрәк бикләнгән.
Әйтер сүзләр күп,
Телләр тешләнгән...
Бер - Өмет көчле
Мөмкинлекләрдән.

## ҮЗ БАШЫМА

Бер өмет юк карашында.
Белмим, нигә генә яраттым!
Үз башыма, үз башыма!
Тик саклама мине, йа Раббым!
Камчысыннан бал тамармы,
Кан тамармы – бәхет санармын.
Аннан алган һәр ярамны
“Язмыш бүләге!” дип ялармын.
Таянырмын мин Иделгә,
“Эт” чә йөзеп, батып та калкып.
Биш артын күрсәткән дөнья
Алдын күрсәтер бит бервакыт?!
Күрсәтмәсә, ярар, бәхил...
Аның Иделендә калыйм тик!
Карап торыйм аңа һәркөн.
Бер күз салыр, бәлки, “Камыш” дип...
Үз башыма, үз башыма!
Соң, ник мине аңа караттың?!
Күрсәт - тик аңардан гына
Күрәчәкләремне, йа Раббым!

## ТАПТЫМ ДИГӘНДӘ ЮГАЛТКАЧ

Нинди авыр серләрең бар
Миңа килеп сөйләрлек,
Ләкин күңлең төбендәген
Күрсәтмичә генә бик?

Нинди юлларда адаштың
Миннән киңәш сорарлык,
Тик киңәшем кирәкмәвен

Яшермичә тыңларлык?

Нинди бәләләргә тардың
Миннән ярдәм эзләрлек?
Хуш килмәдем, куш килмәдем,
Тындың күңелсезләнеп...

Нинди җилләргә тап булдың
Миңа килеп чыгарлык?
Әллә җиле кире булды,
Әллә хәлең чыдарлык...

Хәлләреңә керергә мин
Бик әзер дә, бик риза.
Теләгәнең – бу түгел шул,
Теләгәнең – могҗиза!

Мин дә бер могҗиза телим,
Белмәгәч бүтән чара:
Бәлаләренең шундыена
Килеп тарысаңсана!-
Бер мине генә сайларлык
Бар сереңне чишәргә,
Бер мине генә табарлык
Хәлеңне хәл итәргә!

Кеше бәхетсезлегеннән
Бәхет теләмә, диләр.
Таптым дигәндә югалткач,
Нинди теләк телиләр?!

## ӨМЕТЛЕ ХӘЛ ТҮГЕЛ

Карашыңда шундый авыр моңнар.
Мин күтәрер дип белдеңме?
Җиңеләйтер диеп килдеңме?
Сүзең дә юк. Күз дә күз инде!
Карашыңда шундый авыр моңнар.
Әй, бу хәл дә баштан үткән инде!
Авыр моңны күтәрәлмим мин...
Үзем качам, үзем җәллим мин...
Әй, бу хәл дә баштан үткән инде!

Күлем шундый – миңа моңнар ага.
Әллә син дә шуны сиздеңме?-
Кичә-кичә күпме диңгезне,

Тапкансың бит – нишлибез инде?
Күлем шундый – миңа моңнар ага.

Яңа күлгә күченмәкче идем.
Каян әле шулай син газиз!
Соңгысыдыр: атсыз-йөгәнсез
“Җәллим-ташламыйм!” ди торган хис...
Яңа күлгә күченмәкче идем,
Таштан-ташка сикермәкче идем,
Җиңел хисләр кичермәкче идем,
Җиңел моңнан исермәкче идем!
Авыр моңнарыңнан бөгелдем,
Авыр дулкыннарга күмелдем,
Авыр өметләргә эредем –
Беләм өметле хәл түгелен.

***

Кыргый теләк тулы күзләр-
Утлы күмер диярсең.
Карама шулай тилмереп-
Намусыма тиясең!
Күзләремне чәнчеттереп,
Кадала да карашың,
Йөрәгемә үтеп керми-
Юкка адаланасың!
Тын алырга да куркыта,
Дәртең атылып тора.
И бу ихласлык каршында
Мин бит шау гөнаһ кына...
Шәмәхә чәчәкләрең дә
Корып утыра суда –
Күңелемнең күлләрендә
Юк шул сиңа тамчы да.
Кыргыйлыктан кызык кылып,
Кызыктырып, кылтаеп,
Яңа дөнья ачуым бу,
Җиңел генә юл табып.
Ә син “Көлүең матур!” дип,
Исереп беттең инде.
Мин дә болай булгач...җирдә
Гаделлек юктыр инде...

## ТӨШЛӘР ТӘМАМ!

Кызарып кояш батканны
Охшатам таң атканга.
Әллә гомерем таңнарын
Заяга югалтканга.

Таңнар шундый алсу иде!
Алсу – минем төс идең!
Акыл төсмени яшьлеккә!-
Мин бүтән төсләр кидем...

Таңнарны төшләргә бирдем –
Төсле, чуак төшләргә.
Килешмәгән төсләр киеп,
Килеп кердем кичләргә.

Инде – кием алыштырам,
Инде – яздым йокыдан.
Аллы-гөлле төшләр уңган,
Ләззәтләре онтылган.

Төшләр тәмам. Кичләр калган.
Алсудан киенәм дә
Керим кызыл шәфәкъләргә,
Нурларга коеныргa!

Кызыл кичтә мин матурмын,
Шулай диләр – ышанам.
Заяга үткәргән алсу
Таңнар өчен үч алам!

## ҺАМАН САКЛЫЙ

Өзелә дә өзелә,
Ватыла да ватыла...
Ник ташлыйсың, Музыка,
Мине авыр вактымда?

Ташлаучылар җитәрлек,
Бизүгә дә бизү тарта.
Хәттә газиз күңелем
Бер китә дә бер кайта.

Хәттә газиз әнкәем

Әйләндерде ятимгә -
Төшләремнән югалды,
Өннәремне әйтмим дә...
Төш күрү дә сагынырга
Калыр дип кем белгән!-
Кая качыйм көннәрдән,
Йокы качты төнемнән.
Теләк бетте, көч бетте
Качарга да үлемнән...
Кайда урын бар икән
Качарга үз-үзеңнән?!
Камыр уңмый – кул китте,
Җырлап булмый – хут бетте,
Күңел үсми, гөл үсми,
Бер сүз белән – кот китте.

Тик өзелә-өзелә,
Тик ватыла-ватыла,
Һаман саклый Музыка
Мине шушы вактымда. –
Шайтанга мач килүдән,
Өмет уты сүнүдән.
Ялгана да кыллары,
Яңрый упкын төбеннән:
“Кабык ташлау чире бу,
Төс ташламыйсың әле,
Карт чыбыкны чатнатып,
Чәчрәп чыгарсың әле!-
Таң туганда котылып,
Авызыңнан кош очырып!
Мәхәббәткә юлыккан
Шагыйрьләрдәй, очынып!

## КИПКӘН ЯФРАК ҖЫРЫ

Язмышым, исән калмышым
Тора тик җилдән.
Асылынып - үләлмичә,
Тартышып кибәм.
Җир белән күк арасында
Әллә нәрсә бу:
Төштәгедәй – үзе җиңел,
Үзе баса бу.
Төштәгедәй: тормыш- хыял,
Хыялда – бушлык.
Баш зыңап кибә бушлыктан –

Көннәр-көн уш юк.
Кем белгән юкка чыгарын
Ходай биргәннең!-
Эч тулы дәрт-дәрман иде,
Кадрен белмәдем.
Белмәдем хәзинә диеп,
“Шөкер!” димәдем.
И ходаем ала икән
Биргән бүләген!
Тере шәүлә булуларның
Белдем газабын –
Буш кешене сөймәгәнем
Өчен җәзадыр.
Хәзер ярдәм көтәм бары
Шифалы җилдән:
Гел дәрт тә дерт бу арада...-
Килерен сизәм...
Җир белән күк арасыннан
Алыр коткарып.
Ниләр күрәсем бар икән,
Тагын ышанып?..
Ни булса – шул. Янартауга
Очсам да бәхил.
Барбер тәмугка керәсе,
Барбер – Газазил!
Сал бер чаткы мин шәүләгә -
Кайтсын исәнлек! –
Эчкә баткан эчләремә -
Якты эчтәлек!

## ӘЙ, КАРА КОШ...

Әй, кара кош, кара кош,
Якынсың да акрынсың.
Хәер түгел ашыгыч.
Зәгыйфь корбан таптың син.
Чакма-чакма ташларга
Тырнак үткерлисеңме?
Нәрсә соң син! Мине дә
Күтәрәлмәм дисеңме!
Һи! Карга да күтәрә
Мине, телем булмаса!
Инде талган телем дә,
Төш! Көч җыеп булашма!
Батыр кара тырнагың!
Корбан булыйм үткенгә!

Күпме каным калгандыр,
Акса, агып бетсен лә!
Соңгы тыным булса да,
Чыксын иде Биектә!
Азык булыйм, Ходаем,
Күктә йөзгән киеккә!
Өзгәлә ак тәнемне,
Тынмасмы җан сызлавы!
Авызымнан җан чыкканда,
Көлеп куярмын бары.
Инде давыл котырса,
Тырнакларың ычкынса,
Әй, чәнчелеп китим лә,
Очыйм – кая очылса!

Күптән егылып упкынга,
Җиргә чыккан мин, байгыш...-
... Әллә тәҗрибәм барын
Сизденме, әй кара кош?
Кыядан һәлакәткә
Очудан тәм табалган
Мин, авыруны, кара кош,
Табып алдың кайлардан?!
Әй, кара кош, кара кош...

**СИН ГЕНӘ, ТИК СИН ГЕНӘ**

Юлдан-юлга, илдән-илгә
Саташып йөрүләрем
Сине эзләү булды, дисәм,
“Хак!” дияр сиреньнәрем.
Алар шиңеп бар инде,
Күрәлми йөзләреңне...
Җәлләмисеңмени син
Соңгы сиреньнәремне?..
Минем бәхетле көннәрем –
Бер атна бит бер елга.
Тик сиреньнәр җиргә түгел,
Җаннарыма коела.
Гомер буе коелганнар,
Җыелганнар җитәрлек.
Ах, сиреньле күңелемне
Бер син генә - иснәрлек!
Бер син генә - үрелерлек,
Бер син генә - алырлык.
Бүтән язлар да булмастыр,

Болай хыйлланырлык.
Сиреньнәрнең дә соңгысы
Күңелемә коела.
Бер атнадан – гыйшкый бакчам
Ябылырга җыена.
Тоталсаң, тотып каласың
Капкаларың син генә.
“Ашыкмыйча тор инде!” дип
Боералмыйм сиреньгә.
“Мәңге сиреньле бул!” диеп
Боералмыйм күңелгә.
Боерылган, булдыралган –
Син генә, тик син генә.

## ЮГАЛТУЛАР

Әллә нинди һавасыз дым,
Эллә пар, әллә томан.
Иләс-миләс тирә ягым,
Исәрләнергә торам.

Чирәм өсләренә чирәм,
Күзләремә күренми.
Тик бер бөртек бәбкә үлән:
“Анаң бармы синең?” – ди.

Аллы-гөлле төсләр уйный,
Кинәт караланалар.
Күзләремдә әлҗе-мөлҗе:
Бумы – минем балалар?..

Алда гына кебекләр дә,
Кинәт югалырлар кебек, -
Мин аларны балалыкка
Биреп торганмын кебек.

Тын алалмыйм – һава кала
Төер булып тамакта.
Беткәнме сулыйсы һавам?-
Теләсәң ни дип ата...

Йөгереп китәрдәй булам да,
Тарту көче юк җирнең.
Аяк астыннан җир китү –
Исеме минем чирнең.

Югалтулар белән бергә
Их, үзең дә югалсаң!
... Нәрсә дип атала икән,
Бу чирләрдән чыгалсаң?

***

Биш чат була сирень таҗында,
Сирәк кенә алты була.
Алтылысын тапсаң, уңасың –
Тиз-тиз генә ашап куясың, -
Үскәч, бәхетле кыз буласың.
Андыен да таптык – куандык!
Ләкин бәхетле кыз булмадык...
Җавап белә идек без анда
“Бәхет нәрсә?” дигән сорауга.
Ләкин безне бәхет читләде,
Һаман безгә нидер җитмәде:
Йә каш, йә теш, йә күз, йә керфек,
Йә чәч кистек, йә чәч үстердек,
Төрле-төрле төскә буяндык. –
Ах, без матурлыкка туймадык!
Һәм туймадык матур хисләргә,
Һәм туймадык матур кичләргә,
Матур көлмәккә дә туймадык,
Йокылардан елап уяндык!..
Юк, без бәхетле кыз булмадык:
Бураннар да булды усалрак,
Юрганнар да булды кыскарак.
Әй, ул бәхетсезлек басканы,
Хыялларның эшкә ашмавы!

... Әй, шул чакның татлы яшьләре,
Теләкләрнең күккә ашканы.
Безне ташлап күккә ашканнар...
Җирдә калган – бәхет тапканнар.
Ә без кайда? Бәхетлеме без –
Алты чатлы сирень тапканнар?
Авыр хәзер бирү җавапны,
Тик теләгем һаман – гел алты.
Әй, ник җитми икән биш чатлы?!
Ник ашкынам икән бу чаклы!

***

Әллә күренә белмәдем,

Әллә карый белмәдем.
Күрмәсәм дә күрмәм икән
Мөхәббәтнең йөзләрен!
Сөйдергечләр куйдырмадым,
Язмыш язганын күрдем.
Сөйдергечләр койдырырлык
Затлар алдадыр дидем...
Кудым кулдагы чыпчыкны,
Күктәр торна тотмадым.
Берсенә дә тиң күрмәдем
Күңелемнең кошларын.
Ах, күңелемнең кошлары!
Ал кирәк тә, гөл кирәк...
Сезнең көйгә җыр җырларга
Белмим, ниндиләр кирәк! –
Гөр-гөр итә торганнармы,
Чүт-чүт итүчеләрме?
Каргыйм сезне – ялгызлыкка
Дучар итүчеләрне!
Сихри авазлар чыгарып,
Кабатлап шуларны,
Кол итеп тотасыз мине,
Биздереп былбылларны.
Шулдыр – Язмыш китабының
Миңа дигән битләре!
Язмаса да, язмас икән
Мәхәббәт бәхетләре!..

## СӘҮДӘГӘРЛӘР ҖЫРЫ

Берәмләп тә сатабыз без,
Миллионлап та.
Сигарет та сатабыз без,
Самолет та.
Таз-казаннар тишелеп бетте,
Ямап торма!
Илкүләм талчуктан читтә
Кала күрмә!

Их!
Паровозлар һәм "КамАЗ" лар,
Һәм дә противогазлар,
Алтыннар, бакырлар, җизләр –
Берсе дә калмыйдыр бездән –
Бизнес барысы да!

Бер кәгазьдән бер кәгазьгә
Күчә тауар.
Күренми ул гади күзгә -
Серле базар...
Сафсата да сатабыз без,
Фәлсәфә дә.
Алтыга алып, бишкә сатсаң,
Ул да сәүдә.
Их!
Сәясәтләр сата-сата
Һәм гайбәтләр сата-сата,
Юклык чакта, кытлык чакта
Булабыз без депутат та –
Бизнес анысы да!

Демагогия сатабыз –
Ал, ач халык!
Вагон-вагон чит илләргә
Бүтән байлык.
Шуларга чыгарабыз да
Кырып-себереп,
Беразын кире бирәләр
“Кредит” диеп...

Их!
Тимер кирәк, күмер кирәк,
Ком да кирәк, бур да кирәк,
Корал кирәк, уран кирәк, -
Чимал кирәк, чимал кирәк
Заграницага!

Бәхете тиң булмас инде
Бәндәләрнең. –
Һаман байга байлык керер
Сәүдәләрдин.
Тик шулай да хәерченең
Күңле төшми.
“Байлар – бөлер, без – бөлмәбез!
Фәкыйрь – вичный!”

Их! Терекөмеш сатасызмы?
Ләчтит сатып ятасызмы?
Сатсаң да син, сатмасаң да,
Мич башында яталсаң да,
Барыбыз да шул базарда –
Юк, диләр, бит соң аңарга

Алтернатива!

## ЗАМАНА МАНЗАРАЛАРЫ

**Халык җырлый**

Су буенда кыяк үлән
Кыеп аласы калган.
Мәңге ачыкмаслык итеп,
Ашап каласы калган!
Җыр тыңлаган егетләрнең
Ике күзе ут булсын!
Аракының хакы төшсә,
Путыч булмый, чурт булсын!
Уйныйбыз да җырлыйбыз да,
Гармун кулларыбызда.
Президентка Алла бабай
Килсә генә, без риза.
Тау башында тимер капка
Ачыла да ябыла.
Җырлаучылар ярлы була,
Урлаучылар бай була.
Алга дибез, алга дибез,
Алга таба барабыз.
“Күп ашасаң, әз ашарсың!”-
Дигән Ленин бабабыз.
Алга дибез, алга дибез,
Якты тормыш корабыз.
Бар булганын ашап эчтек,
Инде туктап торабыз.
Әнә килә бер машина,
Төягәннәр чемечке.
Һаман ач тора белмибез –
Ул нинди перивечке!
Башларымның ни уйларга
Белми торган чаклары.
Терапиясыз иттеләр
Безгә дигән шокларны.
Алма бөреле, алма бөреле,
Алма чәчәге төрле.
Шаклар каткач җырлар җырлыйм
Шоклар сукканнан бирле.
Син дә мулла, мин дә мулла,
Атка печән кем сала?..
Заграницы коткармасмы,
Басып алып булса да?!

## ОКЕАН АРЪЯГЫНДА

Ак күлмәгем киеп алдым –
Сөмсерем коелмасын!
Илдә калган чыраем
Мине танып, елмайсын!

Ак – ул күптән төс миңа,
Кәфен төсе булса ни!-
Океан аръягында
Бер үлемнән курка ди!

Океан аръягында
Бер тәңкәгә бер күлмәк.
Тик аны киялырга
Кайбер нәрсәләр кирәк:
Җыйнак, нәфис сөякле
Гәүдәләр мисал өчен –
"Йөз тәңкләлек күлмәк!" дип
Карап калсыннар өчен.

Ак киябез әле,
Иң аруы - без әле.
Юанаймыйбыз билләрне,
Яши беләлебез әле.

Ә курка торган күлмәк
Кимәдек, кимәбез дә.
Булсын кәфен төсе ак –
Ансына көймәгез дә.

Океан аръягында
Үлү күпкә җиңелрәк.
Яшәү – очсызрак монда:
Бер тәңкәгә бер күлмәк.
"Гомер кадерсезрәк"
Дисәм, булыр күберәк.
Һәм хаҗәтсез ак күлмәк!-
Тагын нинди сүз кирәк?
Океан аръягында
Без шулай – "җиңелрәк!"

## АЛМАГАЧНЫҢ АК ЧАГЫ

### Җыр

Алмагачның ак чагы,
Күңелнең йомшак чагы,
Гел-гел генә алай булмас,
Шундый чакта кайтчәле!
Күңелнең исәр чагы,
Могҗиза көткән чагы.
Шаяртсаң да, шатланырмын:
“Яратам!” дип әйтчәле!
Хәтернең начар чагы,
Аз-маз алдашкан чагы...
Алдашсаң да, ышанырмын:
“Яшьсең!” дип әйтчәле!
Алмагачның ак чагы,
Күңелнең чәчәк чагы.
Чәчәк гомере җил кулында,
Җилдән узып кайтчәле!
Алмагачның ак чагы,
Аңлауга мохтаҗ чагы.

## УЛ ЧЫДАРМЫ?

Битем бар да, чыраем юк.
Көзгегә карамыйм да.
Беркемнең дә күргәне юк
Минем чын йөземне монда.

Минем йөзем – телемдә бит,
Ә телемдә - бөтен дөньям.
Алар юклар бу тормышта,
Тик, ни гаҗәп, югалмыйлар!
Киләләр дә күзләремә,
Тик торалар тилмерешеп.
“Мин үзем дә юкмын монда,
Чыгарыйм, дим, сезне ничек!”

Гөлләр генә гөл җанлылар,
Тел җанлылар, моң җанлылар.
Алар минем күзләремнең
Карашына чыдамыйлар.
Чыдамыйлар мин үзем дә
Ишетмәгән җырларыма.-
Тыңлап-тыңлап торалар да

Шиңәләр дә күз алдында..
Мине беркем күрми монда,
Анысынада бер кайгым юк.
Әнкәй күрсә, нишләр менә...
Ул танырмы? – Чыраем юк.
Ул бит гөлдән ныграк сизәр,
Үземнән дә ныграк хәтта...
Кайсы чакта кайтып күрим?
Чыдар микән – исән чакта?..

## КЫШКЫ УРМАНДА

Һәрбер чыршы ботагында,
Кар исенә исереп,
Ап-ак аю балалары
Йоклап ята күпереп.
Егылып төшеп еларлар дип,
Куркам хәттә суларга.
Әй, кысып сөясем килә,
Кычкыртып бар урманга!
Беләм: бу гаҗәп сурәтне
Иҗат иткән кар гына.-
Тезеп салган балаларын
Чыршы ботакларына.
Мөгаен, ак аю булган
Ул – кар түгел чагында.
Йоклаган баласын җуйган
Котып бураннарында.
Аны һаман онталмый ул,
Бәргәләнә, ярсый ул.
Елый-елый үз тәненнән
Ак балалар ясый ул!
Тик басалмый ярсуларын,
Чын түгел балаларын
Өзгәли дә берәм-берәм,
Үкереп үкси тагын!..
Карлардан баласын эзләп,
Үзе кар булган аю!
...Балалы хатыннар гына
Аңлый буран улавын.

## ГОМЕР ИКЕГӘ ЯРЫЛГАН

Гомер икегә ярылган,
Салып булмый күпер.
Теге яктагы яртысын

Җәлли-җәлли үттем:
Азая, дип, ага ла, дип,
Хәләл гомер суга.
Кимегән саен җәлерәк
Булыр иде сыман.
Әйтерсең лә, елга кинәт
Агышларын борды:
Хәзер көннәр шундый озын
Һәм кадерен җуйды...
Шундый озын һәм кирәксез,
Төссез, ямьсез, тәмсез.
Әллә җәннәттә микән мин –
Уйсыз, хиссез, гамьсез?

Урыным әзер – тәмугта,
Тик кызганып, Ходай:
"Башта җәннәт газапларын
Күрсен", диде бугай...

Әйе, ярты гомер белән
Оҗмах та – бер җәза.
Ашым хәрәм, башым вәйран,
Елгам ялгышып ага.

Гомер икегә киселгән,
Юк тегәрлек җепләр...
Гомремнең хәрәм яртысын,
Ходай, тизрәк үткәр!

## КАРЫНДАГЫ БАЛА МОНОЛОГЫ

Җирдә тынычлык.
Рәхәт, рәхәт, рәхәт.
Үсим тырышып
Ятрәк, ятрәк, ятрәк!
Өлгерерменме
Яшәп, яшәп, яшәп? –
Баса ди Җирне
Афәт, афәт, афәт...
Сез ул барын да
Күргән, күргән, күргән.
Мин яңа гына
Тибәм, тибәм, тибәм.
Сез – саф һавада
Көн-төн, көн-төн, көн-төн.
Калдыр балага –

Эчсен, эчсен, эчсен
Һаваны, суны
Капсын, капсын, капкын!
Ах, су булуны
Татыйм, татыйм, татыйм!
Тормыш туган һәм
Булсын, булсын, булсын!
Ә мин тумасам?
Сусыйм, сусыйм, сусыйм...
Яшәүне тәмләп
Карыйм, карыйм, карыйм! –
Көрәштә яулап,
Алдым, алдым, алдым.
Җиңү алмасын
Кабыйм, кабыйм, кабыйм!
Дөнья аңласын –
Кагыйм, кагыйм, кагыйм!

## ӨМЕТЛӘР

Яшел күзле кызым туса,
Яшел күлмәк тегәрмен.
Каермын да кайгырырмын –
Килешми дип йөдәрмен.
(Ни кылсам да, килештермим –
Чамасызрак теләгем.)

Дәртле-хисле улым туса,
Эскрипка алырмын.
Көе килсә-килмәсә дә,
Биермен-юанырмын.
(Һич табалмый үз көемне,
Бии-бии арыдым...)
Яңа-көя тегеләр дә,
Көлә-көлә киелер.
Җырлый-җырлый биелер дә,
Елый-елый сөелер.

Үтәлмәгән теләкләрне
Басар татлы күз яше.
Бөек Яшәү көен табып
Җырлар сөю чишмәсе!
Яшел күзле кызым булгач,
Аерылмам яшьлектән.
Дәртле-хисле улым булгач,
Кипмәс илһами чишмәм,

Мин булырмын Әбелхәят
Чишмәсеннән су эчкән!

## ҖИР ШАРЫНДА

Керләр кибә бавында,
Бала тибә карында.
Җир йөрәге ярсып-ярсып,
Ургый кайнар магмыда.

Яңгыр яуса, кер кипми,
Йөкле чакта тын җитми.
Җирнең үз хәлләре хәлдер –
Аңлата тетри-тетри.
Гаме күп шул аның да:
Яше уртача гына,
Ә магмалар сүрәнәя,
Юл юк – ялкын чагына!
Җылың беткәч, кем инде син
Бу Галәм кочагында!

Ахыр заман юк, диделәр,
Әй, Җиркәем, кайгырма!
Урын юк ла кайгыга:
Яшь тә уртача гына,
Бала тибә карында,
Керләр кибә бавында.
Җилләрдә җилкенеп йөрим, -
Исәнлек Җир шарында!
... Тик күктә үлгән йолдызлар...
Куркыта шатланырга...

## БӘБИ ТУГАЧ

Буш урын юк. Бөтен урын
Туп-тулы.
Һаваның һәр күзәнәген
Тутырды.

Чынаяклар ташып тора
Буш көе.
Монау мендәр шартлый инде,
Шыр тиле.

Һәр нәрсәгә иңгән бөек
Тантана.

Һәм һәрнәрсә бөек эшләр
Башкара:

Элгән керләр әнә ничек
Тырыша.
Бии-бии пешә бүген
Бу ботка.

Сөтле чәйнең кукрайганын
Күрчәле:
Бүгенге көндә иң мөһим
Персоны! –

Аннан башка сөт төшми бит
Әннәгә.
Бар ашамлык әллә кемгә
Әйләнгән!

Гади түгел икмәк-тоз да,
Сөт-май да. –
Хезмәтләр Солтан дигән
Малайда!
Һәр гамәлдә мәгънә хәзер
Һәм файда.

***

Әй, Кояш, кабул ит
Тагын бер улыңны!
Ул – синең бер серең,
Саклаучы бул инде!

Табынган кояшлар
Булдылар күп кенә.
Тик чыны – син генә
Калдың баш өстендә.
Ай, рәхмәт! Улымны
Тик шушы көн килгәч,
Тудырдың, тик нурың
Кимүгә бит, Кояш!
Мәңгелек кыш яный
Улыма һәм җиргә.
Без сине нишләттек?
Син Алла идең лә!
Һәм газиз улларың
Алалар котыңны:

Йә “кара тишек”ләр,
Йә “озон бушлыгы”...
Инде син үзең дә
Мохтаҗсың яклауга...

... Кешеләр синнән дә
Көчлеме, йә Алла?!
Алармы үзләре –
Кояшны сакларга?
Кабул ит улымны
Син шушы сафларга!

## ЙОМШАК КҮҢЕЛЛЕ МАЛАЕМА

Ялгыз калдыралмыйм сабыемны,
Йомшак тотам – үзем бозам шул.
Әй, өлгерер әле төзәлергә,
Ялгыз калырга да – дөнья шул:
Миллионлашып, өелеп яши халык,
Ә кешеләр ераклашалар.
Күпме тәкә башы бер казанда! –
Һәм һәрберсе ялгыз баш алар.
Таш казаннар, улым, таш калалар!
Күз яшьләре үтмәс ташлар ул.
Өйрәнерсең син дә сыкрамаска...
Елап кал ла! Бетсен яшьләрең!
Нинди генә итеп бу тормышка
Чыгарыйм соң сине, бәбкәем? –
Елак булсаң, ташлап китәрләр лә,
Тыйнак булсаң, таптап китәрләр!
Таш йөрәкле итеп үстеримме,
Җан урнына кабан теш куйыйммы,
Яки “Сөзгәрәк бул!” диимме?
Ходай биргән – мин үзгәртәлмәм...
Әй, үзеңнең гүзәл бу нурыңны
Ит, Ходаем, лаек урынлы!

## ТӨПЧЕК УЛЫМ ТУГАЧ

Яшьлек белән хушлашу бу –
Күзләремнән яшь тама.
Мәңгелеккә тоташу бу –
Эчкә сыймый тантана!

Бөтен нәрсәм булды инде,
Калмады бер нием!

Иң шатлыклы гимндыр бу!
Иң сагышлы реквием...

## САБЫЙГА МӘДХИЯ

Үзе йомгак чаклы гына,
Үзе сыймый дөньяга.
Авызы уймак чаклы гына,
Тавышы белән егала!

Патшаларны елатала
Мәрҗән-мәрҗән яшьләре.
Йөрәкләрне туктатала
“Ыг-гы!” диеп әйткәне.

Песине дә елмайтала
Телләрен күрсәткәне!
Үзе гади, үзе гений –
Даһи сәнгать әсәре!

Үзе белми сыңар сүз дә
Сүзләр җитми данларга.
Үзе хәреф хәтле генә! –
Хәреф җитми язарга!

## СОЛТАНГА МИРАС

Шушы мирас сиңа улым,
Шушы биштәр:
Монда нәрсә? Зур дөнья һәм
Зур өметләр.
Зур кораблар үзең эзлә
Зур диңгезгә.
Тыйнаклык һәм хәерчелек
Калыр бездән. –
Безгә шундый төяделәр
Капчык-капчык,
Тамак ягын кайгыртуны
Артык вак дип.
Тагын менә бер утыз пот
Гадилек бар. –
Арзан йөри... Ни хак икән
Мин-минлекләр?
Ул – валюта. Бер-ике пот
Гадилекне
Алыш шуңа. Гадилеккә

Пачут бетте.
Минем кебек дошман булма
Мин-минлеккә. –
Берәр грамм бирсәләр дә,
Алмый китмә!
Тагын менә - ап-ачык кына
Гаделлекләр.
Ансын инде алыштырма. –
Мода бетәр
Мордарлыкка һәм бурлыкка.
Син калырсың!
Һәм егет солтаны булып
Дан алырсың!
Сизденме инде! – Нинди байлык
Зур өметләр!
Чүп тә түгел мең-мең бикләр,
Мең-мең чикләр.
Һәм аларны җиңәр өчен
Биреп китәм
Мөмкинлекләр, мөмкинлекләр,
мөмкинлекләр!
Ә Гали батыр пәкесен
Бирә алмам.
Кыюлыкка үзең генә
Өйрән, балам.

## БАЛА ТАПКАЧ

Күпме корбанга бардың син!
Син ничек ярлыландың!
Каурыйларын салып куйган
Тутый кош булып калдын.

Инде ашау-йокыларың
Һичкайчан тулы булмас.
Балаңа чебен тисә дә,
Аш үтмәс, күз йомылмас.
Инде качар тынычлыгың. –
Инде гомер буе син
Бар җирдә бала елавын
Ишетеп абынырсың...

Син мәңгегә әсир төштең,
Хәттә теге доньяда
Чыгалмассың коллыгыңнан,
Чылбыр чыңлар кулларда...

Азатлыктан үзең теләп,
Баш тарттың син, шатланып.
Ирек кошы кунмас бүтән
Талларына бакчаның.

Нәрсәң калды? Ике кулга
Бер малай – алсу гына.
Барын алды. Һәм алачак
Ул ялгызлыгыңы да.
Сиңа бернәрсә дә калмас,
Хәттә гөнаһ-ише дә -
Тузан бөртеге дә кунмас
Бала тапкан кешегә!
Ямьсезлек-сансызлыклар да
Йөрерләр синнән ерак. –
Кулында бала булгач,
Нинди матурлык кирәк!

Тәмам бөлдең, йолкындың син.
Аның саен баедың! –
Каурыйларын алыштырган
Тутый кош сыман булдың!

## УЛЛАРЫМА ИСЕМ КУШТЫМ

Исемнәре чакырып торсын,
Алга омтылсыннар дип,
Зурына Искәндәр куштым,
Кечесенә Солтан дип.
Исемнәрен ишетүгә,
Карасыннар тукталып.
Гел-гел мескенләнмик әле!-
Без – каратырлык халык.
Улларыбыз туа әле
Чәчрәп торган карашлы.
Искәндәр[1] дә, солтаннар да –
Шул ук адәм баласы.
“Кем булса да, ярар!” димә,
Ярамый: кем булса да!
Улым әнә стенадан
Үрмәли ич түшәмгә.
Күкне күрсәтеп “кю-кю” ди
Ачылмаган телләре.
Ә безнең уллар үрләве –

[1] *Искәндәр* – бу урында: Александр Македонский.

Ул – халыкның үлмәве.
Ә “Хәрәкәттә бәрәкәт”
Дигән милләт кем әле?
Ничек тә бер сынык икмәк
Табып була ул ансы. –
Тамак тую гынамени
Яшәүнең бер гыйлләсе?
Нинди шатлыклардан дисез
Йолдызлар балкып тора?
... Ә аста калган халыклар
Казылма байлык була...

***

Минем улым бар дөньяны
Тарата да туздыра,
Туздыруда балалар ул
Бабаларын уздыра!
Тик җыялмый туздырганын,
Елый-елый тырыша.
Көчсезнең көче ни булсын! –
Җенләнергә керешә:
Курчакны ботарлап ташлый...
Баш өзгән бу! Йә дөнья!
Нинди геннар, нинди җеннәр
Көч биргән кулларына?
Ул геннар юньлерәк нәрсә
Бирсә, булмый микәнни!
Нияте изгедән тагын:
“Имонтивать итәм” ди.
Тик авыр – юктан бер ясау!
Бәләкәй шул, белми ул. –
Оештырып куелганны
Җимерү генә җиңел.
Башларны да өзү җиңел, -
Белә моны һәр патша.
Ләкин иң бөек хаким дә
Ясый алмый бер баш та...
Улым берни белми әле,
Геннар[1] гына котырта.
Җимерттерә, ваттыра да,
Аптыратып утырта.
Хәер, зур-зур абзыйлар да
Йөри әле баш ватып.
Таралганны җыялмыйча,

[1] “Ген” күп телләрдә “жин” дип әйтелә.

Тарих тора шаккатып.
Берәү кора, берәү сүтә.
Котыртып, көлә Вакыт!

## ТҮЛӘҮ СОРАМА

Үзалдыма елмаямдыр,
Сиреньнәр кебек.
Үзалдыма сөйләнәмдер,
Сабыйдан көлеп.

Сирень исенә исереп,
Йөгереп чыгам мин.
Шундук айныйм, ишетәм дә
Балам елавын.

Татлы бәби исләренә
Кереп чумам да,
Әй, хуш булып, сәрхуш булып,
Карыйм дөньяга!

Миңа бит яз беренче кат
Бәхет китергән.
Күп чатлы сиреньнәр эзләп,
Гомер ителгән.

Тапкан берсе теләнгәндер
“Бәхеткә!” диеп.
Бәхетнең бәби икәнен
Кем белгән элек!

Үзе бәби, үзе сирень!
Күбрәк бу ләкин...
Язмыш, ялгыш, түләү сорап,
Килә күрмә син!
Түлим дисәң – шушы балам! –
Үзең беләсең...

## УЛЫМА ДОГА

Улым сары бәбкә генә,
Усал тилгән тимәсен.
Улым алсу чәчкә генә,
Усал җилләр тимәсен.
Улым нәни чеби сыман,
Усал чирләр тимәсен.

Улым чибәрләрдән-чибәр,
Усал күзләр тимәсен.
Улым берәү генә җирдә,
Җеннәр алыштырмасын!
Улым, саклыйм сине җеннән,
Үзең алышынма син!
Искән бер җил уңаена
Муен борып торма син!
Тилгән димә, чир дә димә,
Куркып йөгереп йөрмә син!
Безнең нәсел – күзе яшел,
Гомергә баш имә син!

## СӨЙКЕМЛЕ СӨЯК

Жәлләтеп бер ыңгырашса сабый,
Таш эретә ала.
Көче түгел, көчсезлеге аның
Әсир итә ала.
Сине яратканга түгел, үзен
Яраттырган өчен,
Аңа йөрәкнең иң изге
Җирен жәлләмисең.

Һәм ул алган урын – алтын тәхет –
Бары аңа гына.
Моның кемгә ныграк кирәген тик
Белә ана гына...
Күңелне дә, гомерне дә ала,
Бары – ала бала!
Һәм ул түгел, биргән кеше аңа
Рәхмәт укып кала...

Ләкин Ходай кушмый һичберкемгә
Бурычлы калырга.
“Сөйкемле сөягең белән түлә!”-
Дигән ул сабыйга.

## ӘНИЛӘР САГЫНА

Җир яшәрә, яз була.
Оя-оя каз була.
Әниләр балаларның
Сабый чагын сагына.

Каз кычкыра чагылда

Ялгызлыгта, кайгыда:
“Калган гомрем биреп кайтыйм
Оя-оя чагыма!”

Әй, казкаем, кагынма!
Йөрәкләрем ярыла!
Калган гомерне биреп тә,
Кайталмыйм узганыма...

Канат чыккан балага
Очар далалар көтә.
Сагынганда, чагылларга
Бер кайтсалар, мең шөкер...

Җирдә сихри көч таша.
Хатын-кызны хис баса.
Ямь-яшел каз бәбкәләрен
Тотып сөям ичмаса!

Күңел тулы наз гына.
Ничекләр бушанырга?
Әниләр балаларның
Сабый чагын сагына.

## СИН...

Төннәрдә елмайганым,
Гүрләрдә уянганым,
Күкләрдән сораганым,
Юкларга инанганым!..

Юктан бар кылганнарым,
Утта яндырганнарым –
Дөрләтмәк булганнарым,
Көйрәпләр торганнарың!

Күмергә калганнарың,
Гүремә салганнарым...
Хыялланганнарым!
“Шагыйранә ялган”ым!..

## ШОМЫРТКАЙ

*Җыр*

Урамда яз. Шомыртларга бәйрәм.
“Чәчәк чагым” дияр чак җиткән.
“Иң бәхетле көннәрем бу!” дигән
Истәлекләр калсын яшьлектән!
Әй, шомырткай! Ап-ак чәчәктә.
Ник суыта икән шул чакта!

Ак тәлгәшләр калтырана төсле
Һәм сызлана төсле суыктан.
Чәчәк чакларында бәхет кичеп
Өлгерәләр микән шомыртлар?
Чәчәк сибеп язгы җил исә,
Язгы язмышлар  да төрлечә...

Караерлар әле шомыртлар да...
Ак вакытта, чәчәк вакытта
Кара, кырау кагылмасын иде
Бүтән мәңге кайтмас шатлыкка!
Әй, шомырткай! Ап-ак чәчәктә.
Яшь буласы иде яшь чакта!

## ЯРЫЙ ИНДЕ ҖАЙ ЧЫККАЧ...

Әйләнә дә бер баса бу
Куласа.
Әллә ниләр кыла язмыш,
Теләсә.

Әллә нинди сыйфатларга
Керттерә.
Үз-үзеңне танымаслык
Иттерә.

Тешне ертып керә язган
Ашлары.
Язган булса – югалттыра
Башларны!

Бер рәхәткә - ун михнәт тә,
Ун кыен.
Гадел түгел мавыктыргач
Бу уен.

Шаккатыргыч сюрпризлар
Дөньясы!
Һәм яшәүдән бүтән мәгънә
Юк, ансы.

Көтмәгәндә - башыңа таш
Яки – таҗ!
Кызык уен, туктап булый,
Мавыккач.
Ярый инде, яшәп карыйк,
Җай чыккач.

## ШУНДЫЙ ОЧРАК

Мин көтә белмим. Көтәрмен. –
Монысы шундый очрак:
Син миңа кайтырга тиеш,
Бар юллыйсыңны юллап.
Күп сулар эчәргә тиеш,
Эчәргә дә - чәчәргә!
Минем чишмәм агып ятар,
Исләрендә яшәргә.

Яңалыклар мавыктыргыч!
Алар миннән көчлерәк.
Минем көчне аңлар өчен
Сиңа китәргә кирәк.
Җирнең тарту көчен дә бит
Сизәбез, сикереп карап...
Сикер! Җирдән өскә очсаң,
Искә төшермәм кабат!..

Кояшлар - төрле дә була:
Бу шушындыйрак очрак.
Иң якты дип тапсаң гына,
Минем кояшыма бак.
Кайтма да, шулай булмаса:
Төннән-төнгә күчмәсәң,
Кояшымның күзен чагылып,
Җиргә авып китмәсәң!

Йә, үлү бу, йә калу бу –
Ким дә түгел, артык та.
Белеп торам – кайтмассың син,
Яши алсаң мин юкта.
Кайтсаң – соңгысы булырмын.

Минем тупса шундыйрак:
Егылырга үлем хәлендә,
Кашык ярым су сорап.

## ЯРЫЙ ИНДЕ...

Һәр күрүем – соңгы тапкыр.
Дер дә дер керфек очым.
Син – чатнаган чаганымны
Язгы тал иткән кошым!
    Сыгылып калсын талларым ла,
    Сөенеп калсын җаннарым!
    Их! Зая үткән язларның
    Заялыгын аңладым!..
Инде үлсәм дә үкенмәм,
Елармын гына, җуйгач.
Еласаң да, ярый инде ул,
Күзен язларга чумгач.
      Мәңгелек яз вәгъдә итмә -
      Гөнаһлы була күрмә...
      “Мәңге” диясең килгәндә,
      Озайт кына бер көнгә!
Һәр күрүем – соңгы тапкыр.
Бүтән ни юрыйм инде?..
Ярый инде, ярый инде,
Яз күпкә бармый инде...

## НИК ТУЗАСЫҢ!..

Көзге яфраклар бураны!
Бу җил котырды!
Эчләреңә суык үтеп,
Калтырыйсыңмы?..

Кыйный язмыш ботакларны,
Сындырып алып.
Бик нык җәзаланасыңмы,
Җаның кайналып?

Әй, туза, тузына давыл!
Niләр телидер?!
Тузган уйларың сиңа
Тынгы бирмидер...

Бу – азаккы көне булыр
Зәгыйфь кошларның.

“Аh!” – дип тә хәбәр бирмисең!
Ничек коткарыйм?

Яклар идем, каплар идем,
Коткарыр идем,
Җаннарымны атар идем
Синең өчен мин!
... Ах, тузгыган уйларында
Үземне күрмим...

Синең тузгыган тормышың –
Синеке генә.
Анда миңа урын булса,
Сизәр идем лә...

Синең белән тулган җаным
Түгелә җилгә.
Нишләсен?-
Җилгә аh ора,
Давылны сүгә:
Миңа буласы түгел бит! –
Ник тузасың, җә!!!

## БЕРДӘНБЕР ЧАРА

Йөрәгемнең син - өметсез чире,
Тик Вакыт кына - өмет аңарга.
Тетрәү дә рәнҗеш эчләрем тулы!-
Тетрәп торалар җир дә, hава да.
Ай, бер сүзкәен “Исәнме!” дигән...-
Вакыт кодрәтен юк дип белергә,
Үксеп тетрәгән hава дулкынын
Шау музыкага әйләндерергә!

Тик минем тетрәү – синеке түгел. –
Аңлап торасың, дәшмисең шуңа.
Син дә телисең hава җырлавын!
Ах, җитми тора бер тылсым гына!..

Тылсым кылмагач, бу Сөюемне
Нәрсәгә дип кылдың, Ходаем?!
Ә син җәлләмә, “Исәнме!” – димә.
Исән түгелмен. Ләкин чыдармын.
Исән түгелмен. Син – минем чирем.
Терелтәлмәссең, бик тырышсак та.
Бер-беребез өчен яңадан туу –

Бердәнбер чара безнең очракта.

***

Тыңлыйм сине, йөрәкләрем
Калтырап.
Йөрәгемнең гамәленә
Аптырап.
Йөрәгемнең хәлләренә
Аптырап.

Дәшәм сиңа – баллар тама
Телемнән:
Үз балыннан сәрхүш булып
Тилергән!
Мин тыялмыйм – балым тулып
Түгелгән...

Син тыңлыйсың, син эрисең,
Онтылып,
Бер мәгънәсез сүзләремә
Йотылып,
Калтыраган йөрәгемә
Кушылып,
Эчләремне мәгънә белән
Тутырып!

## МИН СӨЙСӘМ...

Мөлдер күзләреңдә диңгез төсе.-
“Хейзел” була икән сезнеңчә.
Дулкын-дулкын, алкын-салкын – шашкын!
Төштем-баттым! –“әһ!” тә димичә!

Йөзә белмим. Диңгез төпләрендә
Әйләнермен алсу энҗегә.
Булалмыйммы мин бер бөртек энҗе!-
Керә алгач инде күзеңә!

Ә теләсәң – йөзәм. Өйрәнми дә
Йөзәлермен синең кочакта.
Бер диңгезне генә кичмимме мин,
Хейзел дулкынныры бар чакта!

Ә “чык!” дисәң, чыгам... Диңгезеңә
Ут төртимме? Нишлим иң элек?

Әллә эчеп кенә куйыйм микән,
Күзләреңә генә иелеп?

Бер диңгезне генә эчмимме соң,
Әй, “хейзел” ем, “Чыкма! Эч!” дисәң!..
Мин эчкәннән тик ул ташар гына, -
Корытмыйча сөям мин, сөйсәм!

***

Чирле мәхәббәтем минем!
Яратуым яралы.
Әрнү тулы ләззәтләре,
Тынычырак газабы.

Әрнүләргә чыдый алмыйм,
Чирен яшергән – үлгән.
Мин – түземсез, үлемсез зат...
Авыртудан тилерәм!

Өч көн җенләнеп ярату!
Бик җиткән бер гомергә.
Акылыма көч бир, Раббым!
Җеннәр түгел җүнлегә!

Ә газапларг – түзәрмен,
Өйрәнгән аларына.
Хуш, мәхәббәт! Тапшыр мине
Терелү газабына.

## ЯҢА ГОМЕРДӘ...

Әй, ашыктым шул!
Күбрәк кителгән...
Ярты-йортылай
Гомер үтелгән!
Ярты алманың
Шул булыр инде:
Бәргәләнер дә
Сугылыр инде!
Кабаланыр да
Эше дә уңмас.
Күпне эзләр дә -
Ише табылмас...

Язган яртымны

Танымыйммы соң!
Әй, бәгърем, нишләп
Соңга калдың син?!

Мин, ни, бик туктап
Көтәр идем лә,
Туктап көтүләр
Юк бу гомердә!
Газиз яртылар
Аерым йөгерә.
Бөтен алмалар –
Йөзгә бер генә!

Безнең алмабыз
Кушылыр әле.
Дөньясы гына
Бу түгел әле!
Чыгып китәрбез
Бер үк капкадан...
Их, Мәңгелектә!..
Мәңге ташламам!
Алга ашкынмам,
Калмам артыңнан,
Таулар купса да,
Купмам яртымнан!
Нинди камил бит
Без икәү бергә!
Хуш... күрешкәнче
Яңа гомердә...

## СИН ГЕНӘ МИНЕМ ГОМЕРДӘ

*Җыр*

Уйный-уйный тормыш сәхнәсендә,
Әллә кемнәр булып бетелгән.
Син – бердәнбер сәнгать икәнсең лә
Минем өчен иҗат ителгән.
    Болгандым-тулгандым, югалдым...
    Кайда мин – табалмыйм үзем дә!
    Син генә мине мин итәсең,
    Син генә - миңа җан өрергә.
Тик син ачтың минем чын йөземне,
Үз-үземне күреп сокландым.
Күпләр әйткән иде матур сүзләр,
Синең сүзгә генә ышандым.

Болгандым-тулгандым, югалдым...
Кап-кара дөм иде күңелдә.
Кем бирде сиңа бу ачкычны?-
Ачтисәң, миннән нур сибелә!
Башың иеп, күзең йомдың да син,
Минем күзләремне шар ачтың:
Күрдем кинәт синең йөрәгеңне –
Һәм үземне тәү кат яраттым!
Болгандым-тулгандым, югалдым...
Юк идем якты җир йөзендә.
Син иҗат ителгән – яңадан
Миңа җан, миңа күз бирегә!

***

Агачлар кып-кызыл, нык кызыл!
Нык кызу, нык рәхәт, нык кыен!
Үтә кызу тиз уңганын
Ничек итеп онтыем!

Кан саркый йөрәктән, нык саркый!
Җан балкый – кып-кызыл, нык балкый!
Кемнәр икән шушы кадәр
Бәхетлк гомер бакый!

Ах, миңа ут капты, нык татлы!
Нык капты – күз чыга - нык якты!
Тик сукыр мәхәббәт кенә
Яктыдыр шул чаклы!

Бу хисләр иләсәләр – бик яшьләр!..
Тавышымда тик яшьләр, күп яшьләр...
Нигә көзгә кала икән
Үтә кызыл миләшләр?!

## КАЕН УТЫНЫ

Мин - каты каен утыны.
Аңламасаң, карап тор:
Җем-җемләнеп яңа каен,
Чәмләнеп, чатыр-чатыр.
Җырлый-җырлый янадыр шул –
Каен булып каладыр!
Шартлап торган күмерләре
Кызыл-кучкыл карадыр.

Шушылай шылтырап төшә
Каен күмере генә!

Таптап-таптап сүндермәсәң,
Җитәрмен гомереңә!
Ялкыннарым булыр биек,
Алдында торыр биеп,
Авызыңа керер килеп
Тавис кошлары булып!

Үпкәч-үпкәч, үбәм инде
Мин кош тоткан иренне!
Һәм сүнмәс елмаюларың –
Мин бит каен күмере!
Авызыңда бәхет кошын
Мәңге тотармын тере!

Яңа хуш исләр таратып,
Чатнап та чатнап каен.
Ә син тик карап кына тор...
Калганын – аңа калдыр...
Чатыр-чатыр чәм эчендә
Әллә нәрсәләр бардыр!

## БӘХЕТ МАНЗАРАЛЫРЫ

Эчем генә тулып утлар яна
Һәм тыйгысыз исәр елмаю...
Көя-көя кем сөенә инде? –
Әй, исәрләндергән дөнья бу!
Сихер белән сыный бугай бу!

Эчем тулып утлар янмаганда,
Җилләр уйнаганда аранда,
Курыкканмы соң мин бураннардан!
Юкны нинди буран алала!-
Кыю башлар кыю калала.

Яфрак очындагы җилләргә дә
Ялынырлык хәзер көннәрем:
“Араларга гына керә күрмә,
Утларыма гына өрмә!” –дим...
Шундый идемме мин? – кем дә кем!

Өркәм үземнән дә - көзгедәге...
Кол көннәре бирдең, йә Аллам!

Нинди татлы коллык ләззәтләре!
Кире генә алма, ялварам!
Сакла “Ирек” дигән ялганнан!

Беренче һәм соңгы кат бу – беләм:
Мин тезләнгән, беткән, җиңелгән...
Тик иреккә генә кума берүк
Дер калтырап сөю иленнән!
Мин – яраткан колың, сөелгән!

Эчем генә тулып утлар яна.
Дөнья тулы сихри елмаю!
“Югалтудан курыксын!” дип миңа
Бәхет биргән серле дөнья бу.
Бәхет белән сыный бугай бу...

## ХӘСРӘТЛЕ ҖЫР

Нигә шулай ургып чыга икән
Сиреньнәрдән чәчәк ташкыны?
Тыштан гына балкып сибелә шул,
Эчләрендә кала ярсуы.
**Кушымта:**
Сиреньнәр күп иде! Нигә дип түзелде!
Гомерләр узылды, үзәкләр өзелде!
Яшәдем җан атып, дәшмәдем
Һичакыт...
Чөнки мин ифрат нык,
Ифрат нык яраттым бит сине!..

Язлар саен гүзәл ул ярсулар
Хуш исләрен бөркеп чыккандыр.
Җан сөйгәнен килеп сакламагач,
Җиде яттан кемнәр коткарыр?
**Кушымта.**

Тәлгәш-тәлгәш яралган ла сирень!
Җилләр йолкый берәм-берәмләп...
Йолкынырлык чәчәк идемме мин?-
Исләреңә төшер бер җәлләп!
**Кушымта.**

Тыштан гына балкып сибелә сирень,
Эчләрендә кала ярсуы.
Хәсрәт җыры булып чыга икән
Артык яратулар шаукымы...

**Кушымта.**

***

Кашыга белән бирәсең,
Төртәсең сабы белән.
Өнгә тартып чыгарасың,
Төшләрдән айну белән.
Эчкә сыймас куанычлар
Оча җилгә - вәссәлам!
Бернәрсәң дә чын булмагач,
Бәхет нидән ясалган?!
Бер ялганга ярты дөрес
Булса да, ярыйдыр бит?
Алдавычка кабабыз без
Судагы балык кебек...
Кармагыңнан куптарасың,
Ярга селтәп саласың!
Гомер үтә, ялый-ялый
Шул кармаклар ярасын...
Үзең тагын бәндәләрне
Яраткан саналасың!
Бәхет ясарга балчык та
Җәлләп яткан Алла син!

***

Мәхәббәтем сүнмәс борын,
Ник нәфрәт яктың инде?
Мине ике утка салып,
Ни кызык таптың инде?

Тынымнан да мәхрүм булып,
Турыга каттым инде.
Мине тереләй үтереп,
Ни файда таптың инде?!

***

Мин үтердем бүген сине,
Гаделсез хөкем итеп.
Бу гөнаһлы дөньяда
Саф калыйм ничек итеп?..
Синдә генә мондый чырай –
Изгелек тә сабыйлык!
Андыйларны суга Ходай

“Миңа тиң булма!” – диеп.
Мин соң сине ничек итеп
Коткарыйм ул җәзадан?-
Үзем Ходай иҗат иткән
Җирдән генә яралган...
Ярдәм итә алмагачтын,
Ташлап китәм – ни кала?..-
Чыраема чыпта каплап,
Ни чарадан бичара!
Чыпта читен тарткан булам,
Ләкин ачып куялмыйм.
Юк, булалмыйм көрәшүче
Һәм корбан да булалмыйм.
Егылганны түбәлим тик.-
Дөрес, шулай якынча...
Әй, фәрештә була бит ул,
Кара җирдән ак булса!
... Мин инде тәмуг кисәве,
Рәнҗеш төшү хак булса...

***

Хәбәрең-хәтерең юкка
Тугыз көн бит, тугыз көн...
Минем кебек түземсезне
Түздерергә - син соң кем?!

Түздерүдән уздың әллә,
Биздерергә булдыңмы?
Алайга ук киткән булса,
Биздерсәң дә - урынлы!

Тик минем күк бирелгәнне,
Бирәү өчен үлгәнне
Түздерегә, биздерергә -
Син ул кадәр кем әле?!

Юк, әллә кемнәр булсаң да,
Җиңәлмәссең, бел аны, -
Түземсез булган көенә
Биземсез дә булганны!

Ә минем җиңүнең хакын
Белмәссең кем булсаң да. –
Синең кергәнең дә юк бит
Мин әрнегән утларга!..

...Тугыз көндә туксан тапкыр
Янып, кире терелдем....
...Үземнән дә җиңдермәгән –
Кит... мин әллә кемдермен!

## ГАҖӘБЕМНӘН ГАҖИЗМЕН

Карадым да капландым!
Кайнап чыктым! Чак калдым...
Тик чәчрәп түгелсәм дә,
Җирләргә убылсам да,
Сүз дәшәлмим, үлсәм дә!-
Аз булыр, ни дисәм дә!..
Булганында таң калган,
Мөлдер-мөлдер чайпалган,
Очравына шаккаткан,
Авыз ачып җан аткан,
Тезем тотмый, җир сизмим,
Хайранмын да хәлсезмен,
Нәрсәгә дә әзермен,
Гаҗәбемнән гаҗизмен...
Кабул булган теләк син,
Теләктән дә күбрәк син!
Догаларны ишеткән
Бер Ходайга мөкиббән!-
Кулларыңа алгансың,
Алларыма салгансың!
Инде кире алма син,
Аллам! Мине ая син!
“Ник бирдем!” дип үкенмә -
Изге булам бу көннән;
Ант итәмен аң белән –
Куш, кырыкка ярылам!
Ләкин җитмәс аңнарым:
Могҗизадыр язганың –
Ничек мине аңладың?..
Ничек мине сайладың
Ундүртенче кичәсен
Күрсәтергә айларның?..
Кодрәтеңнән телсезмен,
“Иксез- чиксез” – бер сүзем.
Рәхмәтеңнән, Ходаем,
Җырлаем да елаем!